1926–1991 ЕЛЛАРДА АЗАТ ХАТЫН

2021 АВГУСТ № 8

СӨЮМБИКӘ

ISSN 0869-1398

ГҮЗӘЛИЯ
катнаш никах
җиде кат уйла, бер кат кис

ир тоткынында
САБЫР ТӨБЕ
алтынмы

карлыганлы
ЗЕФИР
сере – төгәллектә

Эльмира
МИНҺАҖЕВА:
«Халкыбыз киләчәге – Ана данын яклауда, балалар сәламәтлеген саклауда».

Мин әни булдым, әни!

Мин әни булдым, әни!

Мин әни булдым, әни!

Шушы сүзне әйткән мизгелдә барысы да үзгәрә! Аралар тагын да якыная, җылына, күңелләр бер-берсен сүзсез дә аңлый... Бер үк кичерешләр аша узганнарның якынлыгы башка аның. Сүзләр, хәрәкәтләр, теләкләр бөтенләй үзгә төсмер ала. «Менә әни ни өчен ул вакытта шулай дигән, шулай эшләгән (яки эшләмәгән) икән», – дип уйлыйсың... Барысы да мәңгелекнең үзе кебек гап-гади, чөнки син – Әни! Ә Әниләр инде бер телдә сөйләшә...

Өр-яңа проект башлыйбыз. «Мин әни булдым, әни!» дип атала ул. Бер фоторәсемдә өч буын – әниегез, сез һәм кызыгыз (улыгыз): буыннар чылбыры шулай тезелә!

Җылылык, яктылык, нур бөркеп торган мондый фотосурәтләр сездә дә бардыр – кушылыгыз!

Чулпан ЗАРИФ



* * *

Сиңа миннән мирас – сөю тулы
йөрәк.
Күзең – күктә... «Әни! Миңа йолдыз
кирәк!»
Сиңа миннән бүләк – шәфкать тулы
кочак.
Күзең – күктә: «Әни! Без дә
коштай очсак!»...
Улым, йолдыз ерак, алып булмый аны...
Кошның да бер тала очып канатлары...
Кил, әкият сөйлим, җырлыйм
татар җыры.
Тышта салкын, өйдә – бәлеш исе,
җылы...
Серләр белән тулы зәңгәр гөмбәз ул
Күк!
Йоклыйк инде, улым. Уянасы иртүк...

■ Һәр гаиләдәге кебек үк, безнең дә үз традицияләребез бар. Гаиләбез интеллектуаль уеннарга мөкиббән. Бик еш өй турнирлары уздырабыз. Аңа кадәр әни белән өчпочмак әзерлибез, тәмле чәй пешерәбез. Аннан соң, сыйлана-сыйлана, уеннар уйныйбыз. Җиңүчеләр өчен алдан бүләкләр дә әзерләп куябыз әле. Мондый кечкенә генә традицияләр гаиләне ныгыта, тагын да берләштерә, без бербөтенгә әйләнәбез.

Альбина ТАРАСОВА.
Казан.

Фото: Анна Арахамия.

Сөй гомерне, сөй халыкны, сөй халыкның дөньясын!



© «Сөембикә» 2021



Фото: Анна Арахамия

Ежемесячное литературно-художественное и культурно-просветительское электроннное периодическое издание на татарском, русском языках для женщин и семьи.

Территория распространения: Российская Федерация, зарубежные страны

Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендәге күзәтчелек буенча Федераль хезмәтендә (Роскомнадзор) 2015 елның 18 маенда «Сююмбике» дип теркәлгән. Теркәү таныклыгы Эл № ФС 77-61814

Язмалар авторның тулы адресы күрсәтелеп, паспорт мәгълүматлары, пенсия иминияте таныклыгы, ИНН таныклыгының ксерокс күчермәләре белән бергә җибәрелгәндә генә кабул ителә.

Кульъязмаларга бәя бирелми, алар кире кайтарылмый.

Баш мөхәррир
Л. Н. Маликова

Редколлегия:
Зилә Вәлиева, Нурия Вәлиева, Искәндәр Гыйләҗев, Нәбирә Гыйматдинова, Айрат Зарипов, Эльмира Зарипова, Кадрия Идрисова, Сәрия Сабурская, Нурия Һашимова, Гөлназ Шәйхи, Рафаэль Шәвәлиев, Равилә Шәйдуллина, Лотфулла Шәфигуллин.

Редакциянең гомуми телефоны 222-09-77

Җитәкче урынбасары 222-09-78
Рәмзия Кашапова
Баш мөхәррир урынбасары 222-09-78
Гөлнур Хәсәншина
Җаваплы сәркатип
Лариса Маликова
Әдәби мөхәррир
Эльмира Закирова
Сайт мөхәррирләре:
Сөмбел Гаффарова
Камилә Димөхәммәтова

Автор фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.

Реклама текстлары аны бирүчеләр җаваплылыгында.

Редакциянең язмача рөхсәтеннән башка материалларны «Сөембикә»дән күчереп басу тыела.

Тышлыкта:
Эльмира Минһаҗева
Фото: Анна Арахамия

Мөхәррирләр
Чулпан Галиәхмәтова
Сөмбел Гаффарова
Алсу Шакирова
Фәгыйлә Шакирова
Верстка
Резеда Галиуллина
Корректор
Фирдәвес Исмәгыйлева
Фотокорреспондент
Анна Арахамия
Гамәли хезмәткәрләр
Ильмира Сөләйманова
Виталий Матвеев

Формат: 225x290 мм
Күләме 64 бит

Басарга кул куелды: 3.08.2021 ел.
Чыгу көне: 12.08.2021 ел.
Заказ Е-2634
Тираж 9563

Учредитель: Акционерное общество «Татмедиа»



ТР «Татмедиа» Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр республика агентлыгы ярдәме белән чыгарыла.

Басма Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча федераль агентлык ярдәмендә нәшер ителә

Редакция адресы: 420066, Казан, Декабристлар урамы, 2 нче йорт.
www.syuyumbike.ru
E-mail: suumbike@tatmedia.com
ssuum@yandex.ru
тел./факс: (843) 222-09-77

Язылу индексы
ПАП рәсми каталогы буенча:
Татарстанда П2204 (ярты еллык),
П8299 (берьеллык)
Татарстаннан читтә: П0279

Банк реквизитлары:
Филиал АО «ТАТМЕДИА»
«Редакция журнала «Сююмбикә»
Расч/счет 40702810600020010309
кор/сч 30101810000000000805
в ПАО «АК БАРС» БАНК г. Казань
ИНН 1655144950
БИК 049205805
КПП 165802002

16+





Фото: Анна Арахамия

30 АВГУСТ – ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КӨНЕ

Шамил МАННАПОВ

Татарстан җире

Син шундый җир:
Җан җылымлы, йомшак, –
Яхшы орлык шытмый калмый инде.
Халкым күңеле кебек уңдырышлы,
Туган җирем –
Татарстан җире.

Син шундый җир:
Бөтен дөнья буйлап
Таратса да кырыс заман җиле,
Кайларда да ямен, тәмен җуймас
Туган җирем –
Татарстан җире.

Куп күргәнсең,
Күтәргәнсең күпне,
Өркетмәгән, селкетмәгән бере.
Халкым кебек чыдам авырлыкка
Туган җирем –
Татарстан җире.

Зур төзелеш мәйданнары итеп
Сайлады Ил синең киңлегеңне.
Халкым күңеледәй иркен бу җир –
Туган җирем –
Татарстан җире.

Безнең тышлыкта





10

«Гаилә кыйммәтләрен пропагандалауда, ана булуның изге бурычын бала күңеленә салуда әти-әниләрнең, укытучыларның, табибларның бердәм хезмәте генә нәтиҗәле булачак.»

«Ана булу – тиңдәше булмаган хөрмәттер»
Алсу Заһидуллина

Заман һәм без

6 Сабыр итәм димә...
Мәдинә Авзалова



«Иҗатымны ваклыйсым килми...»
Чулпан Галиәхмәтова
14



16
«Ат духтыры»
Алсу Шакирова



20
Күңел җырлый!
Гөлнур Хәсәншина

Татар дөньясы



22 Яктылык
Гөлнур Сафиуллина



26 Ярларны тоташтырган күпер
Алсу Шакирова

Мәдәни тормыш



32 Зөбәйдә
Зиннур Хөснияр

Яшәеш

40 Сагыналар сине, Ландыш!..
Эльмира Закирова



44 Язмыш шаяруы
Чулпан Галиәхмәтова

48 Идел–Чулман–Агыйдел
Вәсилә Рәхимова


Хуҗабикә

57 «Толлар бөкресе»н чыгармыйк
Чулпан Юнысова

58 Паӊнода... җәйнеӊ хуш исе
Алсу Шакирова



60 Карлыганлы зефир


Фото: www.pixabay.com

Бер-берсенә охшаган да, охшамаган да алар... Кайсы аның баштан кичкәннәре, күңеленең иң тирән почмагына кереп урнашып, үзе дә кагылырга кыймаган авыр истәлекләре турында, «искә төшерүләре хәтәр» дисә дә, теләп сөйли. Кайсы бөтенләй сөйләми... Алар кинәт исеп куйган җилгә дә, кайдадыр еракта ишетелеп киткән тавышка да сискәнеп, дертләп куя. Сөйләгәндә әледән-әле як-ягына карангалап ала. Курку хисе һич тынгылык бирми. Үткәндә калган мәхшәрне оныта алмыйлар, күрәсең.

САБЫР ИТӘМ ДИМӘ...



Мәдинә АВЗАЛОВА

«Мин хәзер бернидән дә курыкмыйм. Мин инде башка», – ди әнә берсе, бүгенгесенә шөкер итеп. «Әти-әнидән дә якын, кадерле кеше юк бу дөньяда. Авырлык килсә, аларга таянасың. Ә мине әни гомер-гомергә күралмады. Әти исә алдады», – дип өзгәләнә икенчесе.

«Аерылышу минем өчен иреккә чыгуга тиң...» Залим ирдән качып китүчеләр барысы да, сөйләшеп куйгандай, шул бер сүзне кабатлый. Үз теләгең белән кергән капкыннан ычкыну юлы, котылуның бердәнбер чарасы – алдыңа-артыңа карамый качу. «Мин инде түздем, ә син түзмә...» Күп еллар аралашып йөргән танышымның кызына әйткән сүзләре – ир тоткынында яшәгән күпләр өчен гыйбрәтле сабак ул.

Гаиләдәге җәбер-золым, ир белән хатын арасындагы мөнәсәбәтләр киеренкелеге – ул беркайчан бетмәс, көн тәртибеннән төшмәс җитди мәсьәлә. Гаилә эшләренә тыкшынырга, ир белән хатын арасына кысылырга ярамый дия-дия, шундый көнгә калдык та инде без. Дөрес, әлеге проблемага бүген башкачарак карыйбыз. Хатын-кыз хокукларын яклау – дәүләтебез алып барган милли сәясәтнең өстенлекле юнәлеше дип әйтер идем.

Менә инде бишенче ел унышлы эшләп килгән, бик күп әниләргә күңел җылысы биргән, матди ярдәм күрсәткән, мөстәкыйль тормышка яраклашырга булышкан «Мамин дом» («Анам йорты») кризис үзәге – шуның бер мисалы. Сүзебез – шул үзәктә булып, шул йорттан канат очырган әниләр турында. Дөньяның бөтен газапларын татыган ханымнар бу хакта үзләре бәян итәр.

Раушания Хәйруллина, 39 яшь: «Ир тоткынында»

– Мин сөйләгәннәр кемнәргәдер гайре табигый хәл сыман тоелмас та, бәлки. Чөнки минем хәлдә калган хатыннар күп, бик күп алар. Балачагымны сагынып искә алам. Әти белән әни кочагында, тәрбияле гаиләдә үстем. 18 яшемдә гашыйк булдым. Егетем белән ярты ел гына очрашып йөрдек тә, аны армиягә алдылар. Яраттым мин аны! Армиядән кайтуына ярты ел да узмады, өйләнештек. Аннары кызыбыз туды. Минем бәхетем, шатлыгым... Ләкин тора-бара ирем белән аралар суына башлады. Бер-беребезне аңламас хәлгә килдек. Мөнәсәбәтләр катлауланды. Кем белә, бәлки, ул баштан ук шулай булгандыр, сизмәгәнмен генәдер. Ә хәзер аңладым. Аңладым, ләкин шулай булырга тиеш дип, гел үз-үземне ышандырырга тырыштым. Тавышланасы килмәде. Бөтенесен ничек бар, шулай кабул иттем.

Ирем хакимлек итәргә ярата торган кеше булып чыкты. Гел боерып кына тора! Яши-яши рухымны сындырды, җанымны изеп таптады. Мин аралашкан танышлар, дуслар даирәсе көннән-көн тарая, кими барды. «Нәрсәгә ул сыйныфташларың белән очрашасың? Җыенысы алкоголиклар, уйнашчылар», «Бу хатын белән сөйләшеп йөрмә, ул начар. Мин аны бик яхшы беләм», «Туганнан туган сеңлең усал. Аерылышуыбызны тели, бездән көнләшә ул», «Эшләгән җирең, коллективың бернигә ярамый. Бу эш синеке түгел!». Көн саен тузга язмаган шундый сүзләр тукып тора... Әкренләп янымда кеше калмады да диярлек. Тормышымны үз кулына алды ул. Болай ярамый, дим, көлә генә. Соңыннан ачуы килә башлады. Кызым туганчы, әле йөкле чагымда, берничә мәртәбә кул күтәрде. Ул вакытларда үзем дә җебегән булганмын инде, каршы торырлык көч таба алмадым. Ә бала тугач, ул миннән читләште, ерагайды. Өстәвенә, нык алдакчы да иде әле. Берничә мәртәбә китәргә дә җыендым. Төенчекләремне төйним генә, ул, үгетләп, уемнан кире кайтара. «Синнән башка тора алмыйм», имеш. Үзен кызгандыра, үкенә башлый.

«Син ялгыз түгел» хатын-кызларга ярдәм күрсәтү челтәре хәйрия ярдәме проектын башлап җибәрде. Ул Казанга да килеп ирешәчәк. Emergency Box – кыен хәлдә калган хатын-кызлар өчен кирәк-яраклар җыелмасы. Россиянең 11 регионында эшләп килгән 19 кризис үзәгендә яшәүчеләргә шундый 1000 сумка җибәрелде. Һәр җыелмага 13 танылган брендның уннарча әйбере кергән. Болар барысы да бушлай.

Хәтта шантажга кадәр барып җитә. Бала тугач «китәм» дигәнемә ямьсез итеп көлде генә. «Кемгә кирәк соң син балаң белән? Кемгә кирәк ипотекаң белән?» – дип мыскыллады. Ә үзе мине икенче баланы табарга үгетләде. Үземнең дә малай алып кайтасым килә иде – ризалаштым. Улым дөньяга килгәч, бераз тынычланып та киткәндәй булдым. Бәлки, шулай тоелгандыр гына... Ихтимал, мин буйсынуның тагын бер баскычына гына күтәрелгәнмендер.

Малайга өч айлар булганда яңа проблемалар башланды. Бар көчемне җыеп, баланы дәвалауга алындым. Беркемдә, бернидә кайгым юк иде. Аннары өченче балага уздым... Уйлаштык та, фатирны сатып авылга күчендек. Ирем шулай теләде. Тормыш гел ул дигәнчә генә бара иде бит безнең. Мин япа-ялгыз калдым. Сыйныфташлар белән күрешкән юк, хәтта колледждагы дус кызлар белән дә аралаша алмыйм – ирем рөхсәт итми. Янәсе, алар начар, хөсетләр. Имеш, әйләнә-тирәбездә барысы да бездән көнләшә, аерырга телиләр. Һаман бер сүз, кыскасы. Әни дә, ике бертуган сеңлем һәм кияү калды. Хәер, кияүгә дә тынгылык бирмәде: «Ул булдыксыз, ул ялкау, ул алдакчы...» – дип хурлады.

Өченче балабыз – кызыбыз тугангда көч-хәл белән йортны салып бетердек. Күчендек... Хәзер инде дуслар белән интернет, ватсап аша гына аралаша алам. Ләкин ул телефонны да тынычлыкта калдырмады. «Күп



Алия БАЙНАЗАРОВА, «Благие дела» («Игелекле эшләр») хәйрия фонды җитәкчесе

– Безнең фонд 2015 елда оештырылды. Фондның максаты – социаль ятимлекне кисәтү. Кыен хәлдә калган гаиләләргә профессиональ ярдәм күрсәтәбез. Бирегә килгән әниләр белән психологлар, юристлар, социаль хезмәткәрләр эшли. Кайчак башка белгечләргә дә мөрәҗәгать итәбез. Гаиләләр белән эш «Кейс-менеджмент» технологиясе буенча алып барыла. Без аларга аякка басарга, эшкә урнашырга, матди тотрыклылыкка ирешергә булышабыз. Оешып эшли башлаган шушы кыска гына арада да Россия Федерациясе фондының Президент грантларына, Татарстан Министрлар Кабинетының, Икътисад министрлыгының, «Лукойл», «Татнефть» акционерлык җәмгыятьләренең грантларына лаек булдык. Татарстан Президенты безгә бина бүлеп бирде. «Анам йорты» 2016 елдан бирле эшли. Баштарак өч бүлмәле фатирны арендага алып торган идек. 2018 елдан шәһәрнең тыныч бер урыныннан коттедж бирделәр. Биш ел эчендә бездә алтмышлап әни, йөзгә якын бала булып китте. Бүген әниләрнең барысы да мөстәкыйль көн күрә. Тору бушлай. Алар бездә бер айдан алты айгача яши ала. Һәр әни белән шәхси план төзелә, проблемадан чыгу юллары, бурычлар билгеләнә. Кирәк икән, психолог, юрист булыша. Әниләр бездән мөстәкыйль тормыш алып барырлык, үз көннәрен үзләре күрерлек булып китәләр.

Фонд оешкан алты ел дәвамында, гомуми алганда, 768 гаиләгә (1312 бала) булыштык, 687 гаилә тотрыклылыкка ирешә, 2187 хатын-кыз бушлай белем алды. Барлыгы 5583 һөнәри ярдәм күрсәтелде, әмма башкарасы эшләребез бик күп әле.



Наталья ЖЕРЛИЦИНА, «Благие дела» («Игелекле эшләр») хәйрия фонды психологы

– Ире тарафыннан кыерсытылып, җәбер-золым күреп яшәгән хатын-кызның хәлен, аның кичерешләрен аңлау өчен әллә ни күп кирәкми. Йөзенә, күзләренә бер күтәрелеп карау да бик җитә. Изелеп яшәүче хатыннар үзгә бертөрле алар. Хатын-кызларның һәм ирләрнең тигез хокукы Төп законыбыз белән ныгытылган булуга да карамастан, гаиләдәге мондый хәлләргә «үз эшләре» дип карау һаман да дәвам итә. Әлеге проблеманың асылы балачакка барып тоташа. «Анам йорты» кризис үзәгенә килгән, төгәлрәк әйтсәк, качып килгән яшь әниләрнең барысының да язмышы бертөрле: ул ханымнар бәләкәйдән үк шуңа охшаш хәлләрне күргәннәр. Кемнеңдер әтисе әнисен кыйнаган йә ташлап чыгып киткән. Балага тиешле игътибар булмаган. Үсеп буй җиткән кыз бала, гадәттә, тормыш итәр өчен, үзе дә сизмәстән әтисенә охшаган кешене сайлый. Һәм бары да яңабаштан кабатлана. Шулай итеп, кыз сират күперен кат-кат кичәргә мәҗбүр була. Аларның кайберсе, әниләре кебек, золым корбаны булып бу мәхшәр белән килешеп яши. Килешергә теләмәгәннәре өйдән качып, безгә килә. Шундыйларга психологик ярдәм күрсәтәбез дә инде без. Алар үз-үзләренә ышанырлык, мөстәкыйль тормыш алып барырлык дәрәҗәгә ирешә. Эшкә урнаша, балаларын тәрбияли. Соңыннан кайсы белән генә сөйләшмә: «Үземнән канәгать», – диләр. Килеп туган мондый хәлдән чыгу юлы бер: йә син язмыш хуҗасы буласың, йә, килешеп, явызлыкка баш иеп яшисең. Ирләрнең төрлесе бар: кайсы психологик һәм әхлакый яктан чыгырдан чыгара, кайсы кул күтәрә. Бу очракта нидер көтү – үлемгә тиң. Андый кешедән тизрәк качарга кирәк. Кая булса да – дус кызыңа, кризис үзәгенә, әти-әниең янына... Авыр, әлбәттә. Әмма шунсыз булмый.

сөйләшәсең. Ни хакында сөйләшәсең?» – дип бәйләнеп торды. Әзрәк булса да безгә ярдәм итим, дип, әнинең Төркиягә эшкә киткән чагы. Сеңлемнең кияүгә чыгып, шәһәргә күченгән вакыты. Хәлләрен белешәсе килә, телефоным ватылды. Яңасына акча юк. Ремонтка бирерлек мөмкинлек тә юк. Кая килеп төртелмә – үтәлмәстәй стена. Шулай итеп, ирем белән икәүдән-икәү калдык. Мин – тулысынча аның хакимлегендә...

Көннәрдән бер көнне хастаханәгә килеп аудым. Эчкә җыелып килгән бөтен чир баш күтәрде: теземнән башлап күземә чаклы. Менә шунда гына гомеремнең тоткында узуын аңлый башладым. Нишлим мин? Балаларны нинди хәлгә куям? Күз алдында ярылып яткан чынбарлыкны ничек күрмәдем икән? Хәзер аңлыйм: психосоматика. Авыруыма иремнең исе дә китмәде. Аның өчен бар да яхшы иде. Кайчан һәм кайда нәрсә эшләргә тиешлегемне искәртеп, фәрман гына биреп торды. Балалар мәктәпкә, бакчага йөрмәсен – өйдә утырсыннар, өйдә укысыннар әнә. Миңа әнинең иске телефонын биргәннәр иде. Аны тавышсызга көйләп, яшереп куйдым. Ирем чыгып киткәч кенә әни белән сөйләшә идем. Ул кайтуга өйдә чит-ят кеше булырга тиеш түгел.

Ниһаять, 2019 елның февралендә, соңгы көчемне җыеп, качып киттем. Кулымда – документлар, кирәк-ярак, кием-салым тулы бер сумка... һәм өч бала. Яңа тормыш шулай башланды. Бөтенләй чит, яңа җирдә... Шәһәрдә! Аннан башка! Хәзер мин эшлим, фатир алып торам. Балалар мәктәпкә йөри. Олы кызыма – 14 яшь, малайга – 9, кече кызыма – 5 яшь. Малайда – церебраль паралич. Аллага шөкер, улыма операция ясадылар. Хәле рәтләнеп килә. Алда безне бик күп дәваланулар көтә. Әтисе ярдәм итәргә ашкынып тормый. Ул бүген ана капиталы акчасын да кертеп төзелгән йортта яшәп ята. Шулай да мин аннан котылуыма шат. Бөтен авырлыкларны күтәрергә риза, тик аның җәберләүләрен генә күрмәскә...

Юлия Шефер, 47 яшь: «Әти бит, ничек ышанмыйсың...»

«Оясында ни күрсә...» дигән мәкальне беләсез инде. Мин өч балалы гаиләдә үстем. Әти – Кемерово өлкәсенең Мариинск шәһәреннән, белеме буенча музыкант. Өстәвенә, спорт мастеры. Милициядә эшләп, полковник дәрәҗәсенә күтәрелгән. Әни – тумышы белән Казаннан. Дөньяның икесе ике читендә торган кешеләр, әйтүләренә караганда, яратышып өйләнешкәннәр. Без иркен яшәдек. Җәйләрен диңгезгә ял итәргә китә идек. Әмма гаиләдә тынычлык булмады. Гел тавыш, гел талаш, әти белән әнинең тату яшәгәнен хәтерләмим. Алар үсеп килүче өч баланың кичерешләрен дә санга сукмадылар. Көннәрдән бер көнне әти безне ташлап чыгып китте. «Урнашыйм да, кайтып алырмын», – диде. Ләкин шул китүдән юкка чыкты. Әнине «Ашыгыч ярдәм» машинасы белән хастаханәгә алып киттеләр. Хәле кинәт начарайды. Без – балалар – язмыш кочагында. Кайсыбыз – кайда. Миңа ул чакта 12 яшьләр тирәсе. Әти бер энемне үзе белән алып киткән иде – аны әти-әнисе тәрбиясенә биргән. Әни хастаханәдән чыккач, шактый вакыт тулай торакның 16 квадрат метрлы бүлмәсендә тордык. Әти безне пропискадан төшереп, өч бүлмәле фатирыбызны саткан да, өйләнеп җибәргән. Яңа тормыш башлаган, кыскасы. Ул безне урамда калдырып, үз рәхәтенә яшәде.

Хәзер үзем турында: авырлыкның ни икәнен балачактан ук татыдым. Иң мөһиме – без исән, иң куркынычы артта калды дип уйлый идем. Тик ялгышканмын. Күрәчәгем алда булган икән. Мәктәпне тәмамлап, педагогика көллиятенә укырга кердем. Балалар белән эшлисем килде. Спорт ярата идем. Волейбол, баскетбол минеке иде инде. Әни белән мөнәсәбәтләр киеренке булды. Ни өчендер ул миңа гел: «Әтиең кызы», – дип кабатлый иде. Мине яратмады, эшләрем белән кызыксынмады... Аңа барыбер иде. Хәтта дошманы итеп күрә иде. Мәктәптә укыганда бер малай белән таныштым. Әмма мине шундук урыныма утырт-

тылар: «Кем икәнеңне, нинди гаиләдән чыкканыңны бел! Син аңа тиң түгел!»

Кимсетүләр, үз якыннарың тарафынннан рәнҗетүләр, «сөйкемсез үрдәк баласы» хәлендә булулар чыгырдан чыгаргандырмы, бервакыт мин дүртенче кат тәрәзәсеннән ташландым. Үләсем килде. Кемгә кирәк соң мин? Хәтта әти-әнигә дә кирәк түгел. Үләрмен дә котылырмын, дигән идем. Юк, исән калдым. Хәтта бер мизгелдә теге дөньяда да булып алдым. Фәрештәләрне күрдем. Алар миңа: «Яшисең!» – диделәр. Хастаханәдә өч ай яттым. Умыртка сөягем, кул, аяклар сынган иде. «Син – инвалид, коляскага каласың», – диделәр. «Бала таба алмыйсың», – дип тә куркыттылар. Өч айда аякка бастым. Һөнәремне үзгәрттем. 17 яшемдә бер егет белән таныштым. Озак йөрмәдек, өйләнештек. Ярты ел да узмады, ирем һәлак булды. Авырга узып калган идем, улым туды.

Кемеровода читтән торып авыл хуҗалыгы институтының икътисад бүлеген тәмамладым. Актив идем. Волейболга йөрдем, ярышларда катнаштым. Үзәк сайлау комиссиясе рәисе булып ун ел тордым. 22 яшемдә икенче мәртәбә кияүгә чыктым. Барып чыкмады – өч елдан аерылыштык. Ул да әти шикелле эчә, көнли, кыйный иде. Институтны тәмамлагач, фермер хуҗалыгында бухгалтер булып эшли башладым. Шунда эшләүче тракторчы егет белән тагын бәхетемне сынап карарга булдым. Кызганыч, бу юлы да уңмадым. Бу кешенең үзенә файда китерер өчен генә өйләнгәнен аңладым. Өйләнгәндә үк бурычлы иде: кредиты, алиментлы... «Түз бераз, аякка басыйм», – дигән була иде. Булдыксыз, хатын җилкәсендә ята торган бер адәм булып чыкты ул. Түзә алмадым, баланы күтәрдем дә чыгып киттем. 2012 елны икенче балам туды. Яшь ярымда аны бакчага биреп, эшли башладым. Тик янә бәла... Мин эшләгән сөт эшкәртү заводы ябылды. Эшсез калдым. Ирем белән аерылгач, 2017 елда ана капиталына искереп беткән бәләкәй генә өй сатып алган идем. Әкренләп рәтләрмен, төзәтермен, дидем. Бертөрле уйлыйсың, икенче төрле килеп чыга икән ул. 2019 елны, һич көтмәгәндә, ничәмә-ничә елдан соң әти шалтыратты. 25 ел күрешмәгән, сөйләшеп аралашып тормаган әти! «Нигә шалтыратты икән?» дигән уй башка да килеп карамады. Каян телефонны тапкан?! Әни белән аралашмыйлар ич алар. Хәлемне сораштыра. «Начар, – дим, – эшем юк, аерылыштым, ирем алимент түләми. Утын белән җылытыла торган җимерек өйдә яшәп ятам».

Декабрьдә әти үзенә кунакка чакырды. Юлга акча җибәрде. Сөенгәнемне күрсәгез. Күкнең җиденче катында мин! Ниһаять, әтием мин барлыкны исенә төшерде бит. Аның янында торган ун көн әкияттәге сыман үтте. Әти белән үткәннәрне искә төшердек, иске фотографияләр карадык. Ул бик кайгыртучан тоелды. Югалып торуы өчен гафу үтенде, үкенде. Тормышыннан зарланып та алды. Хатыны үлгән, ике бала белән калган. Әти аларны берүзе тәрбияләп үстергән. Мин Себергә кайтып киткәч тә гел шалтыратып, хәлемне белешеп торды. «Сиңа булышасым килә», – диде. Әти бит, ничек ышанмыйсың! «Улым 1 нче сыйныфны тәмамлагач, синең янга – Казанга күчәм», – дип сүз бирдем. Ләкин ул ни өчендер ашыктырды. «Сиңа эш сөйләштем, тизрәк кайт!» – диде. Машинаны, булган бар мөлкәтне саттым да, иң кирәкле әйберләрне генә алып Казанга юнәлдем.

Бар да яхшы кебек иде. Баштарак әти үзен бик әйбәт тотты. Ул – дәрәҗәле эшләрдә эшләгән кеше. Аның дүртәр бүлмәле ике фатиры, ике машинасы, гаражлары, җир участоклары бар. Күченеп килгәндә ул миңа бер бүлмәле фатир алып бирәм, диде. Ышандым. Чит кешегә түгел, үз әтиемә ышандым. «Мин – полковник, сүзне җилгә очырмыйм», – дип кабатларга ярата бит. Озак та үтмәде, бөтен нәрсә үзгәрде дә куйды. Әти янына сөяркәсе килгән иде. Шул котыртыпмы, әти миңа бәйләнә башлады. Әнинең телефонын сорый бу. «Без аның белән аралашмыйбыз, ул мине дә яратмый», – дим. Бик каты эчкән иде. Бераз гына йоклап торды да, тагын мине талар-га тотынды. Сейфыннан пистолет тартып чыгарды да: «Син – аферистка», – дип, бала белән минем өскә килә башлады. Телефон белән курткаңы гына чак эләктереп, чыгып йөгердек. Шулай итеп, салкын март төнендә бала белән урамда калдык. Улына шалтыраттым. Ул берни белән дә ярдәм итә алмавын әйтте, ниндидер хостел телефонын бирде. Безне анда шәфкатьле бер ханым каршы алды. Документлар да сорап тормады, шундук урнаштырды. Ул мине тынычландырды. Нәрсә эшләргә, башны кая салырга белми торган чак бит. Полициягә барып булмый, уллары да шунда эшли. Әтинең дә танышлары белән дөнья тулган. Әйберләр, документлар, машина саткан акча анда калды. Алырга рөхсәт юк. Әти: «Полиция чакыртам, мошенница дип гариза язам», – дип куркыта. Дүрт көннән уллары сумканы китерде, тик анда машина акчасы юк иде. Соңгы акчамны алып калган. Аның каравы, кирәге чыгар дип, җыен иске-москы тутырган. Алтын бизәнү әйберләрем дә, энем Алмазның Туу һәм Үлү турындагы таныклыгы да юкка чыккан. Әтинең нигә мине искә төшерүен шунда гына аңладым. Баксаң, аңа энемнең таныклыгы кирәк булган. Алмаз төрмәдә утырып чыкты. Чыкты да асылынды. Әти белән әни аның хәтта соңгы васыятен дә үтәмәделәр: берсе дә аны җирләргә килмәде. Мин җирләдем. Алмаз аның улы булуы турындагы юлларны белешмәдән сызып ташлаган булып чыкты әти. Әти бит полициядә эшли, ә анда эшләүчеләрнең туганнары төрмәдә утырган булырга тиеш түгел. Ярамый! Дәрәҗәсен какшата. Улларына да җил тияргә мөмкин. Менә бит нинди рәхимсезлек...

Инде нишләргә? Кире кайта алмыйм. Акчам да, кайтыр урыным да юк. Мин бу хәлдән чыгу юлларын эзләргә керештем. Эзләнә торгач, «Благие дела» («Игелекле эшләр») хәйрия фондының телефонына юлыктым. Билгеләнгән вакытка фонд хезмәткәрләре белән очрашуга килдем. Булышты алар миңа. Җилкәмнән таулар төшкәндәй булды. Бүгенге көндә без бәхетле!

«АНА БУЛУ – ТИҢДӘШЕ БУЛМАГАН БЕР ХӨРМӘТТЕР»

Алсу
ЗАҺИДУЛЛИНА

Татарның бөек мәгърифәтчесе Ризаэтдин Фәхретдиннең бу сүзләренә искиткеч тирән мәгънә салынган. «Әйе, безнең халыкта һәрвакыт Ана булуга дан җырланган – күңел кылларын тибрәтерлек искиткеч җырлар, шигырьләр, мәкальләр иҗат ителгән. Кыз баланы кечкенәдән яратып, назлап, күз карасыдай саклап үстерергә тырышканнар – үсеп буйга җиткәч, Ана дигән бөек исемгә ирешәсе, нәсел дәвамчылары үстерәсе бар аның. Хатын-кыз сәламәтлеге – гаилә иминлегенең төп нигезе ул. Кызганыч, бүген күп кенә хатын-кызлар әни булу бәхетеннән, сәламәт бала табудан мәхрүм. Бу мәсьәләнең чишмә башы балачакка, яшүсмер елларга барып тоташа. Замана әлеге проблеманың сәбәпләрен фәнни яктан ачыклап, тәэсирен киметү, бала табучылар санын арттыруны таләп итә. Баланың табигатьтән бирелгән саулыгын саклап калырга, чарасын алдан күрергә кирәк. Мин моны төгәл беләм!» – медицина фәннәре докторы, профессор, Татарстан Фәннәр академиясе әгъза-корреспонденты, Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгының Идел буе федераль округы буенча балалар һәм яшүсмерләр гигиенасы баш белгече Эльмира МИНҺАҖЕВА белән тормышчан мәсьәләләрне ачыклыйбыз.

Уңыш сере – тамырларда

Эльмира Баку шәһәре үзәгендә офицер гаиләсендә туа. Җылы, кояшлы, җиләк-җимешле шәһәрне бераз вакыттан соң Германиянең урманлы, таулы Тюрингиясендә урнашкан Штайнхайд бистәсенә алыштыралар. Соңрак Лейпциг янәшәсендәге Брандис шәһәренә күченә гаилә. Әнә шулай берсе икенчесенә ялганып киткән көнчыгыш һәм көнбатыш традицияләре кызның холкында да чагылыш тапкан. Кешеләрне яратучы, ачык күңелле, һәрвакыт елмаеп торучы кызда төгәллек, таләпчәнлек, максатчанлык кебек сыйфатлар бергә үрелеп килгән.

– Бик бәхетле кешемен! Минем әти-әнием белән башкача мөмкин дә булмагандыр. Аларның исемнәренә генә игътибар итегез: Нурислам Гомәр улы – Ислам нуры һәм язмыш дигән мәгънәгә ия. Әнием Рәхимә Гашыйк кызы – рәхимле һәм мәхәббәтле дип тәрҗемә ителә, – дип елмая Эльмира Нурисламовна. – Әниемнең тамырлары – Актаныш районы Колын авылыннан, әтиемнеке – Әтнә янында урнашкан Казаклар авылыннан. Әти кайда гына хезмәт итсә дә, ялының бер өлешен һәрвакыт туган ягында үткәрә иде. Татар Швейцариясе дип аталырга хаклы булган үзенчәлекле, искиткеч матур туган ягыма мин кечкенәдән гашыйк. «Көч бирүче» урыным ул. Эш сөючән, рухи яктан бай, татар телен камил белгән кешеләр яши кече ватанымда. Ул җирлекләр тарихи яктан әле дә өйрәнелеп бетмәгән, дип саныйм. Кала-тау гына да ни тора бит! Мөмкинлек булган саен шул тауга килеп көч җыям, иркенлектә саф һава сулап ләззәт, сихәт алам. Казан ханнарының ата-бабалары яшәгән дип әйтәләр бу җирләрдә. Данлыклы кавем халыкны гыйлемгә, кул эшләренә өйрәткән, сәүдәгәрлеккә нигез салган. Шуңа күрә безнең якларны татар сәүдәгәрлеге, меценатлык, гыйлем бирү үзәге дип саныйлар. Заманның күп кенә билгеле шәхесләре, уңышлы эшмәкәрләре, сәясәтчеләре, республика җитәкчеләренең тамырлары бу якларга барып тоташа. Туган якларын үстерүдә зур көч куя алар. Түбән Бәрәскә авылының 1769 елгы тарихи мәчетен торгызу – моның ачык мисалы. Бу мәчеткә йөреп, ерак әби-бабаларым да белем алган. Ул замана өчен бик укымышлы, гыйлемле нәсел булган алар. Бабам Казанда сәүдәгәрлек белән кәсеп иткән, Сукно бистәсендә урнашкан тукыма кибетләре турында сөйли иде. Казаклар авылындагы балконлы йортыбызны бик яхшы хәтерлим. Бизәлеше буенча Олы Мәңгәрдәге Бакиров йортына охшаган иде ул. Бәләкәй чагымда балкон баскычлары буйлап төшкәндә үземне патшабикә итеп хис итә идем. Әбиемнең лапаста урнашкан бирнә сандыкларына исә чын-чынлап гашыйк булганымны хәтерлим.

Һәр кешенең ике канаты бар. Берсе – әти нәселе, икенчесе – әнинеке. Ике нәсел берләшүе нәтиҗәсендә туган яңа кеше шул нәсел

көчен барлап, аларга рәхмәтле булып яшәргә тиеш. Сез көчле татар халкы дәвамчылары дип, балаларга да әйтеп тору кирәк. Бу сүзләрне ишеткән баланың башы югары күтәрелә, күзләрендә горурлык чаткысы барлыкка килә, ул үзенең кем булуын аңлый башлый, нәсел җебен дәвам итәргә кирәклегенә төшенә. Болар, үз чиратында, баланы төп бурычына – ата-ана булуга этәрә. Күптән түгел генә кызым белән улым мине чын мәгънәсендә сөендереп, гаиләбезнең «нәсел мәчете» – Түбән Бәрәскә авылы иман йорты янында гына ике җир биләмәсе сатып алдылар. Шушы җирдә йорт салып, туган ягыбызга мәхәббәт хисләребезне киләчәк буынга күчерсеннәр дип телим.

Үткәннәргә хөрмәт белән караучы, нәсел җебен белүче, туган җиренең тарихын барлаучы, аны үстерүдә көч куючы һәркемгә Аллаһ үзе ярдәм итә. Мин моңа күптән инандым. Республикабыз җитәкчеләре – моның иң күркәм үрнәге, – дип, фикерләре белән бүлеште Эльмира Минһаҗева.

Галимә

– Гаиләбез белән Германиядән туган якларга күчеп кайткач, Казанның 111 нче мәктәбенә укырга кердем. Яшүсмерләр «слеңгын» аңларга тырышканымны хәтерлим. Куртканы «анарак» дип әйтмәскә өйрәнергә, мәктәптә укучыларның күп булуына ияләшергә туры килде. Мәктәп линейкасында барлык укучылар алдында шигырь сөйләргә кушканнарын хәтерлим. Шулкадәр каушадым – авызымны ачам, бер сүз дә әйтә алмыйм. Ләкин беренче уку елында ук биология укытучысы миндә үз фәне аркылы чыгыш ясауга мәхәббәт уятты. Суганның



Мәктәпне тәмамлаганнан соң финанс-икътисад институтына керергә әзерләнгән **кыз, көтмәгәндә, фикерен үзгәртә.**

Фото: Анна Арахамия

Кыз баланың организмы ачылмаган чәчәк кебек – саклауга мохтаҗ. Аңа табигый рәвештә ачылырга ирек бирергә кирәк.

файдасына багышланган докладымны ничек тәмләп сөйләгәнемне әле дә хәтерлим. Берьюлы укытучы да, табиб та булсаң иде ул, дип уйлап куйган идем шул чакта. Шөкер, балачак хыялым тулысынча тормышка ашты, – дип искә ала Эльмира Нурислам кызы.

Мәктәпне тәмамлаганнан соң, финанс-икътисад институтына керергә әзерләнгән кыз, көтмәгәндә, фикерен үзгәртә.

– Имтихан бирергә ике атна кала, медицина юлын сайладым. Очраклылыкмы? Түгелдер... Тоемлау хисем еш кына язмышымда хәлиткеч юнәлеш алырга ярдәм итә миңа. Документлар тапшырырга үзем генә бардым. «Кайсы факультетка бирәсез?» – дип сорыйлар. Бу турыда уйлап та караганым юк иде, экономист булырга тиешле кеше бит. Ниндиләр бар соң, дип кызыксынам. Дәвалау эше, педиатрия, санитария-гигиена, стоматология факультеты, диләр. Дулкынланудан санитария сүзен башкача аңлаганмын: санаторийда эшләп, никадәр кешенең сәламәтлеген саклап калып булыр иде дип уйлап куйганымны хәтерлим. Чынлыкта, бөтенләй башка юнәлеш булуын соңыннан гына аңладым, ләкин беркайчан да үкенмәдем.

«Казан медицина институтында гигиена белгечлеген, профилактик медицинаны, сәламәтлек саклау даирәсен оештыру буенча Россиянең иң көчле профессорлары кул астында белем алдым, алар мәктәбен уздым», – дип горурлана галимә. Һәм үзен бик бәхетле саный. Бөтен гомерен профилактик медицинага багышлаган Эльмира ханым. Укуын тәмамлаганнан соң, 1986 елда үзе дә остазлык юлында беренче адымнарын ясый – Казан медицина университеты студентларын балалар гигиенасына өйрәтә, фәнни-тикшеренүләр белән шөгыльләнә. 1993 елда яклаган кандидатлык, 2002 елдагы докторлык диссертацияләрен булачак әниләр – кызлар сәламәтлеген саклауга багышлый. Фәнни эшләрендә төрле авыруларга прогноз бирү һәм алдан кисәтү эшендә цифрлы технологияләр куллануның әһәмиятен шул елларда ук билгеләп үтә. Эльмира Нурисламовна салган юлдан галимәнең 11 укучысы – фән кандидатлары һәм докторлары да үткән инде.

– Республика балалар клиник хастаханәсе баш табибы Айрат Зыятдинов, күзләр дәвалау клиникасы баш табибы Софья Шиллер, А. И. Бурназян исемендәге федераль биофизик үзәгендә хезмәт куючы танылган невролог Миләүшә Йосыпова, стоматология клиникасы баш табибы Эльвира Зарипова һәм башка укучыларым белән горурланам, – ди галимә. – Барысы да хезмәт юлларында уңышка ирешкән шәхесләр.

Хатын-кыз сәламәтлеге – уалучан бәллүр чәчәк

12 ел дәвамында Татарстан Сәламәтлек саклау министрлыгының баш белгече булып торган тәҗрибәле галимә бүген Россия сәламәтлек саклау министрлыгының Идел буе федераль округы буенча балалар һәм яшүсмерләр гигиенасы баш белгече вазыйфасын башкара. Укучы балаларга хас авырулар, аларның барлыкка килү сәбәпләре хакында никадәр бәһасез гыйлем туплаганы үзенә генә мәгълүм. Укучы кызларның сәламәтлегенә йогынты ясауда дөрес туклануның гына түгел, дөрес утыру, үзенчәлекле физик күнегүләр ясауга кадәр тикшереп, фәнни яктан нигезле хезмәт куйган ул. Җенси тормыш белән иртә яши башлауның куркыныч якларын да төптән өйрәнеп ачыклаган галимә.

– Республика мәктәпләрендә «Репродуктив сайлау» программасын кертүгә каршы чыгып, үз фикеремне дәлилләргә туры килгән иде. Катлаулы чор булды ул минем өчен. Рәсми рәвештә «абортларга каршы программа» дип аталса да, белгеч буларак, бу программаның яшь буын өчен ни дәрәҗәдә куркыныч икәнен миннән дә яхшы белүче булды микән... Нигезендә чит ил гормональ контрацептивларын пропагандалау ятканын тиз аңладым – телевидениедән чыгыш ясадым, фикердәшләр эзләдем. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының «Мәрхәмәт» хатын-кыз депутатлар берләшмәсе дә теләктәшлек күрсәтте. Шөкер, программа мәктәпләргә кертелмәде – меңләгән кыз баланың сәламәтлеген саклап кала алдык. Ләкин кайбер хатын-кызлар консультациясендә әле дә пропаганда барганын беләм, кыз баласы булган әти-әниләрне бу хакта кисәтәсем килә. Кыз баланың организмы ачылмаган чәчәк кебек – саклауга мохтаҗ. Аңа табигый рәвештә ачылырга ирек бирергә кирәк. Шөкер, хәзер бик күп укучы кызлар өчен сафлык – гадәти әйбер. Ләкин шулай да гаилә кыйммәтләрен пропагандалауда, ана булуның изге бурычын бала күңеленә салуда әти-әниләрнең, укытучыларның, табибларның бердәм хезмәте генә нәтиҗәле булачак.

Табигый сәламәтлек өчен көрәштә битараф була белмәгән галимәнең җиңеп чыгуын медицина өлкәсендә хезмәт итүче кайберәүләр җиңел генә оныта алмый, әлбәттә. Моны аңлап, тоеп торган Эльмира ханым хезмәт юлын Россия регионнарында, чит илдә дәвам итәргә була. Россия Фәннәр академиясе академигы, Н. А. Семашко исемендәге Иҗтимагый сәламәтлек милли фәнни-тикшеренү институты җитәкчесе Рамил Хәбриев галимәне киңәшче итеп үзенә чакырып ала. Ике ел-

дан әлеге институтның баш фәнни хезмәткәре һәм Н. И. Пирогов исемендәге Россия фәнни-тикшеренү медицина университеты профессоры булуга ирешә Эльмира Минһаҗева.

Россия Президенты каршындагы бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Анна Кузнецова Эльмира Нурисламовнаның гаилә нигезләре сәясәтен хуплый. Бер ел дәвамында башында Анна Кузнецова торган Иҗтимагый советның балалар сәламәтлеге саклау буенча эшче төркемен җитәкли галимә. «Россия нутрициологлар, диетологлар һәм азык-төлек индустриясе союзы» профессиональ ассоциациясе Генераль сәркатибе итеп сайланганнан соң, әлеге төркемнең әгъзасы буларак эшен дәвам итә.

Мәктәпләр һәм укучы балалар арасында алып барылган медик-социаль һәм психологик мониторингка цифрлы технологияләр кертергә кирәк дип саный Эльмира ханым. Укучылар сәламәтлеге һәм тәрбиясе өчен җаваплы булучыларга да шул фикерне ирештерергә тели.

– Бу программалар гамәлгә кертелгән регионнар бар, алар тәҗрибәсенә таянып, шәхси мәгълүматларны саклап башкарырга кирәк бу эшләрне. Шундый заманча ысуллар ярдәмендә генә укучылар сәламәтлеген саклау буенча нәтиҗә бирә торган эшләрне тиешенчә бәяләп була. Республикада мине ишетерләр дип уйлыйм.

Татарстанның мөмкин кадәр күбрәк азык-төлек предприятиеләрен Россия нутрициологлар, диетологлар һәм азык-төлек индустриясенә тоташтырырга тели Эльмира Нурисламовна. Бу аларга технологик мәсьәләләрне хәл итүдә генә түгел, продукцияне урнаштыруда да зур ярдәм булыр иде.

Галимә үткән юлны тагын бер кат күз алдыннан үткәрәм һәм аның беренче чиратта хатын-кыз булуына инанам. «Хатын-кыз бәхете – әни булуда», – ди әңгәмәдәшем. Галимәнең бу сүзләренә әниләрчә кайгырту, күңел җылылыгы салынган. Туган җиренә мәхәббәтен, тугрылыгын эшләре белән дәлилли белүче чын татар хатыны – галимә ул.

БЕЛЕШМӘ

Түбән Бәрәскә авылы мәчете Татарстанда авыл җирлегендә урнашкан иң борынгы мәчет. Ибраһим Борнаев исемле сәүдәгәр аны 1769 елда Екатерина II дән рөхсәт алып, үз акчасына төзеткән. 1930 елда мәчет ябылып, 2010 елга кадәр мәдәният йорты итеп файдаланылган. 2020 елның декабрендә төзекләндерелгән мәчет Татарстан Президенты катнашында тантаналы рәвештә яңадан ачылган.



«ИҖАТЫМНЫ ВАКЛЫЙСЫМ КИЛМИ...»

Аның музыкасын тыңлаганда күз алдына океан килә. Әле офыккача тынып калган су өсте, әле ярсу дулкыннар шаулый. Бөтереп ала да, әллә кайларга алып китә – ул кечкенә сәяхәттән кайтасы килми... Бүгенге татар музыка сәнгатенең иң өметле яшь композиторларның берсе, виртуоз пианист Миләүшә ХӘЙРУЛЛИНА морза кызлары кебек: салмак хәрәкәтләр, тыныч-тыйнак елмаю, үзенә бер әдәплелек һәм зыялылык. Аның җырлары да үзе кебек затлы: «Синсез яшәргә», «Кем идек?», «Ак фәрештә», «Мин Казанда калам»...



Миләүшә, син 6 яшьтән музыка яза башлагансың. Талант Ходайдан бирелә, диләр. Килешәсеңме?

– 5 яшемдә әни мине музыка мәктәбенә алып килде. Гаҗәп тә түгел, гаиләбез музыка җанлы: әни музыка мәктәбендә укыта, әти экономист булса да, үзлегеннән баянда уйнарга өйрәнде. Оста баянчы иде ул. Музыка буенча китмәгәненә гомере буе үкенеп яшәде. Табигатьтән килгән сәләттер инде ул миндә. Кечкенә чакта ук күзләрем янып тора иде. Мәктәптән өйгә йөгереп кайтам да, киемнәремне, перчаткаларымны салмыйча, пианино артына утырам. Әнием дә бик таләпчән булды. Гаиләдә бердәнбер бала булсам да, эш беткәч кенә уйнарга ярый дип үстерделәр мине. Ел буена музыка белән бер генә көн шөгыльләнми идем. Җәен әбигә Оренбургка кунакка кайткач, Коръән ашы уздыралар. Әби аңа туйга әзерләнгән кебек әзерләнә. Менә шул көнне генә пианино артына утырмый идем. Әни минем сәләтемне күреп шулай таләпчән булгандыр. «Һөнәрне сайлыйсың икән, аңа җитди карарга, бу өлкәдә әзерлекле, камил булырга тиешсең», – ди иде. Аңа рәхмәтлемен хәзер. 6 яшемдә беренче музыкаль пьесаларымны яздым. Көй язу – әтиемнән бирелгән сәләт дип уйлыйм.

Татар музыка сәнгатенә мәхәббәт кайчан уянды?

– Музыка мәктәбендә татар классик композиторларының әсәрләрен уйный идек. Алар исемендәге төрле конкурсларда катнаштык. Ә талантлы балалар өчен махсус мәктәпне тәмамлап, Н. Җиһанов исемендәге Казан дәүләт консерваториясендә укыганда чын мәгънәсендә татар музыкасына бирелдем. Моның өчен «Калеб» яңа буын җыенына, җитәкчесе Гүзәл Сәгыйтовага рәхмәтлемен. Ул мине бу сихри дөньяга чакырып китерде.

Татар сәнгатендә сез, бер төркем иҗади татар яшьләре, бүген үз юлыгызны саласыз. Сез башка: креатив, кыю, иҗатта янасыз, шул рәвешле татар мәдәниятенә яңа сулыш өрәсез. Бергәләп иҗат иткән җырларыгыз да үзенчәлекле: аерым дөнья кебек.

– Җыр язганда шагыйрь, музыкант һәм җырчының бер дулкында эшләве мөһим. «Безнең җыр» лабораториясе яшьләрне бер мәйданга җыйды. Шагыйрә Гөлүсә Батталова белән мин шунда таныштым. Аның белән бергә җырлар иҗат иттек. Йолдыз, Рүзәл Мөхәммәтшин, Луиза Янсуар, Эльмира Җәлилова белән төрле иҗади проектлар очраштырды.

Эльмир Низамов белән икегез – иң популяр яшь татар композиторлары. Көндәшлек юкмы?

– Юк, иҗатта көндәшлек яратмыйм. Эльмир Җәүдәтович консерваториядә безнең педагог иде, мин аны иҗатташ дустым дип кабул итәм.

Бер әңгәмәңдә: «Композитор – интеллектуаль профессия, хисләргә артык бирелергә ярамый», – дигәнсең. Иҗат итүче хис кешесе түгелме?

– Иҗатта режиссер кебек бөтен картинаны күрә белергә, киңрәк уйларга кирәк. Классикларны укыган саен, яңалык ачасың. Музыка да тыңлаган саен яңача ачылсын.

Димәк, музыка синең өчен логик мәсьәлә кебек. Мин дөрес аңлыйммы?

– Юк, миндә дә хисләр бар. Мин бит хатын-кыз. (*Көлә.*) Әмма хатын-кызда бераз гына ирләр аңы бар икән, шәп инде ул.

Миләүшә, син әле спектакльләргә музыка язасың: «Тапшырыл...ган хатлар», «Җәүдәт белән Зөбәрҗәт», «Кәҗүл читек», «Ак чәчәкләр кебек...»...

– Музыка – спектакльнең аерылгысыз бер өлеше, әмма, кызганыч, ул лаеклы бәяләнми кебек. Ул да – драматургия. Спектакльләргә музыка язу, әлбәттә, авыррак. Анда бар нәрсәне күздә тотып иҗат итәсең, хәтта рольне уйнаган актерны да. Шуңа да актерларның: «Музыкагыз уйнарга ярдәм итте», – диюе минем өчен зур комплимент.

Интеллектуаль иҗатны, кызганыч, киң масса кабул итми, чөнки аны аңларлык дәрәҗәдә үсәргә кирәк дип уйлыйм. Ни дисәк тә, гади тамашачы попсаны якын итә. Шул юнәлештә иҗат итү теләге юкмы?

– Юк дип тә әйтмим, язарга ашкынып та тормыйм. Экспериментлар кирәктер ул, әмма музыкамның очсызлануын, түбән, стилен югалуын теләмим. Поп-музыка да – җитди жанр. Ике нота арасында адашып йөреп кенә музыка язасың икән, ул куыкка әйләнә дә куя.

Акча культы заманында иҗат дип яшәү авырдыр?

– Беркайчан да музыкам керем китерер дип уйламадым. Мин – идея кешесе. Идея ошамый икән, нинди генә зур гонорарлар вәгъдә итсәләр дә, алынмаячакмын. Иҗатны вакларга ярамый, аны сакларга кирәк.

Син Кави Нәҗми турында опера яздың. Аның язмышы нинди?

– Ул язылып бетте, әмма әле дә яңа штрихлар өстим. Кави Нәҗми белән Сәрвәр Әдһәмова мәхәббәте турында гына да түгел әсәр. Тирәнрәк әйберләрне колачлый: халык эпопеясы, репрессия, шул чор татар язучылары... Операны зур сәхнәгә чыгару – минем хыялым.

Текст: Чулпан ГАЛИӘХМӘТОВА.
Фото: Анна АРАХАМИЯ. Видео: Фәнис САДЫЙКОВ.
Видеоны карар өчен смартфонның камерасын QR-кодка якынайтыгыз.





«АТ ДУХТЫРЫ»



Алсу ШАКИРОВА

Вакытны ярты гасыр артка чигерсәк, Казан ипподромы баш табибы Гөлнур Миндубаеваны халык үз итеп «ат духтыры» дип йөртер иде. Татар халкы гомергә хайваннар табибын шулай атаган. Малкайларга электән мөкиббән киткән бабаларыбыз өчен йортта төп хайван ат булгангадыр, мөгаен... Бу мөнәсәбәтләрне язып, аңлатып бирү өчен каләм көченең куәте генә җитмәс! Ә менә Гөлнур Бари кызына каян килгән атларга карата мәхәббәт? Ул үзе дә бу сорауга җавап таба алмый. Әйе, шәһәр кызына бөтенләй хас булмаган һөнәр.

Ат исә тагын да сизгер! Табиб янына алып баруларын күптән аңлап алган инде ул...

Ат җене

Апостол исемле токымлы ат дәвалау башланганын сабыр гына көтеп тора. Гөлнур ханым, алты шприц дару тотып, аның янына килеп басты да: «Улым, сабыр...» – диде. Күзгә карап аңлаштылар. Уң аягына өч укол кадаганда түзеп басып торган чабышкы ат, сул якка күчкәч, тыпырчына башлады. «Бетә, өчәү генә калды», – ди табиб. Энәне кадап куя да, даруны салганчы кулы белән атның аягына йомшак кына суккалап, авыртуын баса. Арт аягын җиргә тидерер-тидермәс басып торган ат менә тибеп җибәрер кебек. «Берәү генә калды, улым. Башка тимим...» – колакка ятышлы сүзләр янәдән Апостолның ярсуын баса. Ярый, дигән кебек, ат аягын җиргә куя.

– Казан урамнары буйлап җигүле атлар узып китсә, шулардан күз алмыйча, әсәренеп карап тора идем бәләкәй вакытымда, – ди табиб. Әмма мәктәптә язган иншаларында «Ветеринар булам!» дип язганда да атларны күз алдына китермәгән әле ул. Этләр, мәчеләрне дәвалыйм дип кенә хыялланган.

Ләкин Гөлнурның йөрәгенә атлар барыбер тынгылык бирми. Казан ипподромында атлар белән шөгыльләнү буенча секция барлыгын ишетүгә, шунда юнәлә. Әтиәнисе җитәкләп йөртүчеләрдән булмый ул – үзе йөри. Алар исә кызларының теләгенә каршы килми. Күрше апасы гына: «Нигә кирәк ул сиңа, атка атланып, кәкре аяклы буласың киләмени?» – дип аптырата. Ни кызганыч, Гөлнур секциягә язылa алмый, төркем тупланган, җыелу беткән була.

«Ат җене» дигәннәре Гөлнурга ни арада кагылып өлгергәндер... Үзен атлар янәшәсендә күргән кыз хыялыннан тайпылмый, үз теләге белән ипподромның ат абзарына эшкә килә. Эшкә дисәң, хәтере калыр. Гөлнур кебек кызларны хезмәткәргә санамаганнар да (әйе, күпчелек кызлар килгән эшләргә). Аларга ат абзарын җыештыру, сирәк булса да, атларның үзләрен чистарту кебек эшләрне тапшырганнар.

– Беренче атымның кушаматы Резвый иде. Ипподромда көн саен көтеп торучы «үз» атым булуы минем өчен никадәр сөенеч булганын белсәгез икән! Сынаулар өчен җибәрелгән атлар ипподромга яшь ярым-ике яшьлек вакытта эләгәләр. Аларны йөрергә, җайдакны йөртергә өйрәтәләр, качалкага – ике тәгәрмәчле арбага ияләштерәләр, ярышларга әзерлиләр. Миңа да Резвыйны өйрәтергә рөхсәт бирә башладылар, ат белән сынауларда катнашырга туры килде хәтта. Мәктәпне тәмамлагач, укырга кая керергә дигән сорау тормый иде инде минем алда.

Чемпионнар арасында

Хорезм исемле токымлы атны утардан алып чыгалар. Утыз метр ераклыкта атлаучы пациентының халәтен шундук сизде Гөлнур Бариевна. Ат исә тагын да сизгер! Табиб янына алып баруларын күптән аңлап алган инде ул, куркуы йөзенә чыккан: күзләрен зур ачып, бау артыннан сөйрәлеп кенә атлый. Көчле авырудан соң аякка баскан ат уколлардан куркып калган. Тиз аңлаштылар үзе. «Мин сиңа тимим, курәсеңме, кулларым буш», – дип, кулын сузды Гөлнур ханым. Йомшак борынын уч төбенә салып иснәгәч кенә Хорезм тынычланды.

Студент булгач та атлар янына йөрүеннән туктамый булачак ветеринар. Казан шәһәренең элеккеге ипподромына эшкә килгәндә яңасының әле котлованнары гына казылып куелган була. Аның проектын әзерләгән вакытта ук архитекторлар Гөлнур Бари кызы белән фикер алышалар, киңәшләрен исәптә тотып эшлиләр. Яшьтән атлар белән бергә үскән белгеч, аларга уңайлы булсын өчен, абзарларны ничек төзергә кирәклеген башкалардан яхшырак аңлый. Әйтик, атлар үзара аралашсын өчен, абзар араларын тоташ биек диварлар белән бүләргә ярамаганын төзүчеләр каян белсен?! Ветеринария клиникасында кайда нәрсә торырга тиешлеген, ничек урнашырга кирәклеген дә үзләре әйтәләр табиблар. Һәрнәрсә уйланып, уңайлы итеп эшләнә.

– Россиянең иң яхшы ипподромы Казанда урнашкан, безнеке Европада да иң яхшылардан, – дип бәяли Гөлнур Миндубаева эш биләмәләрен. Чагыштырырлыгы бар: чит илгә барып, тәҗрибә туплап та кайткан ул. Соңрак алардагы эш рәвешен үзебезгә яраклаштырып, «татарстанчалатып» куллана башлаганнар.

Ат абзарлары буйлап берсеннәнберсе матур, озын торыклы төрле токым атлары тезелгән. Казан ипподромында республиканың төрле почмакларыннан килгән чабыш атлары гына түгел, күрше регион кунаклары да байтак. Башкортстан, Пенза, Самара, Саратов шәһәрләреннән атларны бирегә нәкъ менә квалификацияле көчле персонал булганга алып киләләр дә инде. Атларның күпчелеге ярыш сезонында табиблар, тренерлар тәрбиясендә яши биредә. Утарлар арасында йөргән көйгә дә бик күп мәсьәләләрне чишә Гөлнур Бари кызы. Телефоннан киңәшләрен бирә, бригадирлардан атларның хәлләрен белешә, сорауларга җавап таба. Бер караштан да пациентларының хәлен билгели ала инде ул. Бу – осталыкның тагын бер билгесе.

– Гади кеше, иң беренче чиратта, атның матурлыгына, төз гәүдәсенә, тулып торган күзләренә карап соклана. Мин исә бу матурлыкка соңыннан гына игътибар итәм. Күзләр иң элек атның тышкы яктан да билгеләп була торган җитешсезлекләрен күреп ала, беренчел «диагноз» куела. Бу – һөнәремнең бер үзенчәлеге.

Закат исемле ат утарыннан башын чыгарып, безне күзәтә.

Фото: Анна Арахамия

Шуннан соң атны кабат аягына бастыра алмыйлар. Ә аннарымы? Анысын хуҗасы хәл итә...



31 август – ветеринария хезмәткәрләре көне

Татарстанда нибары **24** хатын-кыз ат табибы бар

Республикада барлыгы **20913** ат исәпләнә

Каршында – әтисе, янында – абыйсы. Кайбер атларның ишегенә тасмалар – ярышларда җиңүне аңлаткан тамга элеп куйганнар. Малкайлар үзләре аңлап бетерми, әлбәттә, бу дәрәҗәне. Аполлон җае чыккан саен шул тасманы чәйнәргә тырыша әнә. Һәр ике атның берсе чемпион монда. Спортчы атлар дәвалауның рәхәте дә, михнәте дә бергә Гөлнур Бариевна өчен...

Язылмаган законнар

Чабышларда катнашучы атларда җәрәхәтләр башкаларныкыннан күбрәк була. Спортның язылмаган законы шундый. Казанда узган чабышларның берсендә токымлы ат тирән җәрәхәт ала. Сынган аякка тиешле процедуралар ясап, беркетеп куялар. Ләкин зарарланган аягына баса алмаган атның бөтен гәүдә авырлыгы калган өч аякка төшә. Табигать үзенекен ала – инде авыруны җиңәбез дигәндә генә, ай ярым йөргәннән соң, «ламинит» дигән тояк авыруыннан ат егыла. Шуннан соң кабат аягына бастыра алмыйлар. Ә аннарымы? Анысын хуҗасы хәл итә...

Эре хайваннар белән эшләүнең авырлыклары бихисап әле анын. Җәрәхәт алган атка УЗИ, рентген ясар өчен дә никадәр хезмәт куярга кирәк. Атларны йоклатып, өстәлгә менгереп салу җиңелләрдән түгел, моны эшләгән кеше генә аңлый. Кайвакыт атларның гәүдә зурлыгы аркасында реабилитация үткәрү дә мөмкин түгел. Болай да арзан булмаган затлы чабышкы токымнар тоткан хуҗа җилкәсенә матди яктан күтәрә алмаслык чыгымга әйләнә реабилитация. Атның гомерен хәл иткәндә менә шундый тормышчан мәсьәләләр дә хәлиткеч роль уйный. Ә табиб өчен алар барысы да бала кебек...

– Кызганыч, ат өчен аяныч тәмамлана торган җәрәхәтләр дә булгалый. Вакытны күпме генә сузсаң да, ул барыбер газап чигеп, тилмереп вафат булачак. Кайсы балаңны ныграк яратасың дигән сорауга әни кеше ничек җавап биргәнен ишеткәнегез бармы? «Юлга чыкканын – кайтып кергәнче яратам, бәләкәен – үскәнче. Авырганын – савыкканчы», – дип җавап биргән ул. Авырып яткан ат аягына басканчы барлык көчемне, игътибарымны биреп карәшәм. Җәрәхәт белән никадәр озаграк тартышсаң, шулкадәр ныграк ияләшәсең атка. Һәрвакытта да уңыш безнең якта булмый. Андый вакытларда бердәнбер мәрхәмәтле юл – атны мәңгелек йокыга талдыру. Минем өчен бу һәрвакыт фаҗига...

Төнлә эштән килеп ирешкән телефон шалтыравы да гадәти күренеш ат табибына. Димәк, кайсынадыр ярдәм кирәк. Ипподромда атларны тәүлек буе карыйлар, уяу торалар. Төнге каравылчы абзарлар буйлап йөргәндә авырый башлаган атны сизеп алып, шундук Гөлнур Бариевнага шалтырата.

– Авырган ат тоягы белән җир казый башлый, ятып ауный, бер яктан икенче якка әйләнеп тәгәри. Моңа юл куймаска кирәк, эчәгеләре борылу куркынычы бар. Эч куышлыгы авыртуыннан җәфа чиккән бер атыбызны 12 тәүлек буе чиратлап сакладык. Шундый авыр очраклардан атны алып кала алсам, ниндидер әйтеп бетермәслек җиңеллек, канәгатьлек кичерәм.

Ләкин озакка түгел... Авырган ат өчен тәүлекнең көне дә, төне дә юк. Авырлыгы да шундадыр. Ат хайваны ялгыш кына аякка басса да, сындырырлык итеп баса. Махсус китереп тибүләрне, тәүлек буе эшләүләрне исәпкә алсак...

– Ардыра... Кайвакыт, заводтагы кебек, станокны сүндереп өйгә кайтып китәсе килә. Ләкин минем эш – бетми торганнардан. Моны аңлап, юанычны тагын шул атларның үзләреннән табам. Мин – аларга, алар миңа бик кирәк!

ГАЙБӘТТӘН КУРКЫРГА КИРӘКМЕ?



Марат КӘБИРОВ,
язучы

Минем хакта гайбәт сөйләгәннәрен яратам.

Ниндидер очрашуда яки концертта чыгыш ясарга туры килә. Бу хакта мин инде күптән оныткан булырга мөмкин. Тик гайбәт онытмый. Ул ниндидер дустыңның теле белән болай ди:

– Безнең тарафларга да килгәнсең икән...

– Каян белдең?

– Әлләкем генә сөйләде инде... «Дустың да чыгыш ясады, бер бөртек чәче тырпаеп тора иде...» – дип. Әллә чәчең коелып бетте микән дип тә уйлаган идем, әле Аллага шөкер икән.

Аның сүзенә ияреп мин дә шөкер итәм һәм күзгә төшеп торган чәчләрне фырт кына артка чөеп җибәрәм. Рәхәт. Яратам гайбәт сөйләгәннәрен.

Яратмый да булмый. Чөнки сөйләүчеләрнең авызын тегеп куя алмыйсың, ә үзең туктата алмаган нәрсәне кабул итәргә туры килә. Кабул итү генә җитми, аны яратырга кирәк. Шул гайбәтчеләргә сөйләр өчен, әледән-әле сәбәп биреп торырга. Ни генә әйтсәң дә, гайбәт сөйләү дә бер эш, бер шөгыль, үзенә күрә хезмәт бит инде. Ә кешенең хезмәтен хөрмәт итәргә кирәк.

Җәй авылга кайткач, гадәттә, яланаяк йөрим. Якын-тирәдә генә түгел, авылның теге очындагы дуслар янына да шулай чыгам. Ләкин анда барып җиткәнче, Казаннан хатын шалтырата:

– Синең турында: «Исерек бугай ул, урамнан яланаяк китеп бара иде», – дип ишеттем...

Көлешәбез. Моның ишене аның да беренче ишетүе түгел. Авыл кешеләрен дә аңлыйм инде. Чәчләре чаларып бара торган ирнең урам буйлап ялан тәпи китеп баруы сәер күренәдер.

Ну, һичьюгында, берәр сәгать күтәргә мөмкин бит инде. Гади генә мантыйк буенча да, кеше авылга кайтып дусты белән очрашкач, берәр рүмкә чәкәштерергә мөмкин. Вәт, аз гына кӧтсәләр, бу гайбәт түгел, ә эсвижжи яңалык булыр иде.

Ләкин яңалык болай тиз таралмас иде. Ә гайбәт тарала.

Мин моның серен аңлый алмыйм. Берәрсе көне буе капка төбендә синең яланаяк узып киткәнне көтеп утырмыйдыр бит инде. Хәтта шулай утырса да... Тиз генә берничә кешегә телефоннан шалтыратамы ул? Тегеләре тагын ахирәтләренә шалтыратамы? Үземне алар урынына куеп карыйм да, берни аңлый алмыйм. Мин, мәсәлән, шалтыратмас идем... Димәк, гайбәт йөртү өчен аерым бер сәләт, кызыксынучанлык, гражданлык активлыгы, оперативлык һәм тагын әллә нәрсәләр кирәк. Шундый талант ияләрен ничек яратмыйсың инде!

Еш кына хәлең ничек дип сорыйлар. Хәл төрлечә була. Кайчагында бөтен нәрсәне ачып салып сөйләшәсе, хәлне сораучы булганда бөтен күңелне бушатасы килә. Тик ирендерә.

Вәт, син үз хәлең турында сөйләргә дә иренәсең. Ә гайбәтче иренми. Ул хәтта ерактан гына күреп калган кеше (ә бу очракта син) турында сөйли. Бушка сөйли, бер тиен таләп итмичә. Бер генә кешегә дә түгел... Күз кырые белән генә күргәнен, колак чите белән генә ишеткәнен читтә калдырмый.

Ә нинди фантазия! Ул гайбәтләргә караганда, мин инде әллә ничәнче хатын белән яшим, балаларым бөтен дөнья буйлап таралган, дөньяның бөтен аракысын мин генә эчеп бетергәнмен, бөтен җирдә блат иметь итәм, әллә кайларда әллә нәрсәләрем бар... Кайчагында шулхәтле җентекле итеп сөйләп җибәрәләр – чынлап та шулай микән әллә дип, үзем дә шикләнеп куям.

Теләсә кем гайбәтче була алмыйдыр, моның өчен аерым талант кирәктер. Ә талант иясе яратуга һәрчак лаек. Тик бер нәрсә бар. Ул гайбәтләрне патша да, ниндидер өлкәдәге бик уңышлы башка кешеләр дә таратмый. Миннән дә гадирәк, миннән дә ямьсезрәк, миннән дә булдыксызрак кешеләр тарата. Алар шулкадәр күп микәнни соң? Күптер шул. Һәм бу да алар файдасына. Күпчелек һәрчак хаклы ич.

Әгәр синең хакта беркайчан да гайбәт сөйләмәгәннәр икән, димәк, син әле кеше түгел, ә күпчелекнең бер өлеше генә.

КҮҢЕЛ ҖЫРЛЫЙ!

– Нишләп йөрисең анда вакыт уздырып? Бер сәгать барасың, шуның кадәр үк кайтасың...

– Рәхәтләндереп бакчаңда эшлә...

– Оныкларыңны кара...

Гөлчәчәк ханымга мондый киңәшләрне бирүчеләр гел табылып тора. Аларны елмаеп кына тыңларга күптән өйрәнгән инде ул. Башкаларныкы кебек, аның да бакчасы бар – анда эшләргә дә ярата ул. Балдай татлы ике оныгы да үсеп килә – аларны тәрбияләшергә дә өлгерә. Һәм җырлый да!

Күңелдәге моң... Юк, болай гына тумагандыр ул. Мамадыш районы Акман авылы кызы Гөлчәчәк бик яшьли ятим кала. «Миңа 6 яшь булганда әни урын өстендә иде инде», – ди ул. Биш кызының иң кечкенәсе өчен йөрәге яна әнисенең: «Башкаларыгыз инде үз-үзен карарлык. Гөлчәчәгем ятим кала...» Апалары мәктәпкә киткәндә салган ипиләрне мичтән чыгару, ярып бәрәңге пешерү һәм бер адым да авыру әнисе яныннан китмәү – балачак шулай уза. Ә беркөнне әле башлангыч сыйныфта гына укучы кызны күршеләренә кертеп куялар. Артыннан ук җан өшеткеч сүз дә килеп җитә: «Өзелде...» Пышылдап кына әйтсәләр дә, ишетә Гөлчәчәк һәм барысын да аңлый... Ә әтисен... Казан хастаханәсендә вафат булган әтисен ул бөтенләй хәтерләми. Үзенә бик тә охшаган төпчеген аерым яраткан, «Гөлчәчәгемне бер алып килеп күрсәтегез әле», – дип сораган. 2 яшьлек кызчыгы белән юлга чыгарга җөрьәт итмәгән шул әнисе... Алай да әтисен бер күрә ул. Төштә! Киез итеккә олтан салып утырган әтисе аны алдына алып сөя. Шушы бер төш: «Мин әтине күрдем!» – дип, әллә күпме вакытлар сөенергә җитә...

Әйе, моң касәсе шулай тамчылап-тамчылап тула.

Гөлчәчәкне үзе дә әле яңа гына кияүгә чыккан 22 яшьлек олы апасы тәрбиягә ала ул чакта. Искә төшергәндә дә күзләргә шунда ук яшь тула: апасыннан бигрәк җизнәсенә рәхмәт. Сыендырган: абый урынына да, әти урынына да, җизни урынына да булган.

Биш кыз туганның бишесе дә җырлаган аларның. Әниләре кебек. Авырган вакытта да әнисенең сөялеп утырган җиреннән җырлаганын, моңланганын бүгенгедәй яхшы хәтерли Гөлчәчәк:

Һаваларда оча ике аккош,
Каурыйлары җиргә коела.
Янып сөйсәң, күңел канатлана,
Мәңге талмас кебек тоела...

Тормышларын җыр белән бәйләргә берсенә дә насыйп булмый кызларның. Гөлчәчәк тә 50 нче һөнәр училищесын тәмамлаганнан соң гомер буе заводларда эшли. 45 яшендә лаеклы ялга чыга. Алтынчы дистәне ваклый башлагач, кинәт уянып киткәндәй була: чынга ашмаган күпме хыялы бар бит әле аның! Очраклы бер туры килү булмагандыр ул: нәкъ шул көннәрдә телевизордан «Дуслык» ансамбле җитәкчесе Гүзәл Маликованың чыгышын тыңлый. Һәм: «Мин дә җырлыйм бит!» – ди. «Сәйдәш» мәдәни үзәгенә – «Тормышны яратучылар» проектына ул шулай килеп эләгә.

Бүген Гөлчәчәк ханым Гыйниятуллина – «Дуслык» ансамбле каршында эшләүче өч төркемнең дә актив әгъзасы.

– Ансамбльгә килгәнче үземне инде шактый өлкән кеше итеп тоя идем. Барысы да булган, беткән, алда картлык кына көтә кебек иде... «Дуслык»ка кушылгач, ансамбльгә йөрүчеләр белән якыннан аралаша башлагач һәм күбесенең миннән шактый өлкән икәнен күргәч кенә аңладым – әле барысы да алда икән. Җырланасы җырлар да, сөйлисе шигырьләр дә... Нәфис сүзгә дә гашыйк бит әле мин! Мәктәптә укыганда ук концертлар алып бара идем.

Беренче тапкыр зур сәхнәгә чыккан көне әле дә истә аның.

– Каушавымны берничек баса алмыйм – микрофон тоткан кул калтырый... Моны бөтен зал күрәме икән дип уйлыйм. Күрәдер инде, күрәдер, дим... Җырның беренче куплетын шулай җырлап бетердем. Аннан тынычландым. Хәер, җырым да шактый авыр җыр иде шул – «Соңдыр шул, соңдыр...» Мин сайлаган бөтен көйләр дә шундый. Моңлы, озын... Хәзер инде сәхнәдә үземне шактый иркен тотам – дулкынланган чаклар артта калды...

Ә аларга ансамбль белән еш чыгыш ясарга туры килә: санаторийларда, музейларда, төрле фестиваль-конкурсларда. Шуларга атнасына өч тапкыр була торган репетицияләрне дә кушсаң. Аннан – өйдә җырлап йөрүләрне дә...

– Мин өйдә бик еш җырлыйм. Бакчада да... Хәзер генә түгел, гомер буе җырладым. Иң рәхәте – су аккан тавышка кушылып җырлау. Савыт-саба юганда, керләр чайкаганда... Күңел шунда ук җыр сорый башлый. Хәер, мин юлда да гел җырлап, көйләп – яңа өйрәнгән җырларны кабатлап йөрим. Эчтән генә инде, билгеле.

«Тормышны яратучылар» проектына бик рәхмәтле ул: үзе кебек күпме кешенең кычкырып әйтергә дә җөрьәт итмәгән хыялларын чынга ашырырга булышкан. Кая барып бәрелергә белмәгән күпме өлкән кеше шушында җан тынычлыгы тапкан.

– Ансамбльгә йөрү – аралашу дигән сүз дә бит әле ул. Дүрт стена эчендә бикләнеп утыру түгел инде бу. Әллә никадәр яңа дуслар таптым бит ич. Репетицияләрдән һәрвакыт җаным ял итеп кайта. Яңа көч җыеп... Шуңа ирем дә, балалар да җырлап йөрүемә бер дә каршы килмиләр. Яңа җырлар өйрәнү, шигырьләр ятлау зиһен өчен дә файдалы. Яшерен-батырын түгел, сәхнә безгә яшь калырга да булыша. Тамашачы каршына чыгасы булгач, үз-үзеңне гел карыйсың: чәчеңне, киемеңне, кулларыңны... Хатын-кыз өчен болары да бик мөһим бит аның... «Алтынбикә» шәһәр матурлык һәм зирәклек конкурсында катнашып, беренче урынны алдым. Бу җиңү, бу уңыш, беләсезме, миңа күпме еллар өстәде?!

«Тормышымны җырдан башка күз алдына китермим», – ди ул. Һәм яраткан җырларының берсен – «Зәңгәр күлмәк»не суза:

Зәңгәр күлмәгеңне киясең дә,
Зәңгәр күлгә көн дә киләсең.
Йөрәгеңдә нинди утлар яна? –
Уйларыңны килә беләсем...

Гөлнур ХӘСӘНШИНА

Кызыксынучылар өчен: «Тормышны яратучылар» («Жизнелюб») шәһәр проекты Казанда 2016 елның 1 декабреннән бирле эшли. Аның максаты – өлкән яшьтәгеләргә актив тормыш алып барырга мөмкинлек тудыру һәм аларның сәләтләрен ачарга ярдәм итү. Иң мөһиме – барысы да бушлай! 13 төрле юнәлешнең җаныңа якынын сайлап алырга мөмкин: җырларга өйрәнергә дә була, биергә дә, рәсем ясарга да, скандинав йөрүе белән шөгыльләнергә дә, фитнес, театр... «Тормышны яратучылар» проекты кысаларындагы дәресләр шәһәребезнең 56 мәйданчыгында уза: мәдәният йортларында, китапханәләрдә, ә җәен – паркларда да. Клубларда, түгәрәкләрдә алган осталыкларын, иҗади сәләтләрен өлкәннәр аннары шәһәр күләмендә узучы бәйге-конкурсларда күрсәтә. 2020 елда, мәсәлән, проект кысаларында узган дәресләргә 69 мең кеше килгән. 626 чара уздырылган, һәм аларда 95 мең кеше катнашкан. Казан шәһәре мэры Илсур Метшин: «Өлкәннәр безне үзләрендәге энергия һәм актив тормыш алып бару теләге белән таң калдыра», – ди.



Видеоны карар өчен смартфонның камерасын QR-кодка якынайтыгыз. Фото һәм видео: Анна Арахамия.

ЯКТЫЛЫК

Аларга бөтен Самара татарларының күзе төбәлгән: милләттәшләребезнең өмете, ышанычы ул «Яктылык» мәктәбе. Киләчәге! Радик Рәфгать улы бу хакта бер минутка да исеннән чыгармый. Ул җитәкләгән мәктәп шуның өчен дә башкалар белән чагыштырганда гел алдарак булырга тиеш. Аның эшенә, кабул иткән карарларына бүген генә түгел, киләчәктә дә кайтып-кайтып бәя бирәчәкләр. Максат гел бер: «Яктылык» – яктылык таратсын. Туган телебезне сакласын! Әңгәмәдәшем – Самара шәһәренең татар телен һәм мәдәниятен тирәнтен өйрәнүче «Яктылык» мәктәбе директоры, Самара шәһәренең Иҗтимагый палата әгъзасы, Россия Федерациясенең гомум белем бирүнең почетлы хезмәткәре Радик ГАЗИЗОВ.



Фото: Анна Арахамия



Гөлнур САФИУЛЛИНА



ТАМЫРЛАР Самара өлкәсе Келәүле районына әтине ветеринария техникумын тәмамлаганнан соң юллама белән эшкә җибәрәләр. Бу мукшы авылында бердәнбер татар гаиләсе идек без. Әти – Камышлы районының Иске Ярмәк авылыннан. Шунда ук «Ярмәк вагы» биюе искә төшкәндер... Шәҗәрәләре бар – ярты Ярмәк безнең нәсел анда. Польша ягыннан килеп урнашкан Биктимер бабайдан башлана ул. Әтинең әтисен – Шәяхмәт бабамны авылдашлары һаман да хәтерли. «Шәяхмәт булма инде!» – дип сөйләшәләр Ярмәктә. Аның кебек артык намуслы, туры булма, ягъни мәсәлән. Яратып, хөрмәт итеп әйтәләр. Төрле җаваплы урыннарда эшләгән Шәяхмәт бабай: склад мөдире дә булган, умартачы да. Әмма өйгә бернәрсә дә алып кайтмаган. Өч сугышны үткән, тугыз тапкыр яраланган. Фронтларда күргәннәрен безгә сөйләгәне истә түгел. Капитан булганлыгын гына беләм. Икенче бабам да сугышны кичеп, Калининградка кадәр барып җитеп, туган ягына – Шентала районы Денис авылына исән-сау әйләнеп кайткан.

Әти авылда гомер буена дәрәҗәле, хөрмәтле кеше булды. Маллар тоткан һәркемнең аңа үтенече төшми калмагандыр. «Равгать, помоги!» – дип, төн уртасында да киләләр иде. Берәүне дә кире бормады – бик ярдәмчел, карусыз иде. Мин аның безгә катырак сүз әйткәнен дә белмим.

Өйдә бары тик татарча гына аралаштык – бездә «папа», «мама» дип әйтүләр булмады. Мәктәптә, урамда русча, мукшыча сөйләштек. Медкартамда: «Мальчику 3 года, свободно разговаривает на трех языках» дигән язу бар. Элегрәк мукшылар мине үзләренеке дип уйлый иде, хәзер тел азрак онытыла төште.

Совет чоры бит: мукшыларның да, безнең дә яшәү рәвеше бертөслерәк иде. Бары тик мунчаны без җомга алдыннан, ә алар шимбә көнне яга иделәр.



БАЛАЧАК Сабантуйларда йә Ярмәк, йә Денис әбиләргә барганнар бик истә. Әти белән әнинең бертуганнары кайта – өй тулы кунак. Әбиләрнең икесендә дә мич ашлары пешә. Дениста – гөбәдия, кыстыбый, Ярмәктә – коймак, зур бәлеш... Табынга ашны зур тимер табакта чыгаралар. Барыбыз да шуннан үрелеп агач кашыклар белән ашыйбыз...

Авыл баласы эш белән үсә инде ул. Көтү көтеп, печән чабып, бәрәңге алып... Әбиләргә дә кунакка түгел, күбрәк булышырга бара идек: колхоз бүлеп биргән суган, чөгендер җирләрен утарга. Кайчакта авыр да булгандыр, туйдыргандыр да, бәлки. Әмма бу зур тәрбия дә булган – рухны, ихтыяр көчен ныгыткан. Авыл кешесе шуңа да юк-барга гына зарланмый. Әйе, авыл ул – үзе бер университет.



УКУ Әти белән әни икесе дә мәктәптә татарча укыганнар, безгә инде ул бәхет эләкмәде. Мәктәптә русча укыдык, урамда мукшыча сөйләштек. Укырга ярата идем. Геометрияне дә, әдәбиятны да – бер дәрәҗәдә. Авыл китапханәсен тулысынча укып чыктым: Бажов әкиятләреннән башлап, «Война и мир», «Мастер и Маргарита»га кадәр. Кем генә булырга хыялланмадым?! Космонавт, милиционер, хирург... Ә менә укытучы булырга беркайчан омтылмадым – андый теләк булмады. Класста староста идем, комсомол оешмасын да җитәкләдем. Беренче класска ук: «Мәктәпне тәмамлыйм да, институтка укырга керәм», – дип бардым. Әти кебек булам! Дөрес, ул югары белемне читтән торып алды. Алгарак китеп булса да әйтим, әти юлыннан энем китте – ул да аның кебек мал табибы һөнәрен сайлады. Мәктәптә яхшы укыгач, югары уку йорты ишекләрен ачып керәчәгемә шигем юк иде. Самара дәүләт университетының икътисад факультеты студенты булырга тиеш идем. Конкурстан узмадым... Аяктан егарлык хәбәр иде бу. Берничек башыма сыймады: ничек инде, шулкадәр яхшы укыпмы?! Рәхмәт язмышка – әлеге сынау мине бик нык ныгытты... Документларымны Самара дәүләт мәдәният институтының рабфагына тапшырып, авылга борылып кайттым. Нигә мәдәнияткәме? Мин музыка мәктәбен дә тәмамлаган идем. Баян классын. Анда керүем кызык кына булды. Авылга мәктәпкә яңа директор килде. Кызы моңарчы музыка мәктәбендә укыган булган икән – безгә килгәч, ул укуын район үзәгендәге мәктәптә дәвам итте. Ишеткән-күргән хәл түгел. Аңа кызыгып ияручеләр арасында мин дә бар идем. Кемдер музыка мәктәбен – бер айдан, кемдер ярты елдан, бер елдан ташлады. Ахырда берүзем калдым! Атнага ике тапкыр җиде чакрымдагы район үзәгенә йөрдем. Җәяү дә, велосипедта да, чаңгыда да. Әни, әмма күбрәк энем озата бара. Икәү бергә барабыз да, ул мине дәресләр беткәнче көтеп утыра. Хәзергә кадәр: «Сине мин укыттым», – дип көлә...

Шәһәрдән борылып кайткач, мине ындыр табагы мөдире итеп куйдылар. Рабфакка керү өчен мәдәният өлкәсендә эшләргә тиеш идем – район Мәдәният йортына да урнаштым. Шуннан эштән кайтканда авылдашлар белән юл фаҗигасенә тарыдым. Санавиация белән Самарага озатканнар – операция арты операция кичердем. Өр-яңадан җыйдылар... Икенче группа биреп кайтардылар. Мин кичергән җитди сынауларның тагын берсе иде бу. Алга китебрәк сөйлим: мәктәпкә эшкә килгәч, музыка дәресләре белән беррәттән, миңа физкультураны да бирделәр. Беркайчан укучыларның шөгыльләнгәнен читтән карап басып тормадым. Бергә йөгердем, чаңгыда йөрдем, волейбол уйнадым... Физкультура укытучысы буларак район бәйгесендә катнашырга җибәрделәр. Җиңдем! Өлкә буенча да җиңү яуладым! Әстерханда узган зона турында да беренче урынны алдым. Бөтенроссия бәйгесеннән лауреат исеме алып кайттым. Үз-үземне җиңү дә иде бу!

Студент чакта «Ялкынлы яшьлек» ансамбленә йөри башладым. Сәхнәдән төшмим дә: концертны алып барам, җырлыйм, баянда уйныйм. Яңа сәләтем ачылды: мәҗлесләр алып бара башладым. Танылдым. Әмма соңрак, Аллаһ ризалыгы өчен дип, ул эштән үзем баш тарттым... Ансамбль мине татар мохитенә алып керде. «Яктылык» мәктәбенең беренче директоры Харидә апа Дашкина мине шул концертларның берсендә күреп, мәктәпкә эшкә чакырды.



УҢЫШ «Яктылык» мәктәбе – минем язмышым. Ун ел укытканнан соң, башта эшкә шәһәр мәгариф департаментына, аннан, конкурс аша министрлыкка күчтем. Җиде елдан соң, шактый тәҗрибә

туплап, 2012 елда мәктәпкә кире кайттым – директор булып.

Безнең мәктәпнең тарихы 1989 елдан башлана. Башта «Якшәмбе мәктәбе» генә булып эшли әле ул. Аннан укучылар җыярга керешәләр. Татар оешмалары активистлары, татар гаиләләре исемлеген төзеп, өйләр, фатирлар буйлап йөриләр. Харидә апа Дашкина бу оештыру эшләренең башында тора. Концертлар алдыннан сәхнәгә чыгып: «6 нчы сыйныфта – ике, 7 нче сыйныфта өч урын калды, балаларыгызны китерегез», – дип сөйләгәнен үзем дә хәтерлим... Инде менә ничә ел бездә беренче сыйныфка керүчеләр арасында – конкурс. Харидә апаның хыялы булгандыр бу... Узган ел ике сменада укытуга күчтек – сыймыйбыз. Ата-аналар канәгать түгел, әлбәттә – балалар бит «Яктылык»ка бик ераклардан килеп укый. Күршедәге бинаны безгә бирүләрен көтәбез. Аның реконструкциясенә генә дә 200 миллион сум акча кирәк булачак.

Мәктәпкә укучылар җыйганда иң яхшыларын – каймакларын гына сайлап алмыйбыз. Безнең төп таләп – татар телен, мәдәниятен өйрәнергә теләк булу. Калганына укытучыларыбыз тырышлык белән ирешәчәк: нәтиҗәләрне күреп торасыз. Минем үземне бигрәк тә катнаш гаиләләрдән балалар килүе сөендерә. Аннан – элеккеге укучыларыбызның үз балаларын безгә укырга бирүе. Бу да күп нәрсә хакында сөйли... Ата-аналарны, әлбәттә, «Яктылык»ның тәрбиягә зур игътибар итүе тарта. Бер генә мисал: авыл кешесенә күршегә нигә ярдәм итәргә кирәген аңлатып торасы юк. Ә шәһәрләр «Күрше хакы – тәңре хакы» дигәннең нәрсә икәнен дә белми. Без менә шуның өчен дә өмә вакытында тирә-күрше ишегалларын да җыештырабыз. Зур бәйрәмгә әйләнә ул: казанда пылау пешә, баянчы уйнап тора... Әле менә яңа гына җыелыш булды, шәһәр советы депутаты очрашуга килде. Халык үзенең зарын сөйли. «Безгә бит хәтта юлны да татар мәктәбе директоры салдырды», – диләр. Юлны без салдыра алмыйбыз, билгеле, әмма бит алар шулай кабул итә. Бу сүздә безне зурлау, хөрмәт бар... Өмәгә ата-аналар да килә. Бер-берсе белән танышу, аралашу өчен менә дигән мөмкинлек. Киләчәктә бит аларның кода-кодагыйлар булып кую ихтималы да зур... Кышын чаңгы базасына барып «Сәламәтлек көне» уздыруыбыз да шуның өчен. Аңа укучыларның әти-әниләре генә түгел, бөтен туганнары чакырыла. Губернатор үзе кунак булып килгәне бар. Укытучыларның, ата-аналарның бергә кушылып ел саен корбан чалуы да – күңелле күренеш. «Әтиләр клубы»ның эшләве дә. Бу клубка өлкән классларда укучы ир балалар әтиләре, ир туганнары белән килә: уролог, психолог кебек белгечләр белән очрашалар, иң катлаулы темаларны кузгаталар... Мәктәп турында бик озак сөйләп булыр иде. «Йолдыз» бию театрының уңышлары, мәктәп музее, көрәшчеләр түгәрәге, «Сәләт-Самара» аланы, Җәмигъ мәчете белән элемтә... Аерым-аерым укытучыларыбыз турында: һәркайсына таяна алам, һәрберсе җанын-тәнен биреп эшли.

Башка мәктәпләргә караганда «Яктылык»ка җиңелрәк: безнең Талип хәзрәт Яруллин, Фәхретдин Канюкаев, Әнвәр Горланов, Ильяс Шәкүров, Ленар Сабиров кебек милли һәм дини оешма җитәкчеләре бар. Алар һәрвакыт хәлебезне белешеп, уңышларыбыз өчен сөенеп торалар.

Игътибар иттегезме икән: бөтен укытучыларыбыз да татар телендә сөйләшә. Бу – аларга иң беренче таләп.



МӘХӘББӘТ Мәктәптә атнасына җиде көн эшләдем – ял көнне «Якшәмбе мәктәбе»ндә дә укыттым. Анда йөрүче өлкәннәр, яшьләр, балалар өчен музыка дәресләре алып бардым. Берничә ел шулай эшләдем. Аннан директордан: «Һичьюгы бер көн ял бирегез инде», – дип сорадым. Урыныма бер кыз тапканнар иде, әмма уку елы беткәндә генә ул кияүгә чыкты. «Якшәмбе мәктәбе»нә кабат әйләнеп кайтырга туры килде. Карыйм, мин юкта яңа бер кыз йөри башлаган. Күрүгә үк ошаттым. Икенче тапкыр очратканда инде: «Ул минеке була!» – дип уйладым... Һәр эштә миңа киңәшләр бирүче журналист Шамил абый Бәһаутдин: «Мәктәпкә әнисе, бабасы белән бергә килгәч, ул кыз, димәк, тәрбияле инде», – диде. Аның бу сүзләре фикеремне тагын да ныгытты... Әнисе белән бабасы гарәп теле өйрәнергә йөриләр: Гөлия башта алар белән утыра, аннан музыка дәресенә керә. Әйе, ул – минем укучым. Яшь аермабыз өч кенә ел булса да, Гөлия миңа бик озак «Радик абый», дип дәште... Мәхәббәтнең ни икәнен сүз белән аңлату авыр бит аны. «Чиләгенә күрә капкачы», ди халык. Аллаһы Тәгалә кушадыр адәм балаларын. Әмма бер-береңне саклап калу өчен аннары үзеңә дә шактый тырышасы әле – гаиләнең нигезендә түземлек ята.



АКЧА Акча күп булмый, диләр, әмма аның күплеге кеше тормышында тискәре роль уйнарга да мөмкин. Әйтик, акчалы кешегә дин тоту да, балалар тәрбияләү дә авыррак – кулда байлык булганда күңелгә ымсыну, вәсвәсә салучы әйберләр күбрәк. Акчам чамасыз булса, балалар үзләрен ничек тотар иде дип уйлыйсың. Мотоцикл кирәкме – рәхим ит. Машина? Алабыз! Армани, Пьер Карденнан киенәсең киләме? Ярый! Франциягә очарга телим дисеңме? Айга?! «Телим»нәрнең чиге булмаячак бит... Тик кесәңдә җилләр уйнаса да рәхәт түгел. «Бедность – не порок, а нищета – порок», дип укып үстек без мәктәптә Достоевскийны. Бер нәрсәне анык беләм: теләк булганда һәм хәрәкәт иткәндә акча табыла. Юк икән, димәк, ул акча сиңа хәерле түгел. Яши-яши шундый нәтиҗәгә килдем.

Ислам диненнән беләбез: ана карынында балага дүрт айлык чакта җан иңә һәм ул бәхетле буламы, әллә бәхетсезме, баймы, ярлымы – барысы да языла. Әмма мондый дога да бар: «Ләүхел Мәхфүз китабында ярлылардан, бәхетсезләрдән язылган булсам, шул китаптан мине сыз, бәхетлеләр китабына керт». Димәк, барысы да үзгәрергә дә мөмкин. Син сора, телә. Һәм тырыш! Нинди хәл булса да, һәрвакыт Аллаһка таяндым: ул юлын күрсәтми калмый.



ДИН Дингә берәү дә бер көндә генә килмидер. Дини мәҗлесләрдә булганда хәзрәтләр сөйләгән вәгазьләр минем күңелгә дә җыелып килгәндер. Гарәпчә өйрәнергә теләдем. Бик тиз генә килеп чыкмады... Мәдрәсәгә кереп укый башладым. Аннан Уфа

ислам институтын тәмамладым. Алган дини белемем эшемдә дә булыша. Шундый чорда яшибез – шөкер, намазда, диндә икәнеңне яшерү кирәкми.



МАВЫГУ Минем өчен иң зур хобби – әлбәттә, мәктәп! Ул гел беренче урында... Тагын табигатьтә булырга, урман-кырларда йөрергә яратам. Каен, имән себеркесе бәйләргә, җиләк, гөмбә җыярга... Карлыган яфрагы, мәтрүшкә, бөтнек... Иң хуш исле чәй – шулардан. Иң яхшы ял да – шушы. Чит илләргә барсаң да яхшы, әлбәттә – яңа җирләр күрәсең. Әмма әни янына кайтуга җитми инде...



БАЛАЛАР Күп балалы гаилә булырбыз дип күз алдыма китермәгән идем. Хатын да шулай ди (*көлә*). Олы кызыбыз Наилә инде югары уку йортында белем ала. Билал быел мәктәпне тәмамлады. Камилә җиденчегә күчте, Ибраһимыбыз 1 нче сыйныфка бара. Олыларын инде алдыңа утыртып иркәләп булмый, шуңа күрә кечкенәләрен күбрәк кочакларга тырышасың – бу чорның бик тиз узачагын беләсең. Мин күбрәк өйдә дә укытучы бугай – тәрбияләргә яратам. Кайчак артыграк та... Әтиләре директор булган мәктәптә уку аларга җиңел түгелдер. Җаваплылык сизгәннәрен беләм. Бигрәк тә Наиләдә күп иде ул. Гел татарча гына аралашалар дип әйтә алмыйм, әмма, шөкер, телне беләләр. Татар теле һәм әдәбияты буенча Казанда, халыкара олимпиадаларда да катнаштылар. Мәктәптә үзем татарча укымагач, кирәк булганда кагыйдәләрне алардан сорыйм – аңлаталар. Иртән эшкә машинада барганда һәр көнне әнигә шалтыратам. «Тордыңмы, исән-саумы?» – дим. Миңа балалар да кушыла: «Зур әни, чәй эчтеңме әле, авырмыйсыңмы?» – диләр. Әбиләре белән татарча гына сөйләшәләр.



КУРКУ Кыямәт көнендә ничек җавап бирербез дигән курку бар... Анысы бөтен кешегә дә хастыр инде... Мәктәптә хезмәт хакы өчен генә эшләмим бит. Безнең бүгенге гамәлләргә киләчәк буыннар бәя бирәчәк. Бу иңнәргә бик зур җаваплылык өсти. Әлеге җаваплылыктан куркам дип әйтүем түгел, әмма мин аны гел тоям.



ҮЗЕМ ТУРЫНДА Авылга кайткач, печән чабасың кайчак. Кояш яндыра, бөтен җиреңнән тир ага. Авыр, әлбәттә. Әмма исәнлегең зарланырлык булмаса, бу барыбер җиңелрәк. Җитәкче урынында утырып, нинди дер җитди карар кабул итүгә караганда, диюем. Мин үзем йомшак кеше, әмма директор буларак алган вазыйфаларым «телим, теләмим»нәремне онытты ра. Өйдә дә шулай бит. Бала тәрбияләгәндә, күңелең моңа каршы булса да, кырыслык та күрсәтергә туры килгәли. Ялгышырга гына ярамый!

Казан–Самара–Казан

Фото: «Яктылык» мәктәбе архивыннан

«ЯКТЫЛЫК» МӘКТӘБЕ САННАРДА:

- бүген мәктәптә 600 гә якын бала белем ала;
- быел мәктәпне 33 бала тәмамлаган, шуның тугызы алтын медальгә лаек булган;
- 2019 елны мәктәпне алтын медальгә 6 укучы тәмамлаган;
- БДИда рус теленнән 100 баллны алдагы елларда – ике, быел рус әдәбиятыннан бер укучы җыйган;
- 2019 елда «Яктылык» укучылары БДИда математикадан җыйган баллар Самара өлкәсе күрсәткечләреннән күпкә югары була һәм математиканы тирәнтен өйрәтүче лицейларны да узып, аларның мәктәбе «математика иң көчле укытыла торган ун уку йорты» исемлегенә керә;
- «Россиянең иң яхшы 100 мәктәбе» арасында «Яктылык» та бар.
- Мәктәптә балаларга 39 укытучы белем бирә, аларның барысы да татар телендә сөйләшә.
- Татар теле, әдәбияты һәм татар халкы тарихы фәннәрен укыту мәктәпнең уку планына кертелгән.









Видеоны карар өчен смартфонның камерасын QR-кодка якынайтыгыз.
Видео: Анна Арахамия





ЯРЛАРНЫ ТОТАШТЫРГАН КҮПЕР



Алсу
ШАКИРОВА

«Нәрсә белән аерылып торасыз, дисез… Алай бер артык җиребез дә юк. Тырышабыз. Булдырырга дигәндә, китереп биргәнне көтеп ятмыйбыз. Бездә күбрәк эш инде. Сездә эш бетми, дип көлә балалар да. Ишле гаилә булгач, маллар да күп асрадык. Көтү чираты җиткәч, берәр атна көтү көтә иде малайлар. Әле дә бөтен эшне җыелышып, күмәкләшеп эшлибез. Үзебез бер бригада кадәр. Өйнең түбәсен дә бергә яптык әле менә», – Фәһеметдин абый ашыкмый гына, ипләп кенә тормыш юлларын күз алдыннан үткәрә.

Гөлнәзирә апа белән Фәһеметдин абый Хисамиевлар бер авылда – Тенекидә туып, авыл уртасыннан агып утыручы елганың икесе ике ягында үскәннәр. «Безнең якка чишмәгә чыгып йөри торган иде Гөлнәзирә, күз алдында булды инде», – ди гаилә башлыгы. Шуңа күрә ике йөрәк – ике йорт арасында күпер кайчан салына башлаганын төгәл генә әйтүе дә мөмкин түгел. Фәһеметдин абый армиягә киткәч, ерак араны хатлар белән җылытып торалар. Хезмәтен тәмамлап кайткач, ел ярым вакыттан соң өйләнешеп тә куя яшьләр.

Фәһеметдин – Фәттахетдин абый белән Өммикамал апаның биш кызлары арасында үскән бердәнбер малай. Йортка киләсе кыз – бер түбә астында гомер итәргә, төп нигезгә кунакка кайтучы кыз-кияүләргә, оныкларга якты йөз күрсәтергә тиешле килен дә бит әле. Күз карасыдай саклап үстергән уллары сайлап алган авыл кызына хәер-фатихасын бирмиме соң олылар? Төкле аягы белән, бердәнбер килен булып Гөлнәзирә төп нигезнең бусагасын атлап керә.

– Курыкканмындыр инде, суга йөзәргә дә курка-курка гына керәсең бит ул... Бер-беребезне ошатып, яратып өйләнгәч, бернинди киртәләр дә комачауламый. Мин килгәндә төп йортта сеңлесе дә бар иде Фәһеметдиннең, кияүгә биргәнче аның белән дә 7 ел тордык. Фәттахетдин әти озак яшәмәде, без өйләнешкәч, биш елдан арабыздан китеп барды. Өммикамал әни белән 25 ел яшәдек. Иремнең кыз туганнарының балалары монда кайтырга дип ашкынып торалар иде. Кайтсак ярыймы дип, бездән рөхсәт сорап кайттылар һәрвакыт, – дип искә ала Гөлнәзирә апа. Кайнанасыннан күп әйберләргә өйрәнә ул.

– Бөтенесен әйтеп өйрәтмәсә дә, күңеле белән күрә белгән кеше кайнанадан карап торып та бик күп әйбергә өйрәнә ала. Өммикамал әни бик тырыш, тик-тормас, җитез кеше иде. Барасы җиренә дә тиз генә барып кайта. Яшь кеше бит, минем дә килмәгән җирләрем дә булгандыр... Кая барсак, китсәк, барыйкмы, дип рөхсәт сорадык. Ничек җайлы, шулай эшләгез дия торган иде әни.

Шулай ипләп, килешеп кенә яшәп ятканда, яшь гаиләгә көтелмәгән сынау килә. Беренче уллары Фидәилгә 1 яшь кенә була ул вакытта. Кайгылы хәбәрне гаиләгә ирештерергә килгән шофер, үзе белсә дә, дөресен әйтергә кыймый...

– Сәгать иртәнге ун иде, мин фермада эштә, – Гөлнәзирә апа ул көнне минутлап хәтерли. – Председательнең шоферы: «Фәһеметдин абыйның хәле авыр, туганнарын алып килергә куштылар», – дип, әти белән мине Саба хастаханәсенә алып китте.

Эшләгән вакытта «Беларус» тракторының прицеп компрессоры шартлап, дисклары аерылып китә дә, Фәһеметдин абыйның аяк-куллары, яңак сөякләре сына. Ирнең гәүдәсен трактор астыннан җиргә чыгарып салалар... Яшь кеше бит, тизрәк хастаханәгә илтегез, бәлки өметледер дип, өлкәннәр аны озатып җибәрү ягын караса да, Фәһеметдин үлгән дигән хәбәр авылны яшен тизлеге белән әйләнеп уза. Юлда барганда гына кыймылдый башлаган ирнең исән икәнен аңлыйлар! Сабада беренче ярдәм күрсәтеп, аяк-кулларына гипс салып, очкыч белән тиз арада Казанга озаталар ирне.

– Син кер әле, сине кертерләр дип, палатага әти мине кертеп җибәрде. Селкенеп ятканын күреп, Аллага шөкер, бу исән икән, дидем. Утырып кына торса да ярар иде, бу дөнья кешесе булса ярар иде дип теләдем... Чынлап шулай дидем, бабай! – дип, иренә борылып дәшә Гөлнәзирә апа. Тыйнак кына елмаялар...

– Гөлнәзирә минем белән ике ай Казанда хастаханәдә ятты. Аяклар йөрми, куллар тотмый, чәйни дә алмыйм. Трубка аша сыеклыклар эчертеп, ризык туглап биреп, бала караган кебек тәрбияләде ул мине. Кул рәтләнде, чәрдәкләнеп, ватылып беткән аяк бер елдан соң гына төзәлде. Ике ел буе дәваланырга туры килде.

Гөлнәзирә апаның догалары кабул була: гомере бетмәгәч, утырып кына тору түгел, аякка баса Фәһеметдин абый. Ферма мөдире булып эшкә урнаша. Фидәилләре янына бер-бер артлы тагын биш балалары дөньяга килә – Камил, Алсу, Рамил, Гөлнур, Илнур. Олы уллары шушы авылда төпләнеп калган. Елганың теге ягында – Гөлнәзирә апаның төп нигезенә башка чыгып, яңа йорт җиткергәннәр. Үз авылында күмәк хуҗалыкта агроном булып эшли Фидәилләре.

Башкалардан аерылып торган бер җиребез дә юк, диләр... Киленнәре Гөлназ әйтмәсә, «Ана даны» медален искә дә алмаслар иде, мөгаен. 2001 елда алган бу мактаулы исемгә лаеклы ана, тугры тормыш иптәше – гаиләнең бизәге. Төпчек уллары Илнурның хатыны – әле өч ел элек кенә йортка килен булып төшкән Гүзәл өчен иң зур ярдәмче дә Гөлнәзирә апа. 2 яшьлек улларын олы абый итеп, йортка игезәк малайлар алып кайткан Гүзәл.

– Игезәк балалар буын аша гына кабатлана диләр иде. Бик теләсәм дә, безгә эләкмәс инде, балаларда гына булыр дип уйлаган идем. Бүген менә бишектә әле бер айларын да тутырмаган улларыбыз – Айзат белән Илзат яталар, – дип сөенә Гүзәл. Менә шулай өч ел эчендә өч балалы гаилә була да куя яшьләр.

Гүзәлне Гөлнәзирә ападан да яхшырак аңлаучы юк. Үзе дә игезәк балалар үстергән ана кеше генә

// Фәһеметдин абый:

«Безнең белән татарча гына сөйләшә оныкларыбыз. Хәзер теләгән кешегә телевизордан да татарча тапшырулар җитәрлек, балалар өчен аерым каналлар бар. Үзең сөйләшмәсәң, балалар да, оныклар да оныта инде телне. Безнең йорт түбәндә урнашкан булгач, элек телевизор күрсәтми иде. Олы балалар күбрәк китап укып үстеләр. Журналлар да яздыра идек».

Фото: Анна Арахамия



Видеоны карар өчен смартфонның камерасын QR-кодка якынайтыгыз.
Видео: Анна Арахамия.

Сабыр булырга, күпне күрмәскә, күп сөйләшмәскә кирәк. Күбрәк олы кешедән тора инде ул.









бу бәхетнең бөтен михнәтен дә, рәхәтен дә беләдер. Төп йортта яшәүче уллары Илнур – игезәк сыңары. Игезәкләре туганда дүрт балалы ана тәҗрибәсе булса да, ничек үстерербез боларны дип борчылган көннәре аз булмаган Гөлнәзирә апаның:

– Игезәкләргә өч ай булганда үз әнием арабыздан вакытсыз китеп барды... Газиз кешеңне югалту ачысын татыганда сабырлык сүзен белмәгән ике сабыйны берьюлы багу җиңелләрдән түгел. Олылар әйтмешли, мәхәббәте белән балаларның мәшәкате дә онытыла. Хәзер үземнән дә озын инде Гөлнур белән Илнур дип, шөкер итеп йөрим, – дип сөйли Гөлнәзирә апа.

Борынгыдан килгән гадәт буенча, яшь әнине кайгыртып, саклап кына тоталар зур гаиләдә. Бөтен эше – бала карау хәзер Гүзәлнең. Олы уллары Ранил дә тәрбиягә мохтаҗ сабый бит әле, 2 яшь кенә булса да, абый булып йөри әнә.

– Кемдә бар әле ул мондый абый, дип әйтә әни, көлешәбез инде. Мин бала табу йортында ике атна яттым. Әби-бабай тәрбиясендә үсеп, тазарып киткән Ранил. Бик яхшы, әйбәт гаиләгә барасың, дигәннәр иде кияүгә чыкканчы ук. Дүртенче килен булып килдем, бөтен эшне әни белән бергә эшләп өйрәндем. Алардан башка яшәүне күз алдына да китермим, – ди Гүзәл.

Гөлнәзирә апа белән Фәһеметдин абыйдан балалар белән бергә матур яшәү серләрен ишетәсе килә. Аерып әйтерлек кагыйдәләре дә юк кебек. Бу – аларның тормыш рәвеше. Тәртип, тәрбия, матур гадәтләр каннарына сеңгән Хисамиевларның. Югыйсә башка чыгарганчы, олы малай-киленнәренең һәммәсе белән дә бер түбә астында яшәгән алар. «Ашыкмагыз әле, киленгә ияләшеп тә бетә алмыйм, тагын бераз торыгыз», – дип, җибәрәсе килми генә аерылышканнар балалар белән. Борчылыр урын юк, малайлар да, кызлар да ерак китмәгән. «Саба монда гына бит ул!» – дип, ун минутта кайтып җитәләр район үзәгеннән Камил белән Алсу. Арчада яшәүче Рамилләре, Питрәчтә төпләнгән Гөлнурлары янына кунакка дип чыгып китәргә дә аптырап тормый әби-бабай.

– Гаиләдә күп нәрсә олы кешедән тора. Сабыр булырга, күпне күрмәскә, күп сөйләшмәскә кирәк. Яшьләргә дә акыллы булырга кирәк. Мин генә дип торсаң, булмый. Алай эшләмәгез, болай эшләмәгез дигән юк. Үзләренә кирәк булганча эшлиләр. Исән-сау булып, балаларын тигезлектә үстерсеннәр! – әти-әни шундый хәер-теләктә.

Хисамиевлар ишегалды оныклар белән тулы. Бергә уйнап, олылары бәләкәйләренә күз-колак булып торалар. Барлыгы унбиш оныклары бар Фәһеметдин абый белән Гөлнәзирә апаның. Тиздән ишәяселәре бар – Илнурның игезәк сыңары Гөлнур икенче тапкыр әни булырга әзерләнә, Аллаһы боерса. Җәйге каникул вакытында авылга кайтып, малайлар бабалары белән мәчеткә йөриләр. Авыл мәчетендә чиратлашып азан әйтәләр.

Зур гаилә башлыгы Фәһеметдин абый Саба районында иң күп газета-журналлар алдыручы кешеләрнең берсе икән. Берара унике басма килгән өйгә. Язылучылар арасында уздырган бүләк уйнатуда катнашып, өч тапкыр бүләк алганы бар икән Фәһеметдин абыйның. Хәтта 100 литр бензин да откан.

– Әниләр исән вакытта бер түбә астында тугыз кеше тордык. Мин эшкә китәм, Өммикамал әни балаларны чәй эчертеп мәктәпкә озата, каршы ала. Ишле гаиләдә авыр вакытлар булмый калмый. Киендерергә, укытырга кирәк балаларны. Алсу кызым: «Эшсез тотмадыгыз инде безне», – ди. Әйе, эшләтеп үстердек. Ферма мөдире булып эшләүдән туктагач, Фәһеметдин үзе дә тик тормады, күмәк хуҗалыкка ярдәм итеп, ат арбалары, чаналар төзәтү белән шөгыльләнде.

«Хезмәт кешесе – хөрмәт кешесе», ди халык. Кулыннан эш килгән балалар – әти-әнинең көзгесе. Бу гаиләдә балаларны хезмәт белән тәрбияләгәннәр. Камил улларының тормыш иптәше Гөлназ да шулай ди:

– Бар яктан да үрнәк, тату гаилә икәнен белә идем кияүгә чыкканчы ук. Гаиләнең асылы дөрес тәрбия салынган балаларда чагыла. Барыбызның да тормышлары көйләнгән. Тәртипле балалар үстергәннәр әти белән әни. Кулларыннан килмәгән эш юк. Кайсы эшкә тотынсалар да, осталарча башкарып чыгалар. Зур эшләрне җыелышып, өмә ясап эшлибез. Өйнең түбәсен малайлар, кияүләр бергәләп яптылар. Үзебез эшләдек дип, әти бик горурлана. Маллар суйганда, каз өмәләрендә бергә җыелу – гаиләнең матур гадәте.

Гөлнәзирә апаның туган көне 31 декабрь көнне икән. Төп нигездә җыелып, үткән елга нәтиҗә ясап, әниләренең хәер-фатихасында яңа елны башлап җибәрү дә матур бер йола Хисамиевларда.

2020 елда тагын бер вакыйга ишле гаиләне Тенеки авылында җыя. Барлык туганнарын, балаларын, оныкларын чакырып, район башлыгы Рәис Миңнеханов Фәһеметдин абый белән Гөлнәзирә апаның өйләренә килеп, «Мәхәббәт һәм тугрылык өчен» медален тапшыра.

Ярларны кавыштырган күпер бүген буыннарны, күңелләрне тоташтыра. Әлләкем түгел без, диләр... Өйнең түрендә түбәтәй кигән әти, ап-ак яулыгын япкан әни утыра. Игезәкләрнең кемгә охшаганнарын ачыкларга тырышып, аш бүлмәсендә кызлар, киленнәр, үзара көлешә-көлешә, табын хәстәрлиләр. Үзләре үстергән тавык итеннән токмачлы аш өлгергән. Мичтә берничә төрле иттән пешкән бәлеш әзер. Төпчек киленнәре сөтле чәй эчә – сабыйларның ризыгы булсын, ди. Табын артына чакырганны көтеп, ишегалдында малайлар, кияүләр гәпләшә. Бишектә йоклап ятучы игезәк энеләренә күз салып, уятмаска тырышып, оныклар йөгерешә. Алар туган телләрендә сөйләшә... Гади, ихлас, тырыш, «нәкъ безнеңчә матур» гаилә. Саксыз кагылырга – күз тидерергә дә куркырсың бу күренешкә...







PRESSA

«Шаянлык – аның калканы. Кәефенең нинди чагы булмасын, борчу-гамьнәрен иңеннән кагып төшереп, бусага артында калдырып керә белә... Сөйләсә – батырып сөйләр, җырласа – өздереп җырлар, көлсә – рәхәт чигеп көләр... Кайчакларда мин: «Гәрәй Рәхим дә, олыгаеп, мыжыклана күрмәсен, Ходаем, алай булса, дөнья бик күңелсезләнер иде», – дип уйлап куям. Шөкер, ул һаман элеккечә, шаян-шук, җор сүзен гүя түш кесәсеннән генә үрелеп ала. Үз борчуларын онытып, кеше гаменә күчә белгән җайлы, иҗтиһатлы, син катлаулы дип уйлаган мәсьәләдән гади генә чишелеш таба белгән хикмәтле шәхес ул. Кеше белән бүлешергә күңелендә һәрчак бер уч җылы булыр...» Язучы Марсель Галиев каләмдәшен менә шулай тасвирлый. Һәм киң күңелле, гади, ихлас, бик тә үз, рәсми кәгазьләрдә Григорий Родионов булып та, иҗатта Гәрәй Рәхим булып танылачы шагыйрь күз алдына килеп баса. Татарстанның халык язучысы Гәрәй Рәхим бу көннәрдә 80 яшьлек юбилеен билгеләп үтә. Шагыйрьне зур юбилее белән котлыйбыз! Иҗат уңышлары телибез.



Гәрәй РӘХИМ

МИН БАШКАЧА СӨЯМ

Татар кешесе

Болгарында болганган,
Биләрендә биртелгән,
Сараенда саргайган,
Суварында сызланган –
Синдер, татар кешесе.

Себергә себерелгән,
Чиләбедә чиләнгән,
Оренбурда орылган,
Каргалыда каргалган –
Синдер, татар кешесе.

Мәкәрҗәдә мекердәп,
Истанбулда ысланып,
Үзбәкләрдә үзгәреп,
Кырымнарда кырылып
Беттең, татар кешесе.

Французга яу чаптың,
Германга да яу чаптың –
Ул илләрдә ни таптың?
Күп вакытта үз җиреңнән,
Иделеңнән, үз өеңнән,
Илеңнән колак кактың,
Яугир татар кешесе.

Рудасын да син чаптың,
Күмерен дә син чаптың,
Балыгын да син тоттың,
Нефтесен дә син таптың.
Үз-үзеңә суыгаяк,
Зимагур дип ат тактың,
Шаян татар кешесе.

Мәскәүдә бар үз өең,
Киевта бар үз көең.
Балтыйгында балкыйсың.
Чит җирдә дә туган телне,
Туган көйне ятлыйсың,
Моңлы татар кешесе.

Фин иле, япон иле,
Болгар һәм румын иле –
Барында да килмешәк,
Күчемсәк һәм йөремсәк
Булдың, татар кешесе.

Болай каңгырап йөрмә,
Кайт син туган илеңә,
Борынгылар түренә.
Бит куй Идел җиленә,
Баш куй Болгар җиренә,
Әйдә, татар кешесе!

Уйнагыз, гармуннар

Җырлагыз, гармуннар,
Кошларның җырларын.
Сандугач җырларын,
Карлыгач җырларын.
Ишетсен кешеләр
Дөньяда никадәр
Сөйкемле җыр барын,
Соклангыч җыр барын.

Уйнагыз, гармуннар,
Ярату турында,
Күңелдән шикләрне
Тарату турында.
Җырласын кешеләр
Таң ату җырын да,
Яхшылык җырын да,
Яктылык җырын да.

Тынмагыз, гармуннар,
Иртән дә, кичен дә.
Уйнагыз сагыштан
Көйгәннәр өчен дә,
Бәхеттән куанып
Көлгәннәр өчен дә,
Ил өчен яуларда
Үлгәннәр өчен дә.

Дәүләт теле

Татар теле – дәүләт теле,
Дәүләте – Татар иле.
Татар теле борынгы –
Аңа төрки чагында ук
Бөек тарих орынды.
Татар теле – шигырь теле,

Мәзәк теле, җыр теле.
Илләр гизеп йөрсен ул –
Халыкара билге алган
Ундүрт телнең берсе ул!

Татар теле – татлы тел,
Ул яхшылык яклы гел.
Татар теле – дәүләт теле,
Ул шөһрәтле, шәүкәтле.
Татар теле дәүләтле!

Мәскәүдә

Мәскәүнең нәкъ үзәгендә,
Якын дуста кунакта
Кызыл балык, кара икра,
Ананаслар, банан белән
Сыйланып яткан чакта,

Кинәт кенә сызып-сызып
Сагындыра башлады
Әнкәемнең чуен белән
Мичкә куйган бәрәңгесе,
Парлы өйрә ашлары.

Күрдем Мәскәү урамында
Һинд дус, негр, башканы.
Һәм сагындым гомер буе
Авылымда яшәп яткан
Шук керәшен картларын.

Яңгыр койды. Бөтен Мәскәү
Кулчатырын каплады.
Арыш кыры белән шаулап,
Хәтеремә килеп керде
Туган Шөгер яклары.

Бастым мәрмәр баскычларга,
Күрдем яшел яшманы...
Шунда күргән кебек булдым
Юл читендә тып-тын торган
Татарстан ташларын.

Әй, син, Мәскәү, гүзәл шәһәр,
Ил үзәге, башкала!
Минем туган якка булган
Иң-иң назлы сөюләрем
Бүген синдә башлана.

Әниләр зары

Ирләр ул гел шулай:
Чәй кайнап чыкканчы гына
дип китә дә...
Югала.
Һәм еллар хәбәрләр китерә:
– Билгесез югалды...
– Приказны үтәгәндә...
– Батырлык күрсәтеп...

Малайлар гел шулай:
Чәй кайнап чыкканчы гына
дип китә дә...
Югала.
Һәм көн дә гәзитләр хәбәрләр китерә:
– Тайгада шәһәрләр төзелә...
– Чирәм җир сөрелә...
– Галәмнән әйләнеп кайттылар...

Көненә ничәмә мәртәбә
куела самавыр.
Көненә ничәмә мәртәбә әйтәсең:
– Чәй кайнап чыга бит,
Кайтырлар...
Кайтырлар...

Татар җыры

Офыкларда иңри безнең моңнар,
Илдән илгә яңгрый татар җыры.
Йөрәкләрне җилтерәтеп үтә,
Күңелләрне өтә кайнарлыгы.

Тынып тыңлый аны Себер, Сембер,
Урал, Уфа, Казан, Оренбуры.
Мәскәү, Кырым, Төрек җирләренә
Ак моң булып ята татар җыры.

«Татар бугазы»ннан чыккан бу җыр,
Кичеп Амур, Кавказ, Карпатларны, –
Сәяхәтче Синдбад кебек иңли
Дәрьяларны, илләр, бар якларны.

Тарихтагы күпме бөек эшләр
Онытыла – тузгый хәтер оны...
Тик көчәя генә бара җирдә
Татлы татар җыры, татар моңы.

Тукта... Тыңла... Әнә татар моңы...
Кыйтгаларга иңә безнең җырлар.
Татар бугазыннан чыккан бу көй
Чорлар бугазында мәңге чыңлар!..

Әни кирәк

Бишек тирбәтергә әни кирәк,
Йөрергә өйрәтергә әни кирәк.
Кулына алып чәбәкләргә әни кирәк,
Усал малайларны әләкләргә
әни кирәк.

Ятлар ятим димәсенгә әни кирәк,
Өйләнгәндә киңәшергә әни кирәк.
Дөнья артка типкәләсә дә, әни кирәк,
Хатын сиңа үпкәләсә дә, әни кирәк.

Ә әнигә ниләр кирәк –
Уйлыйбыз шул ансын сирәк.

Мин башкача сөям

Күзләреңне кара димәдем,
Битләреңне алма димәдем,
Иреннәрең чия димәдем –
Мин, ахрысы, бер дә кешегә
Охшаш итеп сөя белмәдем.

Мин башкача сөйдем, ахрысы,
Үзем генә сөя белгәнчә.
Җирдә әле башка беркем дә
Сөя белмәгәнчә, бүтәнчә.

Ләкин мин үкенмим, хәзер дә
Сөю кануннарын эзләмим.
Мин сөям ич сине үземчә:
Күзләреңне кара димичә,
Битләреңне алма димичә,
Иреннәрең чия димичә –
Сөям сине нәкъ син көенчә.

Бүләк

Мин кояшның җиде төсен
Аерып алмак булам.
Җидесен дә, бүләк итеп,
Алдыңа салмак булам.

Яшеле – яшел болының,
Зәңгәре күгең булсын.
Сарысы – сагынуларың,
Агы ак көнең булсын.

Көрәне – икмәгең төсе,
Кызылы – офыкларың.
Карасын да сал сандыгыңа
Һәм аны ачма, җаным.

Чөнки ансы, иркәм, безнең
Аерыласы көн булыр.
Сандыгыңны ачма, юкса
Җирдә мәңге төн булыр.

Гомер

Артта кала кышның бураннары,
Җанга тигән ачы еллар кала;
Юлда кала яшьлек, яулык болгап,
Гомер дигән пар ат алга чаба.

Бар да кала, бар да артка күчә,
Юл буенда өметләрең кала,
Күпме язлар, күпме назлар...
Гомер дигән пар ат һаман чаба.

Гомер дигән пар ат алга чаба,
Үткән кайтмый, яңа таңнар алда.
Еллар чаба, йөрәк түзми яна,
Әйди һаман киләчәккә таба.





Зиннур ХӨСНИЯР

Пединститутның «Илһам» әдәби-иҗат берләшмәсе, студент елларында ук «Ялкын» журналында эшли башлау, армия, Брест шәһәрендә офицерлар мәктәбе… Аннары инде «Татарстан» радиосы, Татарстан китап нәшрияты… Язучы, журналист, мөхәррир Зиннур Хөснияр биографиясендә алар һәркайсы хәлиткеч роль уйный. Күпләр өчен ул, әлбәттә, «Салават күпере» журналының беренче баш редакторы. Заманында укучыларны «Таһир-Зөһрә», «Җүләр чак», «Әбугалисина», «Язучы» газеталарын чыгарып куандырды. Һәм менә ике дистә ел инде «Сәхнә» журналын җитәкли.

Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, Г. Исхакый, М. Җәлил, Ф. Хөсни, Ш. Маннур премияләре лауреаты Зиннур Хөснияр – бик күп күләмле әсәрләр авторы да. «Таң ата да кич була», «Тәгәри китте язмышлар», «Гарасат», «Кичү», «Көмеш чыбыркы» китаплары, «Терсәк сугышы», «Эттән туган», «Хуш, авылым!» романнары, балалар өчен нәшер ителгән китаплары… Күп алар! Язучыны 60 яшьлек юбилее белән котлыйбыз! Игътибарыгызга аның «Хур кызлары» романыннан өзек тәкъдим итәбез.

ЗӨБӘЙДӘ

(«Хур кызлары» әсәреннән өзек)

...Нәкъ чикләвек җыяр вакыт җиткәч, Зөбәйдәгә шәһәргә китеп барырга туры килде. Әнисенә фермадагы урынын биргәч, авылда башка эш калмаган иде. Рәшит Гарипович әүвәл аны бухгалтерлар әзерли торган авыл хуҗалыгы техникумына җибәрергә уйласа да, кызның сәнгатькә сәләте барлыгын искә алып, «Барыбер кайтмас бу авылга кире» дигән фикер белән әлеге тәкъдимен әйтмәде. Ошаткан иде аны рәис, карусыз, тәрбияле, һәр эшкә кулы ятып тора. Алабугадагы мәдәни-агарту уку йортына Зөбәйдәнең үзенең барырга теләге юк; югыйсә аларга әйбәт клуб мөдире дә кирәк. Баксаң, кызның хыялы – консерваториягә имтихан тапшырып карау икән! Атасы шулай дигәч, рәис тә тынычланды һәм паспорт алырга белешмә язып тоттырды. Аның рөхсәтеннән башка паспорт бирмиләр, район белән шулай сөйләшенгән, паспортың булмаса, син шәһәрдә кирәк түгел.

Бәхет басты тагын: әтисе, Казанга чыгып киткәнче, кызын күрше авылга чикләвеккә алып барып кайтырга булды. Күрше авыл дигәннәре – Салкынсу, әнисенең туган авылы. Зөбәйдә кечкенәдән анда еш булды, үсеп җиткәч, әбисенә йорт эшләрендә булышырга да йөрде. Әнисенең энесе өйләнгәч кенә, мондый барулар сирәгәйде, ара-тирә бәйрәмнәрдә әтисе бишекле матаенда гаиләсен бер әйләндереп кайта иде.

Аның каравы, күрше авыл егете, сыйныфташы Гаяз белән элеккегә караганда да ешрак күрешә башладылар. Гаяз колхозның техника паркына эшкә килде, ул читтән торып авыл хуҗалыгы техникумында укый иде. Укыган кеше булгач, кыз хәзер Гаязны буй җитмәслек егет дип уйлый, тик балачак дусты Рафинад та күңелен һаман ымсындырып тора.

Сигезенче сыйныфны тәмамлагач, нәкъ менә Салкынсудан кыз артыннан ике малай-егет күзләрен кыздырып йөри башлады. Рафинадка ияртеп, аны чикләвеккә җибәрә торганнар иде. Рафинад кызлар кебек тыйнак, тәртипле, җитмәсә, күрше малаен әбисе дә ярата. Үскәч, зур кеше булырга теләсәң урысча белем алырга тиеш.

Зөбәйдә Салкынсуга кунакка килгәч, Рафинад кечкенә чагыннан ук аларга йөгереп кереп җитә, чәкәләшмичә бергә көннәр буе уйный торганнар иде.

Әбисе Зөлхиҗә – гыйлемле карчык, гарәп имлясында Коръәнне укый, күп догалар белә. Аның янына кич утырырга урам хатыннары еш керә, Зөлхиҗә аларга «Йосыф» кыйссасыннан өзекләр укый, тегеләре елый-елый тыңлыйлар. Зөбәйдә андый чакта күрше малае Рафинадны да чакыра.

Апалар чыгып киткәч, берсе – мулла, икенчесе абыстай булып та уйнап күрсәтеп, әбиләренең күңелен күрәләр. Әбисе әйтә: «Кызым, шушы вакыттан берничә дога өйрәнеп калсаң, гомер буе рәхәт яшәрсең», – ди. Аның рәхәт яшәү дигәнен Зөбәйдә зур үскәч кенә аңлады: догалар күңелне тынычландыра, бигрәк тә иләс-миләс күңелле кыз баланың рухын дәвалый, хәзерге тел белән әйтсәк, депрессиядән саклый икән.

Сүгенгән кешенең янында да торырга ярамый, бигрәк тә кыз балага, алайса каның карала, ди әбисе. Ә дога канны чистарта икән, нәкъ анар белән хөрмә ашаган кебек була ди, имеш.

Кечкенә чакта Рафинад белән сынау да уздырып карадылар. Беренче биремне җиңел үтәп була, ә икенчесенә нишлисе менә?! Җаен таптылар тагын: авылда бер исерек бар, ул аты-юлы белән сүгенә торган иде. Шуны магнитофон тасмасына яздырдылар. Аннары бүлмәгә юка кәгазьләр телгәләп элеп чыктылар. Кәтүк җебенә бәйләнгән кәгазь тасмаларның канны ничек агартканын-каралтканын белеп була икән. Бүлмәне эчке яктан шартлатып бикләп куйдылар да магнитфонны кабызыдылар. Кәгазьләр кинәт бөтерелә башлады. Икесе чираттан дога укый башлауга, тагын тынычландылар. «Колхуалла...» да калмады, «Фатыйха» сүрәсе дә, башка догалар да. Үз күзләре белән күреп-күзәтеп тордылар, теге тасмалар беркавымнан бөтенләй тынычланды. Кәгазьләрнең дә җаны бар, алар агачтан ясала бит, ә агачның җаны була, дигән иде әбисе.

Зөбәйдәнең тавышы аеруча матур иде, ул көйләп укыганда, Рафинад йоклап китте. Аның сабый бала кебек мыш-мыш йоклап ятканын карап торды да Зөбәйдә, акрын гына килеп битеннән үпте. Тегесе уянмады, кыз икенче битеннән үпте. Рафинад йокламый яткан икән, ул кинәт сикереп торды да, куркынган күзләре белән кызга карап: «Ә хәзер безнең бала булса?!» – диде. Зөбәйдә үзе дә пошаманга төште. Елый ук башлады. Өстәвенә, теге кәгазь тасмалар селкенеп кенә калмыйча бөтерелергә, зыр-зыр әйләнергә керештеләр! Әле ярый әбисе, эшнең нидә икәнлеген аңлап, балаларны тынычландырырга ашыкты. Моннан соң Зөлхиҗә абыстай аларның икесен генә аулакта калдырмаска тырышты.

Ә менә апалар янында утырырга мөмкин иде. Гомер онытасы юк, беркөнне әбисе җәннәт турында сөйләде. Хатыннар сорау арты сорау яудырды, аларга да тыңлап утыру бик кызык булды.

– Теге дөнья, кабер, Кыямәт хәлләре, җәннәт һәм җәһәннәм мәсьәләләре барысы да кеше күзенә күренми торган яшерен дөнья булып тора. Шуңа күрә анда ниләр буласын кешеләр Аллаһы һәм аның илчесе хәбәр иткән гыйлемнәр аша гына белә ала. Бакча буйлап чиста су, сөт, бал һәм шәраб елгалары ага. Яфраклары фил колагына охшаган төрледән-төрле агачлар үсә. Әлбәттә, оҗмах әһелләренең анда өйләре дә була. Пәйгамбәребез аларны: «Кирпечләренең берсе – алтыннан, икенчесе – көмештән, измәсе – исле майдан, ташы – энҗе һәм якутлардан, ә туфрагы шафраннан булыр. Анда кергән һәрчак нигъмәттә булыр, мохтаҗлык күрмәс, мәңге яшәр, үлмәс, киеме тузмас, яшьлеге китмәс», – дип сурәтли.

– Җәннәттә кеше гаиләсе белән бергә яшәячәкме? Анда бала табачаклармы?

– Аллаһ кешене парлы итеп яраткан. Шуңа күрә оҗмахта гаиләсез бер кеше дә булмас. Әгәр кеше дөньялыкта үз тиңен табып, икесе дә иман белән яшәп, иман белән Аллаһ хозурына кайтсалар һәм икесе дә оҗмахка керсәләр, алар анда да ир белән хатын булып яшәячәк. Әгәр икесенең берсе гамәле сәбәпле җәннәткә керә алмаса, җәннәттәгесе башка кеше белән кавыша. Әгәр хатын-кыз ике мәртәбә кияүгә чыккан булса, ахыргы ире белән кала, дип әйтелә. Бала табуга килгәндә, мәңгелек йортта бала тудыру, нәсел калдыру хаҗәте булмас. Шулай да, бик каты теләсә, Аллаһ теләгәнен бирә. Әмма анда ана карынында бала күтәрү, бала тудыру сызлануларыннан, аны тәрбияләү михнәтләреннән имин булачак. Өстәвенә, җәннәттә кешеләр барысы да бер яшьтә, яше, карты юк ди.

– Алайса, безгә түрәләр әйткән «коммунизм» була икән ич инде ул җәннәт дигәннәре! – дип куйды хатыннарның берсе. Икенчесе аның сүзен куәтләде:

– Алайса, без үлгәч кенә килә икән әле ул коммунизм! – диде ул, авызын чапылдатып.

– Ә менә хур кызлары ничек була?

– Хур кызлары – бик чибәр, пакь һәм саф кызлар алар, – диде Зөлхиҗә әби.

Бүгенгедәй хәтерендә кызның: «Әбием, бу китапта бөтен нәрсә дә бармы?» – дип сорады. Кызның һәр сорауга да җавап табарга мөмкинме Коръәндә дип сорыйсы килгәнен Зөлхиҗә күз карашыннан да чамалады. Тик бу хакта сүз куертып тормады: «Бар, кызым», – диде. Әбисе сизгер иде, оныгын нидер борчыганын күреп тора лабаса. Ләкин хәзер үк сорау биреп тинтерәтмәде, бераздан үзе ачылыр дип уйлады. Чыннан да, кызчык күңелендә йөрткән соравын әбисенә чиште.

– Ә нишләп дөньяда малайлар да, кызлар да була ул?

Зөлхиҗә көлемсерәп куйды: оныгын әнә нинди сораулар борчый башлаган. «Ушлы бала булыр, Алла боерса», – дип сөйләнде ул үзалдына. Аннары сүзен дәвам итте:

– Ходай башта җир йөзенә Адәм белән Һаваны яраткан. Адәм – ир-ат, Һава – хатын-кыз...

Тик балага бу хакта озын-озак сөйләп торасы килмәде, иртәрәк әле дип уйлады. Кыз бу җаваптан гына канәгать түгел иде.

– Ә нишләп Адәмне, малайны гына түгел?

– Башта Адәмне яралта. Чөнки дөньяга әүвәл батырлык кирәк була. Батырлык ул – егет кеше, ир-ат.

– Ә Һава нигә кирәк аңа?

– Матурлык булмаса, егетләр батырлык кыла алмый. Менә шул матурлык итеп Һаваны, хатын-кызны яраткан.

Зөбәйдә башка сорау биреп тинтерәтмәде, ул уйга калган иде. Зөлхиҗә абыстай балаларның Коръән сүзләрен тыңлап утыруларын бик ошата. Тик икенче көнне Хатирә апа малаен әбиләр янына кертмәде. Мулла буласы юк әле малаемның, җыен чүбек белән яшьтән үк башын тутырмасын дигән ди, имеш.

Аның каравы, алар урамда уйнаудан туктамады. Зөбәйдәгә иң ошаганы шул: Рафинад аның һәр сүзен карусыз тыңлый, кыскасы, уеннарда Зөбәйдә командир иде. Бервакыт Рафинадны балык тотарга барырга кыстады.

Күрше урам малае Гаяз алардан алданрак төшеп, шактый кәрәкәләр эләктергән. Аның янына барып кармак салырга уйлаганнар иде: «Башка урын беткәнме әллә сезгә!» – дип куып җибәрде. «Рафинадка дигән балык диңгездән килеп җитмәгән ди әле!» – дип тә мыскыл итеп алды. Күрше кызы янында хурлап сүз әйткәне өчен Рафинад батыраеп кармак чыбыгы белән селтәнде:



«Сатып алган урыныңмы әллә!» Гаяз иңбашы аша гына аңа күз салды да: «Бар, анаңа кайтып җыла!» – дип, черт итеп читкә төкереп куйды.

Зөбәйдә хәзер малайларны чәкәләшеп китәр дип курыккан иде, тик Гаяз утырган урыныннан да кузгалмады. Арырак киттеләр. Барганда, Рафинад, кунак кыз алдында кәперәеп: «Курка ул миннән!» – дип куйды. «Алайса, ник киттек соң аннан?! Шыпырт кына бөтен балыкны әләктереп утыра?!» – диде Зөбәйдә һәм, күршесенең җавабын да көтмичә, батыраеп, кире бара башлады.

– Үзең тай моннан, яме! – диде ул килеп җитешкә. Хәзер үк эләгешеп китәрләр шикелле иде. Ләкин Гаяз күтәрелеп бәрелмәде, тыныч кына утыра бирде һәм бераздан барыбер үчен алды:

– Кыз башың белән балык тотып йөрмәсәң! Ирдәүкә! – дип, тагын читкә черт итеп төкереп куйды.

Ә хәзер Зөбәйдәнең Гаязга отыры ачуы килде, барды да тегене суга этеп төшерде. Гаяз кулы белән кызның күлмәк итәгенә ябышып өлгергән иде, Зөбәйдә дә аның артыннан чумды. Рафинад коткарырга ташланасы урынга: «Әни!» – дип кычкырды да ярдәмгә кешеләр чакырырга йөгерде. Зөбәйдә йөзә белми иде, тончыга, бата башлады. Моны күргән Гаяз аны ярга өстерәп чыгарды. Кыз тынсыз ята, коты очкан малай аны селкетергә, чирәмдә әйләндерергә кереште; менә кызның авызыннан шаулап су чыкты. Тик әле ул һаман хәрәкәтсез, дөрес, күзләрен ачкан иде инде, әмма сулыш алуы авыр әле. Гаяз аның аягыннан тотып өскә күтәрде, кызның башы чирәмгә тияртимәс асылынып калды, тагын шаулап су чыкты. Каяндыр ишеткәне булган күрәсең, Гаяз аңа ясалма сулыш алдырмакчы булып, йөзенә иелде, авызын кызның иреннәренә куеп һава өрә башлады. Зөбәйдә күзләрен ачты, юеш күлмәк аша инде беленә башлаган күкрәкләре бер күтәрелә, бер төшә. Гаяз тагын иелде. Янә ясалма сулыш алдырам дигәндә генә, кыз тез башлары белән аның эченә төртте, нишлисең син янәсе, юньсез… Ләкин ул малайга бер дә үпкәләмәгән иде, аның ничек борчылганын ишетеп, белеп ятты. Гаяз, күлмәген салып, шуның белән кызны төрде дә күтәргән килеш өйләренә таба китте.

***

…Чикләвекнең аскы ботакларыннан инде җыеп бетергәннәр, ә өскә Сәбилә апаның да, Зөбәйдәнең дә буйлары җитеп бетми. Аптырагач, үлән арасыннан коелган чикләвекләрне чүпләргә керештеләр. Тик өйлә җитә башлаганда да капчыкларның яртысы да тулмаган иде. Әтиең югалткандыр дип, Сәбилә кайту ягын карады.

Авылга таба тау төшәсе бар, арышлар арасыннан сузылган тузанлы юл буйлап кайтырга юнәлделәр. Артларыннан мотоцикл куып җитте, Зөбәйдә, Гаязны танып, куанып куйды. Ул да чикләвеккә менгән булган, бишегендә чикләвек белән тулы күтәрмә капчыклар ята. Әнисе бишеккә урнашты, Зөбәйдә арткы утыргычка атланды. Сикертмәләрдә очып төшеп калмас өчен, ике кулы белән дә Гаязны биленнән кочакларга туры килә иде. Гаязның киң аркасы артында ышык, ышанычлы иде кызга.

Егет аларны капка төпләренә чаклы кайтарды, капчыкларын да кулларына да тидермичә, өй болдырына үзе кертеп куйды. Гаяз киткәч, карасалар, ни күрсеннәр: аларның яртылаш капчыклары урынына чикләвек тулы үзенекеләрен калдырган. Әтисе капчыкларны күреп:

– Кызым, син тырышкансыңдыр инде! – дип, аны үсендереп тә җибәрде. Кыз кызарган бит очларын күрсәтүдән оялып, яртылаш ачык калган капканы ябарга йөгерде.

***

…Качып китүдән Зөбәйдәне Тәнзилә Гайдаровна туктатып калды. Тәнзилә ханымның кафеда аерым бүлмәсе бар. Аның яшерен ишеге аша турыдан-туры ишегалдына чыгып була. Кафега азык-төлекне дә шуннан ташыйлар. Ул кызны шул бүлмәгә чакырды. Диварга телевизор элengән, рәт-рәт тезелеп киткән экраннар урам якны да, кафе эчен һәм ишегалдын да күзәтеп тора.

– Утыр әле, – диде ул гадәттәгечә боерулы, ләкин йомшак тавыш белән. Тәнзилә – яше утыздан авышкан кара тутлы, коңгырт күзле, зифа буйлы ханым. Аның бәрхет тавышы кызны һәрчак тынычландыра, киеренкелеген бетерә иде.

– Мин сине бер кеше белән таныштырам. Куркасы түгел аннан. Тешли торган гадәте юк. Кыскасы, үзең күрерсең. Акчасы күктән ашкан. Әниеңнең бурычын түләргә кирәк дисең түгелме соң?

Кыз башын какты. Тик барыбер үзенең нинди вазыйфа башкарырга тиешлеген хәзер үк ачыклыйсы килә иде, шуңа күрә, курка-курка гына:

– Ә нинди кеше ул? – дип сорады.

– Бик зур кеше. Бизнесмен. Кобяшвили… «Кобра» дип йөртәләр.

Зөбәйдә дерт итеп куйды, әлеге сүз «кобра елан» дип ишетелде.

– Мин нәрсә эшләргә тиеш булам анда? – дип сорамыйча түзмәде кыз.

– Референт, – диде Тәнзилә Гайдаровна, артык шәрехләп тормыйча. Ләкин кыз «референт»ның ни икәнлеген белми иде, шуңа күрә авызы ачык калды, аңлату кәтте. – Помощница… Секретарь инде, башкача әйткәндә.

Зөбәйдә җиңел сулап куйды. Аның үзләрендә дә рәиснең алгы бүлмәсендә секретарь утырганын күргәне бар. Көнозын машинкада шакылдатып утыра.

– Сер саклый беләсеңме? – дип сорады Тәнзилә Гайдаровна. Зөбәйдә башын какты. – Белсәң – шул: бар нәрсә хакында миңа хәбәр итәсең. Башка сорау бирмә, бу хакта беркемгә дә әйтмәскә! – диде ул боерулы тавыш белән.

Тәнзилә Гайдаровна кызны озата чыкты. Алар кафе ягындагы алгы ишеккә юнәлделәр. Тик кафе эченә килеп керүгә, каршыларына килгән затлы киемле урта яшьләрдәге ханым белән маңгайга маңгай бәрелә язгач, Тәнзилә ханым кызның беләгеннән тотып туктатты да, үзе тегe «мадам»га борылды, нидер аңлатты. Ул сөйләгәндә, бу ханым бик текәлеп Зөбәйдәгә карап торды, янып торган кара күзләре белән кызны баштанаяк тикшереп чыкты. Зөбәйдә җиңелчә генә калтырануын сизде, ничектер хәерле түгел иде бу хатынның карашы. Ул ризалашып ялгышты бугай. Әүвәл авылдаш кызлары белән киңәшләшеп карыйсы булган… Әңгәмәләре озакка сузылмады, «мадам»



Рәсем: Наталья Васильева

кыз янына килде, елмаеп, кулын сузды. Затлы маникюры ук сыер савучы яки кибетче куллары түгел икәнлеген күрсәтеп тора. Кызга тагын бер сынаулы караш ташлады да:

– Бүген машина килеп алыр сине! – диде, артында басып торган озын буйлы егеткә үзләре генә аңлаган ым кагып, Тәнзилә ханым бүлмәсенә кереп китте. Кафе хуҗасы да аның артыннан иярде.

Озын буйлы егет (Зөбәйдә аңа «Бастырык» дигән кушамат та тагып өлгерде), ишекне ачып, кызны урамга уздырды да машинасына таба йөгерде. Зөбәйдә курка-курка гына «Мерседес»ның күн утыргычына чумды... Мондый машиналарны киноларда гына күргәне бар иде аның. Аннан соң, Әсфан Җасминәсенең, калага китеп югалып торып, кире кайткан саен, иренә: «Икенче барганда, «Мәрс» апкайтам әле мин сиңа!» – дип акланганын ишеткәне булды. Кушамат кебек тә тагылып калды әлеге сүз Җасминәгә, авылда бала-чага артыннан «Мәрс» дип кала иде. Авылын искә төшергәч, кызга ничектер рәхәт булып китте; аңлаешсыз, шомлы, куркыныч каладан башка тагын бер дөнья бар ич әле. Аның үз дөньясы. Тик бу уйларыннан бик моңсу булып китте...

Хәзер шул гап-гадәти, бар нәрсәсе дә аңлаешлы булган дөньядан башкасына кереп бара бугай. Әйтерсең, ул көзге томанлы көндә авылдагы йортларының капкасыннан чыгып киткән дә кайда икәнен белмичә бара да бара. Ә алда томан, алда – билгесезлек.

Менә томан сыеклана, еракта, томаннар артында бер яктылык шәйләнә. Әлеге яктылык бераздан чак кына зурая: кызга аермачык булып офиска охшаган бина, аның зур, якты тәрәзәләре күренә. Тәрәзә аша үзен күрә Зөбәйдә: неон утлар белән яктыртылган бүлмәдә бер кыз утыра. Ул әледән-әле алдында яткан кәгазьләргә озын, матур бармакларын тигезеп ала, язу машинкасы туктап тормыйча шакылдый. Янәшәдәге ишектән чыккан озын буйлы, кап-кара мыеклы яшь ир-ат, Зөбәйдә янына килеп, нидер әйтә, кулы белән Зөбәйдәне чәчләреннән сыйпап ала да кире үз бүлмәсенә кереп югала. «Юк, – дип уйлап куйды кыз, – чәчтән сыйпамасын! Сыйпамый торсын әле, орынмый торсын!» – дигән катгый фикергә килде, аннан соң бу кыланышыннан үзе дә көлеп куйды. Шофер егет көзгедән ара-тирә арткы утыргычка сеңгән кызга күз салгалап бара иде; елмайганын күреп, сүз кушасы итте:

– Бәлки, чәйләп алырбыз? Ул общагаңда көтеп тормыйлардыр әле? – диде. Зөбәйдәнең җавабын да көтмичә, кафе каршысына килеп туктады. – Әйдә!

Зөбәйдә берсүзсез аның артыннан иярде. Үзен шушы кешегә ияртеп җибәргәч, шулай тиештер дип уйлый иде – кафега гына чакыра бит ул аны. Кыз, кабаланып, сумкасына тыгылды, арзанлы бисерлар белән бизәлгән акча букчасын алды, акча ягы сай, кефир-батонлык кына иде. Кафеда ашаган өчен түләргә дисәләр? Юк, кайтканда, кефир гына алыр, монда керүдән баш тартырга кирәк. Зөбәйдә ишек төбендә басып калды, Бастырык эчкә узды, ләкин анда озак тормады. Кафедан нигәдер ачулы чыкты, кире утырдылар да тагын кузгалып киттеләр. Беркавым баргач, ташландык бер йортның ишегалдына килеп керделәр. Бастырык арткы якка күченеп утырды һәм, авызын ерып: «Бу машина шуңа да ярамагач», – дип мыгырдана-



мыгырдана, кызга доллар сузды һәм аңа елышты. Зөбәйдә эсселе-суыклы булып китте, бер кулы белән ишек тоткасына ябышты.

– Мин төшәм!

– Аз булса, тагын өстим! Беләсеңме, рубль белән күпме була бу акча?

– Кычкырам хәзер! – диде кыз, кыюланып. Тавышы ят, ачулы иде.

– Кычкырсаң ни! Мин бушка түгел бит! – диде егет тыныч кына. – Башта гына шулай куркыткан буласыз. Акча күргәч, күзләрегез кыза!

Каравыл кычкырудан файда юк икәнлеген сизгән Зөбәйдә кинәт хәйләгә күчте, мондый уйның башына килгәнлегенә үзе дә гаҗәпләнде. – Үзем, орынма! – диде ул, тыныч булырга тырышып. – Үзем чишенәм! Түлке акчаңны кире ал!

Тегесе кулын тартып алып, гаҗәпләнеп кызга карады:

– Бушка гына, что ли?

– Бушка, – дип пышылдады кыз калтыранып. – Только учти, Ира Закировнага сөйләп бирәм! «Ира Закировна» дигәне – бая кафеда очраткан ханым, ул шофёрның турыдан-туры хуҗасы булырга тиеш иде. Эчке сиземләве дөрескә чыкты, Бастырык бу юлы үзе каушап төште. – Кирәкми алайса. Әйтмә только!

Училищеның үз тулай торагы булмаганлыктан, кызларны вакытлыча төзелеш трестыныкына урнаштырганнар иде. Ишек каршына туктауга, Зөбәйдә ашыга-кабалана машинадан төште. Шул чакта тиз генә кереп югаласы калган, тик аның һаман ачуы яман, Бастырыкны шулай тиз җиңә алуына бик аптыраса да, әлеге хис аңа кыюлык өстәгән; үзенчә үч алырга теләгәндәй, машина янына кире килде дә бар тавышына: – Тагын шулай эшләсәң, белеп тор! Ике дә уйламыйм, әйтәм! – дип кычкырды.

«Мерседес» капылт кузгалып китте дә уктай олы юлга таба атылды. Тиз генә ишектән кереп шыласы калган икән шул – тулай торак тәрәзәләре затлы машинадан төшкән кызны бик игътибар белән күзәтә иде бу вакытта. Мондый машиналар сирәк туктый монда яисә алар бу урамнан бөтенләй узмыйлар да.

Бүген башыннан шактый хәлләр үтте. Ул үзенең тәрәзә янында урнашкан караваты янына килде дә чишенмимитми шунда ауды. Тиктомалдан елыйсы килеп китте, түшәмдә куышкан ике тараканны күргәч, бөтенләй үксеп үк җибәрде. Күз алдына әти-әнисе килде. Алар хәзер өйдә чөкердәшеп йөри торганнардыр. Өй җылы, рәхәт. Әти-әнисе өйдә чакта ул тоташ нурлардан гына тора кебек...

***

Бүлмәдәге ике карават та буш. Әдинә әнисе янына авылга кунакка кайтып китте, Майя исә каядыр чыгып югалган иде.

Авылдашлары Майя белән Әдинә, мәктәп тәмамлауга, аның янына чаптырып килеп җиттеләр. Майяның барасы килмәгәндер дә, тик Әсфан абый кызның авылда мүкләнеп ятуын теләми, бәхетен зур калада табар дип хыяллана. Әдинә өеннән үзе чыгып качканга охшаган. Ул атасының авылдагы коттеджында кунак кызы сыйфатында гына. Прокурор атасы, аларны авылга озатканда, шулай дигән, имеш. Әнисе Әлбирә – ерак туганы, ә Әдинә – кунак кызы, имеш. Кайткан шәпкә шулай дип сөйләнгән. Кеше сизмәсен диптер инде. Һәрхәлдә, әлеге беркатлы хәйлә шундук беленде, Әдинәнең прокурор чапанының итәгеннән туган кыз икәнлеген ул кайтышка ук белә иде инде авыл. «Кунак кызы» дигән кушаматы чат ябышып калды. Шушы хәлдән соң Әдинә авылда үзен гомер буе кунак кызы сыйфатында хис итеп яшәде.

Зөбәйдә, коридордагы кухняга үтеп, газга чәйнеген утыртты да, идәндә чабышкан озын мыеклы тараканнарны сытмас өчен, урау юллар белән кире керде. Шулчак ишек шакыдылар, рөхсәт тә сорап тормыйча анда комендант башы күренде, кулында бер бәйләм кызыл розалар иде. Серафима Семёновнаның авызы бияләй булып ерылган, бәйләмне Зөбәйдәгә суза-суза:

– Менә тагын калдырып китте, – диде серле елмаеп.

– Тёть Сима, бүтән алып калмагыз андый чәчәкләрне дип әйттем ич инде!

– И-и-и, җүләр нәрсә! Шундый чибәр җегеттән мондый матур букетны алмыйлар димени! Менә шиколаты да бар! Миңа да бүләк апкилгән...

Үзенә эләккән бүләккә шул рәвешле сөенгән икән бу ачык йөзле, күп сөйләшә торган керәшен хатыны. Зөбәйдә, чәчәкләрне алып, беркавым кайда урнаштырырга аптырап йөрде, чөнки бүлмәдәге бердәнбер вазада Гаяз алып килгән кыңгырау чәчәкләре әле дә булса шиңмәгән. Гадәти чәчәкләр түгел алар!

Гаяздан чыкса чыга инде кызык хәлләр. Зөбәйдә чәчәкләр өстендәге тузан бөртегенә өф иткән кебек кенә булган иде, шулчак кыңгырау чәчәкләреннән зеңгелдәгән тавыш ишетелә башламасынмы!.. Әйтерсең болындагы искиткеч матур зәңгәр кыңгырау чәчәкләре искән җил көенә җырлап җибәрделәр! Зең-зең, зең-зең-зең... Әүвәл диварга эленгән радио дип уйлап, шул якка күтәрелеп карады, ачык форточкалы тәрәзә янына барып, урамны тыңлады, тик тавыш нәкъ менә чәчәкләр бәйләменнән килә иде. Бәйләмне күтәреп караса, сабагында нечкә бакыр чыбык белән беркетелгән нәни генә чип табып алды, баш бармагы чаклы динамик сыман төймәсе дә бар – көй шуннан чыга икән! Һай, күңелләре булган иде шул чакта кызның, нарасый кебек куанды, и сөенде ул бу хәлгә! Бары Гаяз гына булдыра ала мондый галәмәтне! Бүлмәдәш кызларына да тыңлатты, тегеләре авызларын ачып калдылар. Зөбәйдә күз карашларында көнләшү катыш соклану күрде...

Шкафтан банка алып су салды да розаларны шунда утыртты. Аннан соң озак кына уйланып торды: розалар затлы, кыйммәтле, аларны вазага утырту дөресрәк булырга тиеш сыман, тик зәңгәр кыңгырау чәчәкләре үзенә күрә матур, алар аңа ни өчендер кадерлерәк тә, якынрак та. Бәлки, туган ягы кырларыннан җыелгангадыр? Тик сәбәп ул гына микән?

Бүлмәгә хуш ис таралды. «Тагын Рафинадтыр инде?» – дип, бәйләм эченнән берәр язу-мазар эзләргә кереште. Тапмады. Чибәр егет тагын кем булсын инде, мыек үстереп җибәрсә дә, кызларныкы шикеле аксыл, мөлаем йөзле бары ул гына булырга мөмкин. Тик кызның күптән Рафинад белән күрешкәне юк.

Узган ялда Гаяз килде. Колхозның иске «УАЗ»игында. Кинога бардылар. Тулай торакка кадәр генә озатырга тиешле егетнең калада кунар урыны юк икән. Апасы гаиләсе белән ялда ди. Кылт итеп исенә төште Зөбәйдәнең: күрше бүлмәдә кранчы егет Азамат ялгыз башы яшәп ята ич, очрашканда сүз алышалар. Азаматның Әдинәгә күзе төшеп йөри. Гаязны шунда кундырырга уйлады кыз. Вахтада комендант Сима үзе иде бүген. Берсүзсез кертеп җибәрсә дә, икенче көнне Зөбәйдәнең ялгызын очраткач: «Ул егет түгел бит чәчәк китерүче?!» – дип, гаҗәпләнгән кыяфәт чыгарды.

– Курьер аша җибәрә ул, тёть Сима! – дип хәйләләмичә булдыра алмады кыз.

Ул Гаяз белән кайтып керүгә, кызлар шыбырдаша башлады: минем тегендә барасым бар, ә мине теге чакырган иде, бүген кунарга да кайтып тормыйбыз, имеш. Әлеге имеш-мимешләргә Гаяз үзе нокта куйды:

– Кызлар, урамда буран, өйдә генә утырыгыз! Мин Азамат янына! – дип кырт кисте. Гаяз алып килгән авыл күчтәнәчләре белән бергәләшеп чәй эчкәч, Майя, сылтау тапкан булып, барыбер чыгып китте, Әдинәнең дә ашыгыч рәвештә каядыр барырга тиешлеге исенә төште.

Аерым бүлмәдә икәү генә калгач, ничектер уңайсыз булып китте. Гаяз үзе дә сүзсез калды, аңа кадәр сөйләшеп туя алмаган Зөбәйдә дә тын калды. Тик Гаязның уйлары башкада икән, кызлар барында ук аның тәрәзә төбендәге пыяла банкада утырган розаларга күзе төшкән. Ул бүләк иткән кыңгырау чәчәкләре дә тора вазада. Икесе генә калгач та бу хакта сүз катмады, сорау биреп төпченмәде:

– Аһ, исләре дә тәмле икән! – дип кенә куйды, аннары капылт кына борылды да корбанына ташланган юлбарыс кебек Зөбәйдәгә якынлашты. Кызны күтәреп алды һәм гайрәтле, ләкин таләпчән тавыш белән:

– Зөбәйдә, мин укып бетергәч, өйләнешәбез! – диде. – Минем шундый план!

Кыз башын егетнең күкрәгенә яшерде һәм сулкылдап елап җибәрде. Гаяз бер кулы белән магнитофон төймәсенә басты да, шуннан агылган көйгә вальс биегәндәй, бүлмә буйлап кызны күтәреп әйләнә башлады. Гүя алар түгел, алар тирәсендә җиһан үзе бөтерелә иде.

Гаязның тәкъдименә каршы ни булса да әйтергә кирәк иде бит инде, Зөбәйдә, шуны уйлап, егетнең кочагыннан шуып төште һәм:

– Беләсең, Гаяз, андый вакыт түгел ич безнең әлегә... Туйлар итеп йөри торган чак түгел диюем. Әнинең бурычлары... үзең дә беләсең, – дип пышылдады. Чак кына үпкәсе дә калган иде егеткә. Үзенең планнарын әйтте, укып бетергәч, диде. Ә Зөбәйдәнең хыяллары хакында хәтта сорашып та тормады.

Кызның үпкәләвен тавышыннан ук сизде Гаяз. Әмма үзен барыбер хаклы дип исәпли. Алар киләчәктә барыбер аның планнары белән яшәргә тиешләр.

Бәхеткә, шулчак ишек шакыдылар. Чөнки Зөбәйдәгә Гаязның ихтыярына каршы килү бик кыен, хәтта мөмкин булмаган гамәл шикелле; җитмәсә, аларның гаиләсендә ир-ат сүзен аяк астына салып таптау юк. Аның бу аклап маташуы болай гына, бернинди сәбәп тә түгел, чүп кебек кенә, уч төбенә алып өф итүгә, җилгә оча торган күбәләк шикелле генә... Иң әһәмиятлесе – Зөбәйдә әле һаман ачык кына карарга килә алмый, йөрәгендә ялкын, күңелендә давыл кузгалмаган, ләкин сизә, андый гайрәтле дә, татлы да булган вулкан уянырга маташа. Кем аны беренче булып уятыр, Рафинадның кызыл розаларымы, Гаязның көчле, ышанычлы күкрәгеме? Ишек ачылды, Әдинә икән.

– Мин кайттым, – диде ул гаепле тавыш белән. – Өйдә түгел иде подружкам.

Икесе дә аны куанып каршы алдылар. Тагын бер кат утырып чәй эчтеләр. Әдинә үз караватына ауды һәм йокымсыраган тавыш белән:

– Иптәшләр, минем йокы каты, мине монда бар дип тә уйламагыз! – диде. Һәм бераздан сулкылдый-сулкылдый үксергә кереште:

– Мин өйрәнгән инде, балачактан ук. Авылга килгән һәр кунак абый безгә туктала. Төне буе, төне буе...

Гаяз курткасын эләктерде дә мәче кебек сак кына басып чыгып китте. Зөбәйдә егетне озата чыкты. Алар балконда шактый озак серләшеп тордылар.

– Карале, шәһәрдә йолдызлар юк дип йөри идем. Бар икән ич! – диде кыз, шатланып.

– Нишләп булмасын. Алар барысын да күреп тора.

– Барысын-барысын дамы? – дип көлде кыз. – Безне дәме?

– Безне алар әллә кайчан күреп алды инде.

– Нәрсә диләр безнең турында?

– Зөбәйдә бигрәк чибәр кыз икән, диләр!

– Оялтасың, – диде кыз акрын гына һәм башын Гаязның күкрәгенә куйды.

Гаяз кинәт:

– Зөбәйдә, син бик матур җырлыйсың бит, музыканы да чамалыйсың. Әйдә икәү бергә җыр язабыз! – дигән тәкъдим ясады. Әлеге фикер Зөбәйдәгә дә кызык булып китте.

– Мин риза, – диде ул шатланып.– Туйда... Кыз тукталып калды, йөзе комачтай кызарды, колаклары ут булып янды. Гаяз, аның сүзен элеп алып:

– Ие инде, безнең туйда җырларбыз! Сүзләрен үзем язам. Син – көен.

– Риза, риза! – дип куанып кабатлады Зөбәйдә.

– Менә тыңла, алайса, беренче куплет әзер дә инде:

Мәхәббәтнең төсе булса мәгәр, / Синең күзләр дияр идем мин. / Сиздермичә, белдермичә генә / Күңелемә үтеп кердең син.

Покага шул.

Сүзләр Зөбәйдәгә бик ошады.

– Ә калган сүзләре?

– Уйлыйм, эзлим.

– Алайса, мин дә көй эзли торам. Уйлап тапкач, калган сүзләрен әйтерсең! – диде кыз, Гаязга сыенып.

Гаяз төнге күктән чекерәеп үзләренә карап торган йолдызларга күз кысты. Алар шул көнне беренче мәртәбә үбештеләр, һәм яңа җырга берсе сүзләр, икенчесе көй эзләргә сүз куештылар...

PRESSA

Кадерле «Сөембикә» редакциясе!

Без яшь чакта абруйлы, *дәрәҗәле саналган һөнәрләрнең хәзер кыйммәте югалып бара. Хәтерлисезме, безнең әниләр сыер савучы булып эшләгән елларны?*

Мөслим районында урнашкан Карл Маркс исемендәге күмәк хуҗалыкта хатын-кызлардан торган сыер савучы коллектив бар иде. Алар барысы да сугыш елы балалары: әнием Морзаханова Лиза, Насретдинова Флера апа, Шакирова Нәсимә апа, Нурмөхәмматова Зәйтүнә апа, Ганиева Әлфия апа, Әхмәдуллина Әзһәрия апа.

Бу кызлар, сайлаган һөнәрләренә тугры калып, кырык елдан артык сыер савучы булып эшләделәр. Аларның хезмәт кенәгәләрендә бер генә эш урыны язылган: «Карл Маркс исемендәге колхоз – сыер савучы». Тулысынча кул хезмәте кулланылган, эшләре авыр булган югыйсә. Каядыр читкә китәргә, башка юнәлештә эшләргә, эш алыштырырга уйлап та караганнары булмагандыр. Чөнки үз урыннарында кадерле, хөрмәтле кешеләр булган алар.

Эш сәгатьләре иртәнге дүрттән башланып кичке сигезгә кадәр дәвам иткән. Ял көннәре дә булмаган. Авырып киткәндә яки бәби алып кайтканда берсен-берсе алыштырып торганнннар, сыерларын үзләренеке янына кушып куйганнар. Һәммәсенә 20–25 баш сыер беркетелгән, һәр сыерның үз исеме бар иде. Әни аларга Шомырт, Бәләкәч, Апрель дип исем кушканын хәтерлим. Кыш көннәрендә су җылытып, сыерларга саламнан башак ясап биргәннәр, силосын, сенажын салганнар, урыннарын чистартканнар.

Җәй көннәрендә сыерлар җәйләүгә чыккач, эшләре бераз «җиңеләйгән». Кулларына чиләк тотып, көненә өч мәртәбә сыерларын саварга йөргәннәр. Сөтне сөзеп, тимер бидоннарга салып, үзләре шул бидоннарны йөк машиналарына төяп, районның сөт эшкәртү заводына озатканнар.

Шушы эшләре, үз йорт-хуҗалыклары белән генә чикләнмичә, җилкәләренә башка вазыйфалар да алганнар әле. Халык сүзен җиткерүче, алдынгы фикерле җәмәгать эшлеклеләре дә булганнар. Шакирова Нәсимә апа – биш ел буе район советы депутаты. Насретдинова Флера апа, алдынгы сыер савучы буларак, район делегациясе белән Куба халык республикасына бара. Минем әнием Морзаханова Лиза хезмәт ветераны дигән мактаулы исемгә лаек була. Әнием, Әзһәрия апа, Әлфия апа әле бүген дә Үрәзмәт авылында акрын гына үз көйләренә яшәп яталар. Бик тыйнак апалар. Хәлләрен белешсәң: «Аллаһка шөкер, пенсиябез бар, авылда кибет эшли, медпунктыбыз бар. Иң мөһиме – өебездә газ булдырган өчен Минтимер Шәриповичка чиксез рәхмәтлебез!» – диләр.

Фидакарь хезмәтегез өчен үзегезгә бик зур рәхмәт, апалар!

Светлана ШӘМСЕМӨХӘММӘТОВА.
Мөслим районы.

Безнең милләттә телне бозу мисаллары бик күп очрый. *Ана телендә сөйләшмиләр дип, балаларның киләчәге өчен борчылган булып йөрибез. Бездән үрнәк алган яшь буын каян килеп туган телен белсен инде?*

«Университет бетергән», «институт бетергән», дип әйтәбез еш кына. Ягъни укыган кеше югары уку йортын бетереп, юкка чыгарып киткән була инде. Фәлән югары уку йортында укып, танылык алып чыккан дип әйтү дөрестер бу очракта. Җөмһүриятебезнең хөкүмәт бинасын Министрлар Кабинеты дип атыйлар. Шулхәтле зур бинаны ничек итеп кабинет дисең инде? Татарстан җөмһүрияте хөкүмәте дип әйтергә кирәктер, бәлки.

Менә шундый хәлләрдән соң минем күңелемдә нишләп без шундый дигән сорау туа. Кайбер милләттәшләребезнең ана телен санга сукмауларымы, кайберәүләрнең артык «белемле» булулары нәтиҗәсеме, «үгез үлсә – ит, арба ватылса – утын» кебек битарафлыкмы? Телебезне бозып, аны хөрмәт итмәгән һәм сакламаган өчен мәңгелеккә киткән әби-бабаларыбыз да рәнҗеп ятадыр кебек тоела. Дөньяга килгән һәрбер зат үзенең ана телен камил

Фото: Анна Арахамия

белеп, аны сакларга да, үстерергә дә, якларга да бурычлы.

Телне бозуга кайбер кешеләр аеруча зур өлеш кертә кебек. Общежитие дигән урыс сүзен алыйк. Берсе моны «тулай торак» дип тәрҗемә иткән дә, шуннан кулланылышка кереп киткән. Татар телендәге «тулы» сүзе берничек тә русча «общий» дип тәрҗемә ителми инде. Общеобразовательная школа – гомуми белем бирү мәктәбе булган кебек, общежитие да гомуми торак булырга тиештер. Ягъни, күп кеше яши торган урын. Ни кызганыч, Казанның күпме югары һәм махсус урта уку йортлары студентлары яши торган гомуми торакларның элмә такталарында «Тулай торак» дип язып куелган. Бу күренешне бит читтән килгән, татар телен камил белүче кунаклар да күреп гаҗәпләнүләре бар.

Төрле оешмаларда хезмәт итүче белгечләр, җитәкчеләр, хәтта мәгълүмат чараларындагы кайбер хәбәрчеләр дә русча сүзләрне еш куллана. Производство, управление, управляющая, начальник, холодильник, кресло, крестьянин һәм башкалар. Җитештерү, идарә, идарәче, башлык, суыткыч, кәнәфи, игенче, терлекче дип, нишләп үзебезнең сүзләрне кулланмаска?

Мине тагын сүзлекләр чыгаручы кайбер галимнәрнең җавапсызлыгы нык борчый. Ул сүзлекләр тузан җыеп ятар өчен түгел, кулланыр өчен зур суммалар сарыф итеп чыгарылган бит. Ләкин аларда күп сүзләрнең тәрҗемәсе урынына шул ук русча сүзләр язылган. Диванның тәрҗемәсе диван һәм кәнәфи, креслоныкы – кресло һәм кәнәфи дип тәрҗемә иткәннәр. Берсендә хәтта креслоны – култыклы урындык, икенчесендә кәнәфине канапе дип урысчага тәрҗемә иткәннәр. Кирәк бит шулкадәр җавапсыз булырга. Нишләп безнең төрле әйберләрнең, җиһазларның милли телебездә исеме юк? Сүзлек төзүчеләр алда чыгарылганнарын күчереп кенә утыралар сыман. Сүзлекләрдә мөхәррир – редактор бар, кырып эзләсәң дә, редакциянең тәрҗемәсен табып булмый. Башка милләтләрнең бөтен сүзләре дә бар, рус теленә мохтаҗлык юк. Ә мең еллык әлифбасы булган безнең милләттә гел рус сүзләре.

Мине борчыган төп сәбәп – шушы түбән сыйфатлы, кешенең ихтыяҗына җавап бирә алмый торган сүзлекләр ярдәмендә милли сүзләребезне җуеп, телебезне ярлыландырып, руслашып бетмәбезме? Ничек милләттәшләребезне ана телебезне яратырга өйрәтергә? Әлбәттә, иң беренче булып бу мәсьәләнең башы гаиләгә барып тоташа, аннары мәгариф хезмәткәрләреннән тора. Әмма шунысын истә тотарга кирәк: теләге булган кеше берничә тел белә бит.

Телне саклау, аны үстерү буенча кануннар кабул итәргә, бозган очракта җавапка да тартырга кирәктер.

Илгизәр ГАЛИЕВ.
Тәтеш районы.

Тугызынчы дистәне ваклаган әбиләр киенү, ясану, бизәнү, үз-үзен бик купшы тоту чире белән чирли башлады бит әле.

Күз явын алырлык итеп шулкадәр бизәнәләр ки, хәтта аларга элек патша-солтан сарайларында яшәгән 12–16 яшьлек кызлар да шаккатырлар иде. Бу киемнәр милли кием дә түгел, кайсы милләткә караганын төгәл әйтү дә мөмкин түгел. Башкалардан аерылып торырга кияләрдер инде бу купшы челтәрле калфакларны, кыргый җәнлек, кошкортлар сурәте белән бизәлгән шарфларны...

Коръән аятенең берәр аңлашылмаган сүзен кайда, ничек кулланырга дигән булып, мулланың игътибарын үзенә җәлеп итәр өчендер инде дип уйлап куям кайвакыт. Андыйлары да бар бит араларында.

Менә шулай купшыланып йөреп, диндар булып кыланып, утырып кайткан уллары белән масаеп йөрүчеләрне дә беләм мин хәтта! Алай гынамыни әле, күрше-тирә карт-карчыкларны малайлары белән өркетеп, куркытып яшиләр... Элек хурлык, оят дип бәяләнгән гамәлләр хәзер горурлык булган аларга. «Улым дусларына гына әйтер, хәзер килеп сабак укытырлар!» Яисә: «Малайга бер генә әйтермен, өеңнең көлен күккә очырыр!» – дип яный шул әбиләр. Куян тиресе ябынган явыз ерткыч дими, кем дисең инде мондый әбиләрне.

Рәшит НУРГАТИН.
Казан шәһәре.

Токиода узган Олимпия уеннарында алтын медаль яулаган Татарстан кызы – рапирачы Марта Мартьяновагы Казан аэропортында каршы алганнарын күреп, аның өчен дә, әнисе өчен дә сөенеп йөрдек.

Ул кызның тормыш юлын, әтисез үскәнен белгәч, күз яшьләрен тыю да мөмкин түгел иде. Күпме хезмәт, тырышлык кирәк бит бу дәрәҗәләргә ирешер өчен. Ә бит безнең спортчыларны әләмсез, Россиягә кагылышлы булуларын күрсәтүче атрибутларсыз гына керттеләр Олимпиадага. Ярый әле җитәкчеләр, бернигә дә карамастан, катнашырга дигән карарга килде.

Безнең күршедә яшәүче малай 5 яшеннән хоккей белән шөгыльләнә. Иртәнге алтыда олы гына сумкасын сөйрәп тренировкага китә инде ул. Аннары – мәктәпкә, кич тагын тренировкага бара. Дәресләренә кайчан әзерләнәдер бу бала, йокы да күрмидер, дип, балкон тәрәзәсеннән карап калам.

Иң югары дәрәҗәле ярышларга әзерләгер өчен, бу балалар тормышларын спортка багышлый, балачакларыннан мәхрүм булып, көн саен тренировкаларга йөриләр бит. Балачактан илебезнең данын яклыйлар, сәламәтлекләренә дә зыян киләдер кайвакыт. Марта кебек геройларча ил данын яклаган кызларыбыз, егетләребез булганда безне беркем дә аяк астына салып таптый алмас. Әләмебез күтәрелмәсә дә, гимныбыз яңгырамаса да, бу патриот спортчыларның Россиянеке икәнен бөтен дөнья белеп торсын!

Гөлназ ХӘБИБУЛЛИНА.
Казан.

Хөрмәтле укучыларыбыз! Сездән хатлар көтеп калабыз. Безнең адрес: Казан, Декабристлар урамы, 2. e-mail: ssuum@yandex.ru

САГЫНАЛАР СИНЕ,



Эльмира
ЗАКИРОВА

«И-и-и гомерләр... Мин бит Ландышның соңгы пациенты булдым. Бүгенгедәй күз алдымда: кич иде инде. Мине УЗИдан карады. «И-и начар күренә бит!» – дип өзгәләнде. Алайса иртәгә яңадан килермен, дидем. «Юк, мин бүген соңгы көнемне эшлим», – диде. Ире белән баласы килгәннәр иде. Алар тәрәзә янында – урамда. Ул, торып, тәрәзәне ачып аларга нәрсәдер әйтте, нәрсәдер эшләргә кушты. Шундый шат иде. Көлештеләр. Шунда аның авырлы икәнен күреп алдым. Декретка китә икән дип уйладым. Аның вафатын ишетмәгән идем. «Сөембикә» журналын укыгач, барысы да аңлашылды. Инде 18 ел гомер үткән. Урыннары җәннәттә, җаннары рәхәттә булсын!»

«Эльмира, бу язманы укыган көннән алып, Ландыш йөрәк түрендә. Илһам, Искәндәр, Ислам язмышларын беләсе килә. Бу язма чыккан журналны еш кулыма алам...»

«Йөрәгем телгәләнеп, елый-елый укыдым. Гаиләсенә, әти-әнисенә, туганнарына Ходай сабырлык бирсен.»

«Яшьләрем ага... Шундый авыр укырга... Нык сабырлык телим якыннарына.»

**«Бу дөньяның бар чәчкәсе – сиңа!» Ул чакта язмамның исеме шулай атала иде. Бәлки, ул тагын хатирәләрне яңартыр? Инде еракта калган язмыш, вакыйгаларны кабат исегезгә төшертер? Моннан шактый еллар элек, 2003 елның мартында «Сөембикә» журналына бер гаилә язмышы турында язган идем. Табибә Ландыш, ашкынып, өзелеп сагынып, туасы баласын көтә. Көндәлегендәге кичерешләре меңләгән хатын-кызларга бик тә таныш, бик тә якын. Никадәр өмет, хыял, ярату, яшерен серләр бөркелә ул юллардан! Әмма көндәлекнең дәвамын – бәхетле әни кичерешләрен без беркайчан да укый алмыйбыз инде. Нарасые дөньяга аваз салуга сөенеп, балага сөеп багарга гына өлгерә ул – санаулы минутларда мәңгегә күзләрен йома...
Бу – 2002 елның салкын декабре...
Яңа туган баланың язмышы ничек булып бетте? Ул бала кемгә әни дип дәште? Ире белән улы Искәндәр бу кайгыны ничек күтәрә алды?.. Шулар хакында сорап, редакциягә бик күп хатлар килде, телефоннардан шалтыраттылар. Һаман кызыксыналар, һаман язалар. Журнал язмасы «Сөембикә» сайтында урын алгач, күптәнге яралар кабат яңарды. Комментарийлар шул хакта сөйли.**

Ландышны, аның гаиләсен яхшы белгән кеше буларак, тагын кулга каләм алдым... Өстәлемдә – Ландышның миңа биргән соңгы бүләге: фирүзә кашлы йөзек, алкалар... Аңа аларны ире Илһам каяндыр алып кайткан иде. Бер алды, бер куйды, яратып тагып карады алкаларын. Яшермим: мин дә кызыгып, сокланып кулларымда тотып тордым. Очратсам, үземә дә шундыйларны алам, дидем. «Кайчан да булса бу алкаларны, бәлки, киленемә бүләк итәрмен. Ләкин кайчан? Искәндәр әле үзе дә бала гына...» – дип елмайды ул. Ә соңгы күрешүебездә: «Эльмира апа, теге вакытта ошатып калдың, сиңа булсын әле...» – дип, йөзек, алкаларын миңа тоттырган иде. Мин ул ядкарьне Искәндәрнең Диләрәсенә – Ландышның әле хыялында гына яшәгән килененә тапшырырмын.

Искәндәр... Ул инде хәзер ике бала атасы. Тарих, хокук белеме, җәмгыять белеме фәннәре укытучысы.

Исламга – 18 яшь! Студент, ТИСБИда укый.

Илһам белән шәфкать туташы Мөслимә бергә яши башлаганга да инде 15 ел...

Теләнче Тамак – бар да җыелып кайта торган рәхәт бер җир.

Кулга каләм алганчы, һәркайсы белән тагын сөйләшәм, истәлекләргә чумам...

ЛАНДЫШ!..



Фото: www.pixabay.com

Балага бит әни кирәк!

(Илһам сөйли)

Ландышны югалту хәсрәте белән улыбыз туу шатлыгы берничек тә бергә сыеша алмый иде. Сагынып көткән бәләкәчебез дөньяга аваз салганда, әнисе мәңгегә күзләрен йомды. Үзем туктаусыз: «Улыбыз туды!» – дип еламсырап кабатлыйм да, «Их, Ландыш, Ландыш!..» – дип, үксеп елыйм. Өнме бу, төшме – күңел һич кабул итеп бетерә алмый. Куркыныч төш булса да түзәр идең, өн бит бу! Искәндәр бертуктаусыз шыңшый. «Әнием кайчан кайта, әтием? Кайчан? Кайчан?» дигән соравы йөрәкне чәнчеп-чәнчеп ала. «Әниең үлде» дип әйтергә телем әйләнми. «Кайтыр, улым... Хәле авыр... Ул әле реанимациядә», – дигән изге ялган килә телгә...

Ул эшләгән поликлиниканың урам баскычыннан ук кызыл канәферләр сибелгән... Ак халатлы табиблар, шәфкать туташлары озатырга чыккан... Бер көнлек

Сабыебызны күргән саен сагышлы сөенечкә батам. Бәхетле бәхетсезме мин, бәхетсез бәхетлеме?

улыбызны роддомда калдырып торып, декабрьнең чатнама салкын кичендә Теләнче Тамакка кайтыр юлга кузгалабыз. Ландышны җирләргә... «Әнием!» – дип ачыргаланып кычкырып, Искәндәр машинадан төшә, чарасыз калып, поликлиникага таба йөгерә... Кайсыдыр, аны кочып, кире машинага утырта... Бөтенесе дә кинодагы сыман күз алдыннан шуып үтә...

...Капкалары каерып ачып куелган. Көтәләр... Кызларын соңгы юлга озатырга... Ландышның әтисе белән әнисе каршына атлыйм... Бер сүз дә әйтә алмыйча тагын елыйм...

...Төрле мәшәкатьләр белән көн тиз уза. Ә төннәрен елап чыгам. Балаларымны, үземне, Ландышны жәлләп елыйм... Мин инде башка өйләнмәскә, дөньяны үзем алып барырга карар кылдым. Исламны Чаллыда Ландышның абыйсы Ришат белән җиңгәсе Люция, апасы Гөлшат белән җизнәсе Дамир алмашлап карыйлар. Искәндәр минем янда. Боегып, бөрешеп калган. Көн саен мәктәпкә озатып калам, каршы алам. Кая да булса алып барырга, күңелен күтәрергә тырышам. Ул гел моңсу. Яллар җитүгә, Чаллыга кайтабыз. Ислам кулга да тими анда: Ришат, Гөлшатларның балалары күтәреп кенә йөриләр.

Ә бер кайтуда Ришат: «Илһам, болай булмый! Сиңа өйләнергә, тормышыңны җайларга кирәк. Ә Исламны үзебезгә уллыкка алабыз, Люция белән шулай килештек», – дип, тәмам өнемне алды! Күз алларым караңгыланды. Ярсудан шартлар хәлгә җиттем! Ничек? Кем рөхсәте белән? Ул бит минем бала! Кызулык белән нарасыемны кочагыма алдым да: «Улымны беркемгә дә бирмим!» – дип дулап чыгып киттем. Кайнарлыгым сүрелгәч, баланы тагын әнисе авылында калдырдым... Кайталы-китәле йөреп, өч ел узды...

Көннәрдән бер көнне күршебез Тәбриснең хатыны Резеда туктатты. Хәл-әхвәл сорашкач: «Сиңа өйләнергә кирәк, Илһам», – ди. «Юк, өйләнмим. Мин шулай хәл иттем инде. Хатын-кызлардан да остарак, тәмлерәк пешерергә өйрәндем. Керләрне хатын-кызлардан да чистарак юам. Өйдә тәртип!» – дип кырт кистем. Таныш-белеш, бергә укыган дуслар төрле кызларга димләп карады. Кияүгә чыкмаган курсташ кызлар да бар икән... Берсенә дә күңел ятмый. «Син өйләнми дә яшәрсең, ә балага бит әни кирәк! – дип, һаман үз сүзеннән кайтмады күршем. – Бер акыллы хатын бар... Мөслимә исемле. Менә телефон номеры. Шалтырат әле. Ошатырсың, бәлки...»

Телефон номерын ничек кесәгә салган булсам, шулай оныттым да. Айлар узды. Тагын Резеда очрый. «Син телефон номерын алдың да бит... Һаман шалтыратмагансың! Ымсындырып куйгач, көтә бит ул. Сузма...» – ди.

Тәвәккәлләп, шалтыраттым. Очраша башладык. Ягымлы. Чиста-пөхтә. Аш-суга да оста... Өйгә алып кайтырга ашыкмыйм һаман. Анда – Искәндәр. Анда – Ландыш рухы: аның фотолары, гөлләре, яраткан песие... Аның куллары кагылган тәлинкә-чынаяклар, сөлгеләр, тәрәзә пәрдәләре... Күлмәкләре... Ул теләгәнчә урнаштырылган диван...

Мөслимә дә ашыкмый. Хатын-кыз сиземләве белән нәрсә яраганын-ярамаганын белеп, тоеп тора, ахрысы. Үзе дә ике бала анасы бит... Бераздан килеп, балаларга ашарга пешерә башлады. Тиз генә идәннәрне юып чыга, бүлмәләрне җыештыра... Искәндәрне якын күреп җайлап сөйләшә. Яраларына кагылмаска тырыша... Көннәрдән бер көнне Искәндәр үзе сүз башлады: «Әтием, Мөслимә апа әйбәт бит, өйлән аңа», – ди. Искәндәрнең сүзе хәлиткеч булды: Мөслимә бездә калды.

Һәм 15 ел инде бергә без

(Мөслимә сөйли)

Икебезгә дүрт бала безнең: Илһамның ике баласы, минеке – икәү... Кызым Наилә авыл хуҗалыгы институтының экономфагында укыганда ук кияүдә иде инде, улым Марат спортфак студенты ул чакта... 14 яшьтән хоккейда инде ул. Хәзер чирәмдәге хоккей буенча яшьләр җыелма командасы капкачысы. Күп тапкырлар Россия чемпионы... Ике балам да мөстәкыйль булып үстеләр. Өченче баланы бик тә табасым килә иде. Аллаһтан гел сорадым. Исемем Мөслимә – мөселман хатын-кызы дигән мәгънәне аңлата. Тарихы кызыклы гына аның. Әнинең Тәслимә дип куясы килгән. Радиодан Сарман, Мөслим районнарында урып-җыю турында сөйләп яталар икән. Әти тоткан да Мөслимә куябыз, дигән. Хәзер дә Илһамнар ягына кайтсак: «Мөслимә дә кайткан Мөслимгә», – дип, якын итеп каршы алалар. Шулай язгандыр инде... Ислам исеме дә динебезне зурлап куелган... Аллаһы Тәгалә миңа шушы баланы өенчесе итеп биргәндер, дим. Ислам – «әни», дип, Искәндәр «Мөслимә апа», дип эндәшә. Баштарак икесе дә «апа», дип дәштеләр. Ислам: «Искәндәр абый, әйдә инде Мөслимә апага әни дип әйтик», – дип бер әйтте, ике әйтте... Ә абыйсы дәшми... Аңлыйм, аңламаган кая! Әнисе бит – Ландыш! Ә Исламның, башка малайлар-кызлар кебек, авыз тутырып, иркәләнеп, кирәк чакта яклау эзләп, «әни» дип әйтәсе килә! Ул балалар бакчасына йөри иде. Көн саен иртән бакчага илтәм, кич алып кайтам. Бала миңа тәмам ияләште. Мин күренүгә үк, каршыма йөгереп килеп кочагыма ташлана. Ә бер көн минем өчен могҗизага тиң булды: Ислам бакчадан кайтканда миңа «әни» дип дәште! Баксаң, тәрбияче апалары әниләргә багышлап кечкенә дәрес үткәргән икән. Әниләр сезгә тәмле ашлар пешерә, авырсагыз, төн йокламый янгызда утыра, аларның сүзен тыңларга, әниләргә булышырга кирәк, дип аңлаткан. Бала шулкадәр сусаган, тансыклаган икән шушы сүзгә! Ислам юл буе: «Әни, әни», – дип кайтты. «Әни» сүзе һәр җөмләдә, һәр сорауда кабатлана иде.

Мин дә: «Әү, улым!», «Әү, балам!» – дип, аның аркасыннан сөеп куям, учымдагы нәни кулларыннан чытырдатып тотам. «Ислам» яки «балакаем» дип эндәшүгә һич ризалашмады. Шундук: «Юк. Улым!» – дип төзәтә иде.

Мөслимгә кайтышлый беренче тапкыр Ландышлар авылына сугылып чыгуны бик дулкынланып кабул иттем. Әтисе, әнисе, апасы, абыйсы – барысы да шунда. Миңа сынап карыйлар. Бәлки, кызларына охшаган якларымны да күрәселәре килгәндер, кем белә... Үземне кайнана йортына аяк баскан килендәй хис итәм. Ландышның апасы Гөлшатның сынаучан кырыс карашын тойдым... Юк, гаепләмим, аның халәте аңлашыла инде! Исән булса, яраткан сеңлесе Ландыш кайтып керер иде... Аны кочак җәеп каршы алырлар иде... Ришат, шундук урыныннан кубып, иң беренче минем белән күреште: «Әйдүк, Мөслимә, түрдән уз!» – диде. Ихтирам күрсәтеп, пальтомны алып элде. Эчтән җылы дулкын үтте. Тамактагы төерне йотып җибәрдем. Башкалар да җанланып китте. Гөлшат мине өстәл янына әйдәкләде. Әниләре Нәһия апа: «Аерып килмәдең. Мин сиңа риза-бәхил!» – диде. Соңрак Ришатларның өч баласының да туенда утырырга туры килде. Ришат йөзәрләгән кунакларны безнең белән таныштырганда: «Монысы – Мөслимә, Исламның әнисе. Моннан соң Исламның әнисе юк, димәгез. Әтисе дә, әнисе дә бар. Әнисе – Мөслимә», – дигән иде.

Вакытлар узган саен, Нәһия апаның үземә карата җылынганын тойдым. «Бала сине ярата. Урамда уйнаганда бала-чага: «Кайсын ныграк яратасың: әтиеңнеме, әниеңнеме?» – дип сорагач, әнине, дигән бит әле әнә! Матур киендереп кайтарасың. Киемнәре чип-чиста, сумкасына тәртип белән таслап-таслап салынган», – дип әйтүе иң зур мактау сүзләре кебек яңгырады. «Баланы бик карыйсың, рәхмәттән башка сүзем юк. Ислам өчен мин тыныч. «Әни» дип өзелеп тора синең өчен. Бу бала картаймыш көнеңдә үзеңә бер терәк булыр әле, Аллаһ боерса. Ул әнисенә охшаган. Ландышым да бик әйбәт, кешелекле, ярдәмчел, миһербанлы иде», – диде соңгы күрешүебездә. Үзем дә сизмәстән, аларның үз кешесенә әйләндем шулай.

Исламның беренче класстагы укытучысы күрше подъездда яши иде. Ландыш белән дә гел аралашканнар... Минем белән дә дуслашты. Берсендә: «Кара, син Ландышка охшагансың бит! – диде ул. – Сабырлыгың, зирәклегең белән... Елмаюларыгыз охшаган...»

...Ландышның 45 яшен үзебезчә билгеләп үтәргә булдык. Зу-ур бәлеш пешердем. Гөлшатның улы Динар, Ришатның улы Ленар гаиләләре белән килделәр. Бик сөенделәр. «Рәхмәт, апа! Бик рәхәт итеп утырдык!» – дип кочаклап саубуллаштылар.

Ә Искәндәргә әнисе белән бәйле һәр әйбер кадерле. Инде өйләнгәч тә, үзе генә килеп, әнисенең яраткан песиен иркәләп, сөеп китә. Берчак ишек янында торган таякка күзем төшеп: «Бу нигә монда тора икән?» – дип аптырап калдым. Искәндәр аңлатырга ашыкты: «Мөслимә апа, берүк ташлый күрмә, әнием исән чакта өчәүләп урманга баргач, гөмбә эзли торган таягыбыз ул!» – ди.

Бәйрәмнәрдә бергә җыелганда бездәге шау-шуны күрсәгез! Искәндәр белән Диләрә – игезәкләре Хөсәен белән Ясминәне алып килә, минем балалар, оныклар килә... Шундый күңелле!

Бар да әйбәт булыр

(Гөлшат сөйли)

Ландышны югалтканнан соң әни бик бетеренде. Әни, елама инде, безгә дә авыр бит, дигәч, «И-и, ничек еламыйсың! Уйламаган бер генә көнем дә юк бит балакаемны!» – дип сыгылып төшә иде. Зиратка җирләргә бармады. «Мин барганнан кабердән чыгып утырмый бит. Чыгып утырса, гел шуннан кайтмас идем», – дип үрсәләнде. Мөслимәдән риза-бәхил булып китеп барды бу дөньядан. Ислам Мөслимәгә «әни» дип эндәшә. Үземчә нәтиҗә ясадым: Ландыш исән булса, абыйсы Искәндәр кебек «әнием» дип әйтер иде... Аллаһның рәхмәте, Ислам да, Искәндәр дә намазда. Әниләре сөенеп ятадыр, дим. Искәндәрнең туенда: «Килен кайнана туфрагыннан була, диләр. Диләрәдә дә әнисе сыйфатларын күргәндер Искәндәр. Диләрә дә Ландыш кебек сөйкемле, сабыр, тырыш», – дигәннәр иде. И-и шатланыр иде Ландыш киленен күреп: бигрәк тәрбияле, акыллы бала! Искәндәрнең бәхете! Ике бала да тапты, тормышларын да җайлап алып бара. Әле өйләнешкән генә чаклары иде. «Гөлшат апа, мин төшемдә Искәндәрнең әнисен күрдем бит. Шундый матур иде ул. Бар да әйбәт булыр, борчылма, дип тынычландырды мине. И сөйләшәсем килеп калды үзе белән», – дип ачылган иде миңа.

Мөслимәгә рәхмәт! Бик җаваплы эшкә алынды: балаларга әни җылысын бирергә тырыша. Алла ярдәм бирсен үзенә!

Әнием – бердәнберем минем!

(Искәндәр сөйли)

Әниемне беркем алыштыра алмый! Аны сагынуларым мәңге басылмас инде... Теләнче Тамакка кайткач, зиратка барып, аның рухына догалар укыйм. Әниемле көннәрем хәтердә яңара. Бәләкәй чакта азга гына әниемнән аерылсам да, елап бетә идем. Тавышы, әйткән сүзләре, иркәләп эндәшүләре һаман йөрәгем түрендә. Ул миңа, яратып, гел «җимешем» дип дәшә иде. Үзем дә сизмәстән, Диләрәгә шулай эндәшә башладым. Бер тапкыр да күргәне булмаса да, ул да әниемне ярата. Әнием утырткан алмагачлар күптән алма бирә инде. Бакчада аның алсу-кызыл пионнары җәй саен шау чәчәк ата. Ул чәчәкләрне Диләрә белән сак кына өзеп, вазага алып кайтып утыртабыз. Өебезгә ямь керә, хуш ис тарала. Әниемле чакларда да шулай була торган иде...

* * *

Укучыларыбыз үзләренең сорауларына җавап табалгандыр дип уйлыйм. Ә тормыш дәвам итә. Балалары өчен Ландыш сөенеп ятадыр. Әни кеше теләгән теләкләр кабул була, диләр. Аның якты уйлары, өмет-хыяллары улларында, оныкларында кабатлана...

Ландышның көндәлекләрен
Qr-код аша кереп укый аласыз



ЯЗМЫШ ШАЯРУЫ

«Күрәсең, миңа бу юлны узарга кирәк булган. Башкаларга сабак булсын өчен! Аллаһы Тәгалә баланы да шуның өчен бирмәгәндер, мөгаен...» Һәр кешенең үз язмышы, үзенең хаталары, югалту-табышлары. Башкалардан гыйбрәт алып яшәргә өйрәнүчеләр бик аздыр ул. Шулай да җырчы, продюсер ГҮЗӘЛИЯ яшьләргә ярдәм итә алачагына ышана. Бары тик җан авазын гына ишетсеннәр... Язмышы хакында ачыктан-ачык сөйләшәбез.

Чулпан
ГАЛИӘХМӘТОВА



Фото: Николай Кулагин

Әдини әби белән үскән оныкның язмышы башка төрле булырга тиеш кебек тә, әмма... Ишле гаиләдә унынчы бала булып тудым. Әнине күрми дә идем: көне-төне эштә булды. Ун баланы аякка бастырырга, өс-башын карарга, ашатырга кирәк. Әти, кызганыч, гаиләбезнең терәге булалмады. Эчте ул, шуңа күрә дә тормыш арбасын әни тартты. Мине башта апалар тәрбияләде, 4–5 нче сыйныфларда укыганда әбигә яшәргә күчтем. Көндез өйдә көндәлек эшләрне эшлим, кичен әби янына китәм.
Чын мәгънәсендә әби кызы мин. Апаларым һәм әбием – тормышка юнәлеш бирүчеләр. Әбием дини, гыйлемле иде. Өендә китаплары бик күп. Эшен тәмамлый да кулына китап ала. Күз алдыгызга китерәсезме, ул фарсыча язылган китаплар укый. Китаплар аның өчен бик кадерле: тышлыклар ясап, саклап кына тотты.
Без аларга кагылырга да курыктык. Кычкырып «Әбугалисина», «Сак-Сок»ларны укуы һаман исемдә. Фарсы телендә укый да, миңа тәрҗемә итеп

сөйли... Бервакытта да намазын калдырмады ул. Аллаһының барлыгын һәм берлеген аңлатты, догалар өйрәтте. Намаз укуны кечкенәдән үк күреп, изге гамәл дип санадым. Үземә күрә хыялым да бар иде: мәктәпне тәмамлыйм да укырга керәм, укудан кайтуыма әти белән әни икәүләп тыныч кына намаз укып утыра. Бик тели идем хыялымның чынга ашуын, әмма булмады. Дин минем күңелемә шуның кадәр кергән иде: «Туй ясап кияүгә чыкмыйм. Никах укытачакбыз», – дип йөрдем. Кечкенәдән Аллаһы Тәгаләдән акыллы, сабыр, эчми торган ир сорадым. Әмма теләкне дә тели белеп теләргә кирәк икән шул...

Беренче мәхәббәт тарихым күңелсез тәмамланды. Без аның белән Казан мәдәният институтына укырга кергәч танышкан идек. Бер-беребезне яраттык, бергә булырбыз дип хыялландык, әмма ике елдан соң аерылыштык. Сәхнә кешесе юньле хатын була алмый, сиңа гади кыз кирәк, дип, әти-әнисе каршы килде. Ул безнең мәхәббәтне яклый алмады. Аерылышуыбыз тирән яралар салды. Бик авыр кичердем. 5–6 ел егетләргә борылып та карамадым, ул булмагач, башкалар кирәкми дип уйладым.

«Заман егетләре» мине зур сәхнәгә алып менде. Кабат гашыйк булдым, әмма анысы да күңелсез тәмамланды. Ул вакытта язмыш мине гел үземнән көчсез егетләр белән очраштырды. Ир-аттан күңелем кайтты. «Димәк, мин гаилә кешесе түгел. Кияүгә чыкмыйм, үземне карьерага багышлыйм», – дип сүз биргәндә миңа 28 яшь иде. Ә балага килгәндә... Гаиләң булмагач, ничек бала табасың инде?!. 33 яшемә җиткәч, тормыш юлын узганда иптәш кирәклеген аңлый башладым. Ялгызың гына булмый икән ул. Аркадаш кирәк! Һичшиксез! Шул уй кергәч, булачак иремне очраттым. Мәскәүгә апалар янына күченгән идем. Анда ресторанда идарәче булып эшлим, Татарстанда иҗат итәм. Ул көнне ресторанда клиентлар юк иде. Кәгазьләргә күмелеп утырам. Дусты белән килеп керде ул. Күтәрелеп карадым да, әллә нишләп киттем. Тәнем буйлап электр тогы үткәндәй булды. Минем янга – барга килеп басты да, «Лә иләһә иллал-лаһ...» дип сүз башлап, Коръән турында сөйли башлады. «Мин аны укып чыктым, ул миңа бик якын», – ди. Бейджигымда язылган исемемне күреп, игътибарымны шулай җәлеп итәргә булгандыр, күрәсең. Рус кешесенең изге китап турында шулай сөйләвен шаккатып тыңлап тордым. Ул Мәскәүдә туып-үскән, авиация институтын тәмамлаган укымышлы, интеллигент кеше булып чыкты. Элек егетләр белән танышкач, аларда әти чалымнары күрсәм, бигрәк тә ул егет эчсә, тиз арада аралашудан туктый идем. Ә бу бик тәртипле тыныч кеше. Минем хыялдагы ир, әмма... башка милләттән. Әйтәм бит, теләкне тели белергә кирәк, дип. Ә мин Ходайдан бервакытта да мөселман ир сорамадым, чөнки янәшәмдә башка милләт кешесе булуын башыма да китермәдем. Мәхәббәт ул – химия, диләр. Хак сүзләр. Башымны югалтып гашыйк булдым. Аның рус булуы икенче планга күчте дә куйды. Тиздән бергә яши башладык. Ул вакытта әбием якты дөньяда юк иде инде. Әни каршы килмәде. 35 яшьлек кызына кияүгә чыгарга каршы килү урынсыз да булыр иде, мөгаен. «Башка милләт кешесе белән яши аласыңа ышанасың икән, чык кияүгә, үзең генә калма, әмма син бит әби белән үскән кеше», – диде. Юк, минем тарафтан бу уйланмаган адым булды дип әйтә алмыйм. Әлбәттә, дөрес эшлим микән дигән шикләнүләр булды. Үземә ышанычым көчле иде. Үзебезнең дингә тартырмын, ул мөселманга әйләнер дип өметләндем. Җитмәсә, ул дини түгел иде, чиркәүгә йөрми, өендә иконалар юк. Әмма кешене үзгәртәм дип өметләнмәгез дә. Кеше үз асылын югалтмый ул. Шул хакта онытмагыз! «Әйдә, ислам диненә күч», – дип тәкъдим ясап карадым. «Дини кеше булмасам да, әти-әнигә хыянәт итмим, аларга әрнү китермим», – диде. Һәм аның фикере, билгеле, хөрмәткә лаек.

Безнең никах булмады. Башка милләт кешесенә кияүгә чыгып, никах укыту – икейөзлелек! Ул мөселман динен кабул итәргә тиеш. Исем алыштырып кына түгел, чын йөрәге белән. Хәзрәт белән дә сөйләштем бу хакта. «Дөрес никах булмаячак», – диде. Кеше күзенә төтен җибәрәсе килгәннәр генә эшли инде моны. Чиркәүгә барып та никахлашмадык. Әйткәнемчә, ирем дини кеше түгел. Аның әти-әнисе дә ул өйләнгәч кенә дин турында уйларга тотынды. Бәйрәмнәрен үткәрә башладылар. Мондый үзгәрешләренә хәтта ирем дә аптырады. Әмма мин аңладым: алар курыктылар. «Үз диненә тартыр да, малайсыз калырбыз», – дип уйладылар булса кирәк. Бәйрәмнәрен үткәргәндә, безне кунакка чакыралар иде. Сәбәп табып бармаска тырыштым.

Кайнанам бик әйбәт кеше. Ул бернәрсәгә дә кысылмый, шул дин проблемасы гына борчыды. Ирем, беренче тапкыр сүзгә килешкәч, әнисенә китте. Кайнанам: «У тебя есть жена, иди к ней», – дип, аны куып чыгарган. Безгә килгәч тә, өебездә эленеп торган «Аятел көрси»не күрә иде, ошамаганлыгы йөзенә чыга, әмма белгертмәде. Ә шәмаилне бик тиз алып кайтып элеп куйдым. Хәйләгә бардым: «Бүләк иттеләр, ыргыта алмыйм бит инде», – дидем. Хатын-кызның хәйләкәр булуы күп проблемалардан саклап кала ул. Шул сыйфатым ярдәм итте. Ул күп нәрсәне аңлап та бетермәде бугай. Аннан соң иремнең бик тәрбияле, сабыр булуыннан уңдым. Сугышып яшәгән катнаш гаиләләрне дә беләм. Безнең өйдә бервакытта да тәре дә, дуңгыз ите дә булмады. Моны аның миңа карата зур хөрмәте дип кабул иттем. Гаиләдә миңа ирек бирелде. Җаным теләгән җиргә йөрдем, нишлисем килсә, шуны эшләдем. Ирем бервакытта да каршы төшмәде. Ул татар музыкасын да тыңлый, җырчыларны белә. «Бар, намаз укы», – дип үзе әйтә торган иде. Әйе, рус белән яшәп, нинди намаз инде ул, дип тәнкыйть итүчеләр дә булыр. Бу хакта да хәзрәт белән сөйләштем. «Син үзеңне мөселман дип саныйсың, күңелеңдә иман нуры бар. Укы намазыңны. Киләчәктә үзең бер фикергә килерсең. Синдә башка уйлар тумый калмас әле», – диде. Ул вакытта аңламасам да, нинди уйлар килергә тиешлеген хәзер аңладым инде...

«Шулай яхшы яшәгәч, башка милләт кешесенә кияүгә чыкмагыз дип ник әйтәсең соң?» – дип сорыйсыгыз



Мәхәббәт күп еллардан соң башка формага күчә икән. Ахыргы сулышка кадәр сакланган сөю хисләре сирәктер.

киләдер. Монда бер генә җавап: безнең балабыз булмады. Бала булса, проблема чыкмый калмас иде. Ул сабыйга нинди исем бирәләр, аны кая йөртәләр? Күрәм бит инде, кайберәүләр яшереп кенә мәчеткә алып бара, икенчеләре чиркәүгә алып кереп чукындыра. Бала язмышы белән шулай уйнарга ярамый инде! Беренчедән, ул ялган күреп үсә. Икенчедән, аның күңелендә шик, икеләнү яшәячәк. Кем динендә булырга аңа? Катнаш гаиләдәге кайбер ата-аналар: «Үскәч, динне үзе сайлар әле», – диләр. Ә үскәнче ул кем канаты астында булачак? Анысын уйлаучы юк. Аны кем саклый? Баланың дини кыйбласы, үз фәрештәләре булырга, ул кемгәдер ышанырга тиеш. Нигез бит кечкенә чакта булдырыла!

Бергә яшәүнең өченче елында балалар темасына килеп терәлгәч, безнең тормышта да проблема туды. Аңа кадәр зур мәхәббәт – конфет чоры иде. Ирем бала теләмәде. Моңа кадәр өйләнмәгән егет булса да: «Үзебез өчен яшик», – диде. Ә минем бала табасым килде. Без бит инде башка тәрбиядә: гаилә ул – әти, әни һәм бала дип үскән кеше. Бик авыр кабул иттем. Бик еладым, чын йөрәгемнән үпкәләдем. «Ярар, сабыр итим инде», – дип түздем. Әйе, хатын-кыз тели икән, бала тапмый калмый. Әйткәнемчә, ишле гаиләдә туып-үскән кеше мин. Нәрсә генә әйтсәләр дә, андый гаиләдә наз да, игътибар да җитми. Әниемне күрми дә идем, шулай булгач каян җитсен соң ул мәхәббәт?! Бала мәхәббәттә туарга, назга төренеп үсәргә тиеш. Ә ирем сабыемны яратмаса, игътибар итмәсә... Шуннан курыктым. Баланы бар яктан бәхетле итә алмыйм икән, нигә тудырырга дигән уем да бар иде. Иремне хисчән кеше дип әйтә алмыйм, ул мантыйк белән гомер итүче. Сигез ел яшәгәннән соң: «Хәзер менә безгә бала кирәк», – диде. Аның ягыннан моны оятсызлык дип кабул иттем. Эчтән генә: «Ә минем хәзер табасым киләме соң?» – дип уйлап куйдым. Сәламәтлегем белән дә проблемалар башланган иде. Бала табарга курыктым. «Ә кем булачак соң ул бала?» – дигән уй баштан китмәде. Үз-үземә: «Ничек синең балаң мөселман булмасын инде», – дип әйтә идем. Һәрвакыт үз-үзем белән сөйләштем. Менә шулай баласыз калдым. Ә болай бик яхшы яшәдек. Безнең кара-каршы басып талашкан да булмады. «Ты неправильно поступила, ты была не права», – дип аңлатуга кайтып кала иде ул. Күршеләр талашканда бер-берсенә нинди генә сүзләр әйтеп бетермиләр. Шуннан соң да ничек бергә ятып йоклый икән болар, дип аптырый идек. Әмма кечкенә аңлашылмаучанлыклар да яши-яши җыела икән ул. «Нишләп алар татарча күп сөйләшәләр, мин дә монда утырам», – дип әйтүләр, әниләренә дини бәйрәмгә бармаган өчен үпкәләүләр була иде. Барыбер дә иремне начар дип әйтә алмыйм. Начар кеше булса, өйгә шәмаил алып кайтып эләргә, намаз укырга ризалык бирер иде микән?! Бервакыт дус хатынның кызы рус егете белән йөри башлады. Очрашкан вакытта ук: «Мне надоели твои татары. Поженимся и никакой татарской музыки», – дип шарт куйган. Шуларны сөйләгәч үк: «Бу сүзләргә игътибар ит. Әле сез очрашасыз гына, яши башлагач ни булыр», – дидем. Тыңлады, кияүгә чыкмады. Ә өлкәннәр сүзенә колак салмаучы яшьләр бик күп бит. Шәхсән миңа якыннарым бер киңәш тә бирмәде. Алар үзсүзле икәнемне белә. Шуңа да эндәшмәгәннәрдер. Кияүгә чыгар алдыннан бер дус музыкантның әтисе шалтыратты. «Син – Гүзәлия! Үзең үрнәк булырга тиешсең, ә хәзер безнең балаларга нинди үрнәк күрсәтәсең?» – дип каты гына әйтте. Хәзер генә аңладым сүзләренең асылын, ул вакытта аңа үпкәләдем – ярты ел сөйләшмәдем. Ә ул дөрес әйткән булган. Хәзерге акылым ул вакытта булган булса, билгеле, рус кешесенә кияүгә чыкмаган булыр идем. Әмма үкенмим. Файдасыз. Димәк, шулай кирәк булган. Аның белән яшәү – үзе бер тормыш дәресе. Ул мине күп нәрсәләргә өйрәтте. Рәхмәтем зур. Иремнең белмәгәне юк. Нәрсә турында сорасам да, җавабы бар. Казандагы тарихи бинаналар турында да, ислам диненең тарихын да ул сөйләде. Әни дә киявен бик яратты. Эшли, эчми. Безнең әниләргә тагын ни кирәк инде? Ә менә дуслар, туганнар арасында «аның ире рус бит», дигән түбәнсетүле караш яшәде. Ничек кенә яшерергә тырышсалар да, сизелде. Бик тәэсир итә, җанга тия, чөнки ул синең ирең, аны беркемнән дә кыерсыттырасы килми...

Еллар үткән саен, эмоцияләр тынычлана, дәрт югала, «күбәләкләр» очмый башлый, ул синең үз кешеңә әйләнә. Икең бер кеше булып яши башлыйсың. Бу инде мәхәббәтнең акыл белән баетылган иң югары ноктасыдыр, мөгаен. Ул синең туганыңа, тугры дустыңа әйләнә. Уртак мәшәкатьләр саклый гаиләне. Ә менә бала да булмаса, бик авыр икән ул. Аннан соң рухи якынлык булмаса (ә дин ул әнә шул рухи якынлыкның бер нигез ташы), бер-береңә карата суынасың. Өйгә кайтып керәсең – салкын. Сөйләшер сүз юк. Балалар булганда исә һәрвакыт уртак тема бар. Олыгайган саен, рәхәтләнеп, бернәрсә турында уйламыйча, тынычлап кына яшисе килә башлый икән. Икесе ике диндә булган парлар арасында алдау, әйтми калу булмый калмый... Менә шунысы яман да...

Бу хакта ачылып сөйләвемнең дә төп сәбәбе – яшьләргә аңлатырга тырышу. Катнаш никахта яшәгәнемне белгәч, киңәш сорап язучылар күп. Үз милләт кешесе белән яшәгәндә дә аңлашылмаучанлык чыкмый калмый, ә монда өстәмә проблемалар килеп туачак, дим. Катнаш никахта иң күп авырлык күрүчеләр – балалар. Туачак балаларыгызны җәлләгез. Аларның бер гаебе юк. Болай да авыр тормышны катлауландырмагыз. Рухыгызга якын булган кешеләр сайлагыз. Шунда гына гаиләдә җылылык булыр.

ИСЕМ КУШУ



Илнар хәзрәт
ЗИННӘТУЛЛИН,
«Туган авылым»
мәчете
имам-хатыйбы

Яңа туган балага бер атна эчендә исем кушарга кирәк, диләр. Әлеге йоланы ашыгып үтәүнең берәр сәбәбе бармы?

– Бала тугач, ата-ананың аның алдында билгеле бер җаваплылыклары бар. Болар турында Пәйгамбәребез (с.г.в): «Бала тугач, аңа яхшы исем кушыгыз, вакыты җиткәч, белем бирегез һәм өйләндерегез яки кияүгә бирегез», – ди. Шуңа күрә бала алдындагы беренче бурычыбыз – аңа яхшы исем бирү.

Исемне кайчан бирергә кирәк соң? Галимнәр төрле фикердә тора. Берләре: «Тууга, беренче җай чыгу белән бирергә кирәк», – ди. Ягъни бала дөньяга килүгә аңа шунда ук инде исем бирергә була. Кемдер – өченче, кемдер җиденче көнне, ди. Ләкин «җиде көннән дә соңрак», дип әйтүче ишетелми. Шуңа күрә без дә: «Исемне ашыктырып кушу хәерле», – дибез. Җиде көн эчендә бу йоланы ничек тә үтәргә тырышырга кирәк.

Исем кушу нәрсәдән гыйбарәт? Әлбәттә, матур исем сайлаудан һәм шул исем белән баланы атап йөртүдән гыйбарәт. Әгәр бала тудыру йортыннан чыкканда балага туу турында таныклык бирелгән һәм анда исеме язылган икән, димәк, инде балага исем кушылган дигән сүз. Ләкин дини яктан исем кушу әле тагын файдалы да булсын өчен, баланың уң як колагына – азан, сул ягына камәт әйтәләр. Бу нәрсәгә кирәк? Пәйгамбәребез: «Бала тугач та үзенә шайтан кагылудан елап җибәрә», – ди. «Газиз әти-әнием, кешеләр, сез мине бу күңелсез зат карамагында калдырмагыз», – дип елый ул. Шайтан яңа туган баланы көтеп кенә тора: аңа кагылырга, зыян китерергә, аның янында булырга... Ә азан һәм камәт әйткәндә, шайтан, куркып, бала яныннан кача. Соңрак шайтан бала янына килергә мөмкин, әлбәттә, тик аның йогынтысы, зыяны инде кимрәк була. Азан әйтү баланың сәламәтлеге, холкы, киләчәге өчен дә яхшы.

Начар мәгънәле исем кушу, аңа шул исем белән дәшү баланың хәтта холкына да тәэсир итә, дип әйтәләр. Бу чынлап та шулаймы? Әгәр ата-ана ялгышканын аңлап, баланың исемен үзгәртергә теләсә, аларга нишләргә кирәк?

– Начар исемнәр нинди исемнәр алар? Беренчедән, мәҗүси исемнәр. Башка диннән алынган исемнәр яки башка диндәге Аллалар исемнәре. Бездә, кызганыч, башка диннән кергән исемнәр бик популяр: Диана, Венера, Марс, Ралина... Исемнең мәгънәсендә «нәрсәнеңдер алласы» дип әйтелә икән, бу очракта мондый исем кушу катгый рәвештә тыела: хәрам була. Андый исемне баласына кушкан кеше дә гөнаһлы булып санала.

Кушарга киңәш ителмәгән исемнәр тагын бар. Тәрҗемәләрен белмичә, чит телдән алынган исемнәрне яки төрле хәрефләр җыелмасы гына булган исемнәрне кушу дөрес түгел. Тагын – начар мәгънәле, пычраклыкны, бозыклыкны аңлата торган исемнәрне. Яңгырашы матур дип кенә, мәгънәсе аңлаешсыз, сәер исемгә тукталырга кирәкми. Начар мәгънәле исем баланың психикасы бозылуга, ямьсез холыклы булуына, авыруларга ансат бирешүенә сәбәп була. Моның хаклыгын бүген фән дә раслады. Бар шулай ук авыр мәгънәле исемнәр. Мәсәлән, Пәйгамбәребез вакытында бер кеше килеп аңа мөрәҗәгать итә. Пәйгамбәребез аннан: «Ә синең исемең ничек?» – дип сорый. «Хәзен», – ди теге кеше. Авырлык, күңелсезлек дигәнне аңлата бу исем. Пәйгамбәребез: «Исемеңне Сәхел, ягъни җиңеллек дип үзгәрт», – ди. «Юк, әти биргән исемне үзгәртә алмыйм», – дип, ул кеше баш тарта. Һәм аның балалары, якыннары соңыннан: «Ул исән чакта тирә-юнебездә гел авырлык, гел күңелсезлек булды», – диләр. Кешенең исеме аның тормышына, язмышына бик нык тәэсир итә. Менә шуның өчен дә әгәр ул бик нык авырып китсә яки авыр язмышлы булса, кайчак аның исемен алыштыралар. Шушылай итеп аның бераз хәлен җиңеләйтергә мөмкин. Кайчак яшьләр: «Безнең бала – ничек телибез, шундый исем кушабыз», – диләр. Мондый хәлләр хәзер бик еш очрый. Ялгышканыңны аңлагач, баланың исемен үзгәртергә мөмкин, әлбәттә. Бу очракта шулай ук баланың колагына азан әйтәләр.

«Документта баланың исеме шулай дип язылган, әмма без аңа болай дип эндәшәбез», – дип әйтүчеләр очрый. Ике исем белән яшәү баланың язмышына ничектер тәэсир итәме?

– Кайчак әти-әниләр кызларына, әйтик, Кәримә дип кушуны сорый, баксаң, үзләре документка инде Карина дип яздырганнар һәм сабыйга шулай дәшәргә җыеналар икән. Мулладан Кәримә исеме куштыру бу очракта үз-үзеңне алдау гына – аның бернинди мәгънәсе юк. Чөнки әгәр исемнең мәгънәсе начар икән, ул каядыр телгә алынса, барыбер балага тәэсир итәчәк. Шуңа күрә балага яңа исем бирелгән икән, ул шул исем белән йөртелергә тиеш. Ислам динендә, христианнардагы кебек, яшерен исем дигән нәрсә юк. Бездә, киресенчә, кешенең яңа, яхшырак исеме бар икән, аңа шул исем белән эндәшелергә тиеш – бөтен мәгънә, хикмәт тә шунда. Кайчак олы кеше исемен алыштырганда, дуслары-танышлары: «Без элеккегесенә ияләшкән инде, шулай дип кенә йөртербез», – диләр. Әмма кабатлап әйтәм, исем документта элеккегечә дә калырга мөмкин, әмма тирә-юнендәгеләр кешегә яңа исеме белән мөрәҗәгать итәргә тиеш. Югыйсә исем үзгәртүнең бер мәгънәсе булмаячак.

PRESSA

ИДЕЛ–ЧУЛМАН–АГЫЙДЕЛ



Василә РӘХИМОВА

«Сәяхәт вакытындагы тормыш — хыялның саф хәлендәге чагылышы ул!» – дигән Агата Кристи. Килешәм. «Агыйделдә йөзсәң иде, / Камыштан көймә үреп...» дип, әллә ничә ел хыялландым да, ниһаять, ниятемә ирештем. Җәй башлануга, Казан–Уфа маршрутында алты көнлек круизга кузгалдым. Агыйдел мул сулы чакта, май-июнь аенда гына йөзә икән теплоходлар. Уфада берничә тапкыр булсам да, су юлы белән, табигатькә хозурланып барасым килде. Ялның бу төрен күпләр иң тыныч, уңайлы ял дип саный. Ыгы-зыгысыз гына юлыңны дәвам итәсең. Шәһәрләргә барып җитүгә, заманча уңай экскурсия автобуслары каршылый, истәлекле урыннарда йөртә һәм теплоходың причалына ук китереп тә куя. Юл сорап, автобус, такси эзләп мәшәкатьләнмичә генә ике-өч сәгатьтә шәһәр белән танышасың.

...Моннан 20–25 еллар элек җыйнак кына ике палубалы теплоходка утырып, Казаныбызга Башкортстаннан язучылар, артистлар килә иде. Әдәбият-сәнгать көннәре башлана. Хөрмәтле тугандаш халыкларны ут күршеләр дип зурдан кубып каршылауларны телевизордан күрсәтәләр, газета-журналлар язып чыга... Әллә шул заманнардан ук күңелгә кереп, кызыктырып калган инде: Агыйделдә йөзәсем, Урал тавы итәкләрен су юлында карап узасым килде.

Йөремсәкләр яраткан ял

Без үскәндә юл йөрүдән үзенә бер хикмәт тапкан, сәфәрләргә чыгуны авырыксынмаганнарны «йөремсәк», диләр иде. Хәзер исә турист, сәяхәтче дип атыйлар. Ярар, мин икесенә дә риза. Кайтуга «журналист Вәсилә Рәхимова» булып каләмемне алам.

Хәзер дөнья күрүләр, юл йөрүләр белән берәүне дә шаккаттырып булмый. Сәяхәтләрнең, ялларның ниндиләре генә юк?! Тикмәгә генә туризм иң уңышлы, табышлы бизнес саналмый. Әйдәгез, кечерәк елгаларда йөзү өчен үзебезнең уңайлы ике палубалы, 130 ял итүчегә исәпләнгән «Алдан» теплоходына, аның палубаларына кучик тә, круизга кузгалыйк әле! Ни дисәң дә ялның күп өлеше палубада уза. Июнь башы – табигатьнең кыз чагы, иң җете төсләрдәге саф, матур чагы, диләр борынгылар. Тирә-як белән хозурланып йөзәбез дә йөзәбез. Сүз белән аңлатып бетермәслек матурлык бит бу дип сокланабыз. Барыбыз да «өченче буын» дип йөртелүче пенсионерлар, замандаш-чордашлар җыелганбыз икән. Фикерләребез, тәэсирләребез дә туры килә, ярты сүздән аңлашабыз. «Без дә менә ял итәргә өйрәндек. Югыйсә Европадагы өлкәннәргә кызыга идек», – дип көлешәбез...

Су өстендә кояш чыгу, кояш баю мизгелләрен күзәтү үзе генә дә ни тора!

Ярда – Чистай, Түбән Кама, Алабуга...

Менә без X гасырда ук нигез салынган Чистайда. 3 сәгатьлек экскурсиядә гидыбыз Россия тарихында якты эз калдырган шәхесләрнең Чистай белән бәйләнешен сөйләп калырга ашыкты. Язучы, шагыйрь, тәрҗемәче, Нобель бүләге лауреаты Борис Пастернакның мемориаль музеенда булдык, XIX гасырда Казан губернаторы Николай Скарятин нигез салган, шул заманның элитар ял урынын — бакчаны да, андагы биек фонтаннарны да карарга өлгердек.


Чистайда 160 еллык тарихлы, атеизм чорында да Татарстанда сакланып калган бердәнбер агач мәчет булган «Нур» мәчетен автобус тәрәзәсеннән карап уздык. Анда ярты гасырга якын имамлык иткән, шул ук вакытта II гильдия сәүдәгәре булган Мөхәммәтзакир ишан Камалов-Чиставиның үз акчасына мәдрәсәләр салдырып, гомере буе аларның бөтен чыгымнарын күтәрүче юмарт булганын белдек. Чит илдә яшәп татар язмышы өчен җан аткан бөек татар улы Гаяз Исхакый шушы яктан.

Кичен химиклар каласы Түбән Камага туктадык. Безне каршылаган гид өч сәгатьлек экскурсиядә шәһәр төзелеше белән бәйле вакыйгаларны сөйләргә, кичке каланы аркылыга-буйга иңләргә, легендар төзүче Николай Лемаев һәйкәлен күрсәтергә, химия гигантларына гомер биргән җитәкче исемендәге скверда йөртергә дә өлгерде.

Түбән Камалыларның горурлыгы булган Тукай паркында туристларыбыз аеруча җанланды: «этнокультура», «этноүрнәкләр» дип, милли бизәкле татар йортларын, Тукай шигырьләре буенча ясалган скульптураларны, әкият геройларын шалт та шолт фотога төшерергә ашыкты. Сорауларын да яудырыпмы яудыралар. «Шүрәле» әкияте буенча ясалган Былтыр һәм Шүрәле сыннары янында бераз «гид» булырга да өлгердем. Яшеллеккә күмелгән кала урамнарыннан Җәмигъ мәчетенә килеп чыккач та, юлдашларым соклануларын яшермәде. Манарасының биеклеген дә, ярым айларның авырлыгын, кайларда ясалуын да, мәчеткә күпме халык сыюын да беләселәре килде.



Чистайның милли төсмерләргә шактый мул «Хәзинә» скверында Гаяз Исхакый, Фатыйх Әмирхан, Кояш Тимбикова, София Гобәйдуллина бюстларын күреп сөендек.



Уфаның су юлы капкасы – елга порты, яр буйларының бизәлеше бирәүне дә битараф калдырмады.

Сәяхәтебезнең икенче иртәсендә без инде меңьяшәр Алабугада идек. Әле яңа гына файдалануга тапшырылган дебаркадерга, төзекләндерелгән, уңайланган Чулман ярларына озаклап сокланырга өлгермәдек, татар көйләре яңгыратып, милли киемле кызлар чәкчәк тотып каршы алды, елмаеп сәламләде. Тоташ тарих, чып-чын купецлар шәһәре. Ике катлы борынгы йортлар. Барысы да сәяхәтчеләргә күрсәтерлек төзек хәлдә. Һәр урам, һәр тыкрык кунак көткән кебек ялт иткән. Атаклы рәссам Иван Шишкинның музей-йорты, шагыйрә Марина Цветаевага багышланган мемориаль комплекс, кавалерист кыз Надежда Дурованың музей-йортларында булдык дию генә аз. Үз эшләрен яратып башкаручы экскурсоводлар безне гүя әлеге шәхесләр яшәгән дәвергә, шул мохиткә алып киттеләр...

Җай гына сәяхәтебезне дәвам итәбез. Ярда – ак кала, КамАЗлары белән бөтен дөньяга данлыклы Чаллы кала, кайчандыр Бондюг эшчеләр поселогы булган химиклар шәһәре Менделеевск кала... Теплоходыбыз зәңгәр Чулманнан ап-ак Агыйделгә күчә. Актаныш җирләренең болыннары, әрәмәлекләре кала...

Әкияти матурлык, сәгатьләр буе Идел–Чулман–Агыйдел дулкыннарына карап бару күңелне дә йомшартты, күрәсең. Хәтергә заманында бик тә яратып җырлаган, шушы яклар гүзәллегенә багышланган җырлар искә төште. Сүзләре онытыла төшсә дә, көе истә. Фәтхерахман Әхмәдиевнең «Чистай вальсы», «Кама буе – туган як» көйләрен агымсуларга карап үзалдыма моңланып бардым. «Кама буе – туган як, / Гөлләр үсә торган як...» – дип, ничек җырламыйсың инде?! Уфада йөргәндә исә күңелем белән гел Рим Хәсәновның «Өфе юкәләре»н эзләдем. Сара Садыйкованың Нәби Дәүли сүзләренә язган «Уфа ни өчен матур?» дигән соравына да җавап табарга тырышып йөрдем.

Уфа ни өчен матур?

Уфа безне дүртенче көнне каршылады. Уфа Уфа инде! Агыйдел тирәнлеге, киңлеге белән мактана алмый, дидем. Уфага лайнерлар да, дүрт палубалы теплоходлар да килеп җитми. Шуңа карамастан, Агыйдел ярларын бик матур ял итү урынына әйләндергәннәр. 7 чакрымга сузылган яр буен (киләчәктә ул 14 чакрымга җитәчәк, диләр) кемгә генә күрсәтсәң дә, тел шартлатырлык итеп матурлаганнар. Миллионнан артык халык яшәгән Башкортстан башкаласы белән таныштыруны гидыбыз: «Уфа – исемнәре дөньяга танылган атаклы шәхесләре белән горурлана. Биредә Башкортстанның халык шагыйре Мостай Кәрим яшәде, иҗат итте», – дип башлавы күңелне уңай дулкынга көйләде.

Россия мөселманнарының Үзәк Диния нәзарәте Баш мөфтие Шәйхелислам Тәлгать хәзрәт Таҗетдин һәм аңа кадәрге мөфтиләрнең дә тарихи резиденциясе белән кызыксынучылар арабызда шактый булды... 4 сәгатьлек экскурсиябез азагына якынлашып килә, вакыт та санаулы. Гидыбыз: «Шәһәр үзәгендә христианнарның әле күптән түгел генә төзелгән чиркәве белән танышабызмы, әллә Уфаның Җәмигъ мәчетенә барабызмы?» – дип сорауга, сәфәрдәшләрем беравыздан диярлек икенчесен сайлады. Мине бу шаккаттырды. Арагызда татарлар күп булгандыр диярgә ашыкмагыз – дүрт кенә бөртек идек. Яңа җирләрне, яңа мәдәниятне күрү, таныш булмаган урыннарда булу — һәр туристның хыялы: ислам динен тотучыларның мәчет тәртипләре белән танышу, гыйбадәт йортларын үз күзләре белән күрәсе килү өстенлек алды.

Аллаһка шөкер, динебез белән кызыксыналар. Теплоходыбызда динебез кушканча – мөселманча киенгән икәү генә идек. Юлдашым, Казанның Тынычлык бистәсе абыстае, 76 яшьлек Сәлимә апа Хөсәенова круизга кузгалуга зәвыклы киеме, ап-ак яулыгы астыннан килешле калфаклары белән туристларның сөйкемле сөягенә әйләнде дә куйды. Йөзеннән елмаю китмәгән, тәмле телле абыстаем белән күбесе аралашу җаен таба: «Сезнең бәрәр бәйрәмегезме әллә, бик матур киенеп йөрисез?» – дип сорыйлар.



■ Тура-Таудан башланган шәһәр тарихы белән дә, бүген биеклеккә һәм киңлеккә үсүче затлы Уфа белән дә иркенләп таныштык. Башкорт халкының милли каһарманы Салават Юлаев һәйкәле һәркемне еракттан ук сәламли.

Йомгак һәм киңәш

Алты көн буена бер табында кунак булган күршем, Михаил Ломоносов исемендәге Мәскәү дәүләт университеты ректораты хезмәткәре Елена





■ Сәяхәтебезнең соңгы көне. Алда – безнең бөтен татар дөньясы өчен кадерле, борынгы, изге Шәһри Болгар җирләре. Узган көнне генә барыбыз да җыелып, шушы җирләрнең тарихы, бүгенгесе хакында фильм караган, шактый күзалларга өлгергән идек. Әмма үз күзләрең белән X гасырдагы Идел Болгарстанының тарихтагы урынын дәлилләгән бай экспонатларны күрү, «Болгар цивилизациясе», «Истәлек билгесе» музейларында булу, ачык һавадагы археологик корылмалар белән танышу – бөтенләй башка!



Викторовна Волкованың Изге Болгарга кылган сәяхәт тәэсирләрен сезгә дә ирештерәсе иттем:

– Круизларга беренче генә чыгуым түгел. Моңарчы булмаган яңа маршрутларга йөрим. Бу сәяхәттән дә белемебезне арттырып, күпме яңалыклар ишетеп кайтабыз. Идел Болгарстаны, татарларның килеп чыгышы, ничек итеп исламны кабул итүләре һәм аны бүгенге көнгә кадәр китереп җиткерүләре хакында фәнни яктан дәлилләнгән тарих белән очраштым. Хәтердә ныграк калдырыр өчен бик күпләрен фотога төшердем. Сәяхәттән кайткач, тәэсирләремне сөйләвемне гаиләм көтеп ала. Үзенә бер пресс-конференция уздырам, хәзергечә әйтсәк: онлайн-сәяхәт килеп чыга. Төшергән фотоларымнан альбом төзеп, оныкларым белән җыелып, кат-кат карарга, дусларыма күрсәтеп, тәэсирләрем белән уртаклашырга да яратам.

Юлдашым, беренче тапкыр шушындый сәяхәткә чыгучы Сәлимә апа Хөсәенова исә:

– Чордашларым арасында ял итү, шәһәрләр күрү, зур елгаларда йөзү – барысы да минем өчен могҗиза булды, – ди. – Изге Болгар җирендә намаз укыдык, күп-күп догалар кылдык. Уфаның тарихи мәчетендә алган тәэсирләремне дә тел белән әйтеп бетерерлек түгел. Алты көн буена агымсуларга карап ил-көнебезгә тыныч тормыш, бәрәкәт теләдем...

Кайткач мин дә сәфәрем хакында рәхәтләнеп тәэсирләр уртаклашам. Кызыгып тыңлаучылар да, сорау яудыручылар да бар. «Мине дә иярт әле. Мин дә хыялланам сәяхәтләргә чыгарга», – диючеләр байтак. Аларга киңәшем: сәяхәт итәргә теләү, бу хакта хыяллану – бер хәл. Буш хыял булмасын өчен тәвәккәллек бик кирәк. Җәйге ялларның кызган чагында: «И-и, акчам бар, йөреп кайтыйм ла», – дип, юллама эзләргә керешү файдасыз. Сайлау мөмкинлеге бик чикле бу вакытта. «Ике-өч ел алдан чираттагы ялларны кайларда уздырасын тәгаенлибез», – ди йөремсәк Европа халкы. Безнекеләр дә хәзер сәяхәт маршрутларын ачыклагач та, бер ел алдан ук юллама алу хәстәренә керешә.

Хәләл ризык, хәләл туклану турында еш сорыйлар. Проблемасы булса да, әлегә моны хәл итәргә алынучы күренми. Тик балык, сөт ризыклары белән дә тамакны туйдырып була. Мин ашау ягын артык куертмыйча ял итү ягында. Бер атна мөселманча чалынган ит, тавык, хәләл казылыкларсыз да торып була.

Нәрсәләр алып кайттың, бездә очрамаган әйберләр бармы, дип тә сорыйлар. Гадәттә, шушы сәяхәт, шушы шәһәрләр истәлеге итеп сувенирлар, кайткач, бергә чәй эчәргә дип тәм-том алам. Бу юлы менә Уфа истәлеге дип башкорт милли бизәкләре төшкән касәләр сайладым. Сәфәрдәшләрем исә туктаган бер шәһәрдә чәкчәк, Уфада алмас җирдән алырлык итеп, төрле савытларга кызыктырып салынган башкорт балын сатып алды.

Ял итүчеләр өчен күңел ачу программасы да күпкырлы иде. Сәяхәтчеләрнең күңеленә иң хуш килгән яңалык – тукталасы шәһәр, сусаклагычлар, шлюзлар тарихы хакында алдан ук кыскача мәгълүмат бирү белән бергә, шушы хакта документаль фильмнар күрсәтү булды.

Атнага якын табигать бишегендә тирбәлеп, туган ягыбызның күз күреме җитмәс манзараларына сокланып үткән ялыбызны әле озак еллар сагынып сөйләрбез. Биек йортлар арасында офык күрергә тилмергән кала халкына барысы да бик тансык! Һәр көнне иртән теплоходыбыз радиоалгычыннан агылган чишмә чылтыравы, дулкыннар шавы, кошлар сайравы, әтәч кычкыруы кушылган табигать симфониясе уятуын да онытмабыз.

«ХАТЫН-КЫЗ ЧИБӘР БУЛА!»



Ир-ат һәм хатын-кыз. Бер үк Галәмгә без бит очраклы гына эләкмәгән... Шулай булгач, нигә соң бер-беребезне күп вакыт аңламыйбыз? Гамәлләребезне, теге яки бу адымыбызны, әйткән сүзләребезне... Үзара тартылуны «җиңеп», арага каршылыклар керә дә куя...
Ә ир-атлар үзләре бу хакта ни уйлый икән? Сүзне аларга бирик әле.

Илдар СӘГЪДӘТШИН, Татарстан китап нәшрияты директоры; гаилә стажы – 15 ел; балалары – Илсинә (14 яшь), Сәлим (6 яшь).

1 Иң элек хатын-кызның нәрсәсенә игътибар итәсез: киеменә, буй-сынына, күзләренә, чәченә...

– Бу соравыгызга Роберт Миңнуллинның шигъри юллары белән җавап бирәсем килә:

Хатын-кыз ямьсез булалмый,
Хатын-кыз чибәр була!
Шуны күрмәгән ир-ат ул,
Әлбәттә, җүләр була.

Миңа калса, сез санаганнарның барысына да игътибар итәсең, шул очракта гына гомум бер образ килеп баса. Әйе, күзгә барысы да чалына...

2 Хатын-кызның кайсы сыйфатларын гафу итәргә була?

– Хатын-кызга карата артык вакчыл караштa булырга кирәкми дип саныйм. Аннан күп кенә кимчелекләрне яшәү дәверендә сизми дә башлыйсың – күнегәсең. Миңа исә гафу итү, гомумән, авыр бирелә – кичерсәм дә, күңелемдә юшкыны кала. Бу – характер, холык инде... Аны үзгәртергә тырышу – үз-үзеңә каршы бару, үз-үзең белән көрәшү була. Ә нигә үз-үзең белән көрәшеп торырга әле? Мин үзем кешеләрне юк-бар сүзләр белән рәнҗетмәскә тырышам.

3 Ә нәрсә өчен бик якын хатын-кызны да гафу итмәс идегез?

– Хыянәтне кичерә алмас идем, тик моңа физик яктан хыянәт итү генә керми. Гомерлек юлдаш итеп сайлаган парың сиңа бөтен яклап тугры булырга тиеш дип уйлыйм. Ышанычлы булырга тиеш! Дусларга да төп таләбем шул: кеше ышанычлы икән, аның белән аралашу җайлы миңа.

Бер дустым өч тапкыр өйләнеп аерылды. Әлеге дә баягы хыянәт аркасында... Кемдер хыянәттән соң да балалар хакына бергә яшәп кала. Әйе, уртак балалар булу – ул җаваплылык. Әмма балалар хакына гына бер түбә астында калдык диючеләр барысын да әйтеп бетермиләрдер. Ике арада барыбер мәхәббәт тә каладыр. Һичьюгы – очкыны. Бернигә дә карамыйча, күңелләрне шул бәйләп торадыр... Бу өлкәдә тәҗрибә юк минем. Булмасын да... Үземне хәтта мондый ситуациягә куеп та карыйсым килми.

4 Хатын-кызлар икегә бүленә: ир-атны илһамландыручы алиһәләр һәм өйдә аның өчен комфорт тудыручы хуҗабикәләр. Сезгә кайсы якынрак?

– Карагыз әле, бу яктан караганда минем хатыным идеаль булып чыга бит! Ул үзендә сез әйткән ике типның да сыйфатларын туплаган. Һәм бу шулай булырга тиеш тә! Шушы очракта гына гаиләдә ир-ат белән хатын-кыз арасында хисләр суынмый, гармония урнаша.

5 Ир кеше өчен аның хатыны дус та була аламы?

– Беренче чиратта дус булырга тиеш тә. Хатыны белән бернидән курыкмыйча, икеләнмичә, шикләнмичә ачыктан-ачык төрле темага сөйләшә, фикерләшә алганда гына, ир кешегә гаиләдә җиңел һәм рәхәт була.

6 Хатыныгызга ничек тәкъдим ясаганыгызны хәтерлисезме әле?

– Әлбәттә, хәтерлим. Гомергә истә кала торган, бик җитди адым бит бу. Хәзергеләр кебек шаккаттырып тәкъдим ясау модасы юк иде әле ул вакытта, шулай да без бик бәхетле идек. Казансу буенда булды ул хәл. Шуңадыр бу урыннар Гүзәл белән миңа хәзер дә бик якын. Туебызда «Айфара» төркеме җырлады. Иң элек – «Ак каен»ны: «Ак каен, яшь каен, / Син үлмә, яшә син...» Сүзләренең моңсулыгына игътибар итмәделәр – иң популяр җыр иде бу ул вакытта.

Миңа 27 яшь иде инде. Барысы да үзем күзаллаганча булды. Әгәр 18 яшемдә сорасагыз: «27 яшь тулып узгач кына өйләнәчәкмен», – дип әйткән булыр идем. Беренчедән, әти-әнидән өйләнергә акча сорыйсым килмәде. Туйның бар чыгымын үзем күтәрергә теләдем – шулай дөресрәктер кебек тоелды. Мин аларны туебызга кунак итеп кенә чакырдым. Икенчедән, бу яшьтә инде дөнья күргән, азмы-күпме тәҗрибә туплаган кеше буласың дип уйлый идем. Бүген исә башлы-күзле булу өчен 27 яшь тә иртәрәк икән әле, дим.

7 Ир кеше хатын итеп әнисенә охшаган кызны сайлый диләр, шулаймы?

– Минем очракта бу дөреслеккә туры килми. Сез миңа ир-ат белән хатын-кызны «икесе ике Галәмнән» дисез бит әле, әни белән хәләл җефетем дә нәкъ шулай: алар тышкы

кыяфәт буенча да, холык ягыннан да бер-берсенә охшамаган. Әнием шагыйрә Фәйрүзә Мөслимова – иҗат кешесе, ә хатыным – финансист. Алар хәтта төрлечә уйлыйлар, әмма уртак телне тиз таптылар... Гаилә корганда әнинең миңа ниндидер киңәшләр биргәнен хәтерләмим. Бирмәгәндер дә: киребеткән икәнемне, барыбер үземчә эшләвемне белә бит ул. Килен алып кайтып сөендергән өчен рәхмәт әйткәне истә минем. Буйдак булып кала ахрысы, дип курка башлаган булганнар бугай *(көлә)*.

8 Хатыннары ирләреннән күбрәк мал тапкан гаиләләр бар. Ир бу очракта үзен ничек тотарга тиеш?

– Киләчәктә шундый низаглар килеп чыкмасын өчен, үзеңә бар яктан да тиң ярны сайларга кирәк тә. Моны борынгылар ук әйтеп калдырган. «Аягына күрә – башмагы», «Атына күрә – йөгәне», дигәннәр. Ә үземә килгәндә, Гүзәл миннән күбрәк мал тапса, шатланыр гына идем: гаилә бюджеты уртак бит – аның зураюына борчылалар димени?! Тик тормышны хатын алып барыр көнгә калмам дип өметләнәм. Эшләргә яратам! Нинди эшкә тотынсам да, җанымны-тәнемне биреп башкарам – эштән курыкмаган кеше эшсез каламыни?! Гадәттә, тамыры авылдан булганнар: «Һичьюгы кайтып көтү булса да көтәрмен», – диярргә ярата. Тик хәзер авылда көтүне дә электр тогы ярдәмендә генә көтәләр... Ә минем әле ДТ тракторын йөртү хокукым да бар. Мәктәпне әнинең туган ягында – Актаныш районы Иске Кормаш авылында тәмамладым, безгә анда «механизатор ярдәмчесе» дигән һөнәр дә бирделәр...

9 Гашыйк булуын хатын-кыз башлап үзе белдерүгә ничек карыйсыз?

– Бу яктан мин – консерватор. Татар халкында яшәп килгән гореф-гадәтләргә, безнең менталитетка туры килә торган хәл түгел. Ир кеше хатын-кызны яулап алырга тиеш, шуның белән ул үзенең тормышны тартып бара алырлык, җитди, тырыш икәнен дә күрсәтә.

10 Хатын-кызларны ир-атларда иң беренче чиратта нәрсә җәлеп итә дип саныйсыз?

– Бөтен кешенең уенда йөрткән идеалы була: ул шуннан чыгып үзенә пар сайлый. Һәм... күп очракта хаталана. Минә ни өчен берәүне дә артык идеаллаштырырга ярамый.

11 Ир-ат белән хатын-кыз икесе ике Галәмнән икәне билгеле инде. Кайчакларда аларның бер-берсен аңламаулары шуннан килеп чыга да. Хатын-кызның нигә нәкъ менә шулай эшләгәнен үзегез аңламаган берәр очракны искә төшерегез әле.

– Кинәт кенә искә төшми бит... Ә шаккатырганы ярыймы? Менә шушы көннәрдә генә өченче югары белем алырга җыенуын әйтте Гүзәл. «Юрист буласым килә – бу өлкәдә белемем җитмәвен сизәм», – ди. Бәлки, абыйсыннан үрнәк аладыр – аның югары белемнәре бишәү. Мин, әлбәттә, риза, кирәк икән, ярдәм дә итәчәкмен.

12 Хаклы икәнегезне яхшы беләсез, әмма хатыныгызның үз туксаны – туксан, хаклык аның ягында дип саный.

– Мин хаксыз булсам да, моны белеп торсам да, сүземне бирмим. Ә ул, үзенең хаклы икәнен белсә дә, күп очракта миңа юл куя, бирешә. Һәм... барыбер үзенчә эшли *(көлә)*. Чын татар гаиләсендәге кебек, бездә дә ир – баш, хатын – муен һәм хатынымның зирәклеге белән муен башны үзенә кирәк якка бора да тора *(көлә)*. Ә җитди итеп әйткәндә, гаиләдә ир белән хатын бер-берсенә юл куя белергә тиеш. Кемдер күбрәк, ешрак юл куя, кемдер – сирәгрәк.

13 Шундый очракны күзаллыйк әле: ачыгып, арып-талып эштән кайтып керәсез, ә өйдә ашарга пешмәгән. Хатыныгыз, арыдым дип, диванда кырын ятып тора...

– Мондый хәлне күз алдыма да китерә алмыйм. Безнең өйдә ашарга гел нидер бар. Хәтта юк дигәндә дә нәрсәдер табыла – хатынымның уңганлыгы, бәлки, шуннан да күренәдер. Гүзәлнең бик күп ризыкларын мактый алам, ә менә бәлешен... Без шәһәр читендә, авылда торабыз. Андагы гадәт буенча, күршеләр белән бер гаилә кебек яшибез. Күрше Мәрзия апа, аның кызы Лилия апа кебек тәмле бәлеш пешерүче дөньяда да юк! Мәрзия апаның ире мәрхүм Салихҗан Галимҗанович заманында зур җитәкче булган. «Өйдә гел кунак иде, көн саен табын кордым – шулай остардым», – ди Мәрзия апа. «Кайбер серләрне минем хатынга да ачыгыз инде», – дип, бәлеш ашаган саен әйтәм. Әлегә серне каты саклыйлар *(көлә)*. Бәлешкә аларга җитеп булмаслыгын Гүзәл үзе дә белә. Ә менә хатынымныкы кебек солянканы Мәрзия апалар әзерли алмый. Безгә туганнар Гүзәлнең солянкасын ашарга килә.

Сорауга әйләнеп кайтыйк әле. Кирәк булса, мин үзем дә нидер пешерә алам – ач калмыйм. Шашлык кыздырырга яратам менә. Әзер ризыкка заказ бирүгә дә уңай карыйм – хәзер андый сервислар бик зур үсеш алды бит.

14 Сер түгел, берәр җиргә җыена башласак, без, хатын-кызлар соңга калучан...

– Төрле хәлләр була инде... Кайчак чыгып машинада көтеп утырасың. Ул, ниһаять, ишектә күренә һәм... «Тукта, башка күлмәк киеп чыгам әле», – дип кире кереп китә. Күлмәкне генә алыштырмый бит ул, барысын да үзгәртә: аяк киемен, сумкасын, бизәнү әйберләрен... Мин, әлбәттә, моны мәзәккә борам – «ачу килә» дигән сүз минем хакта түгел. «Бүген ике генә тапкыр алыштырдың, әллә тагын бер керәсеңме?» – дим. Ул моны күлмәген ошатып бетермәвем дип аңлап булса кирәк: «Чынлап та шулай уйлыйсыңмы?» – дип кире борыла!

15 Хатын-кызлар еш кына... бүләк сайлауда ялгыша: ир-атка ошамастай бүләк бирә.

– Гүзәлгә өйләнгәннән бирле, миңа, гомумән, гел кирәкле һәм үзем теләгән бүләкләрне генә бирәләр. Сере шунда: дуслар, туганнар хатыным белән алдан киңәшләшеп, нәрсә кирәген белешеп куя. Бик җайлы икән ул. Нәшрият өлкәсендә эшләүче буларак, миңа иң матур бүләк, әлбәттә, китап! Болай да шул дөньяда яшәгән кешегә бүләккә китап сайлау авырдыр, дисезме? Юк, алай түгел. Дөньяда китаплар бихисап! Һәм иң кызыгын син әле һаман да укымаган... Беренче чиратта укырга кирәк дигән 20–30 китап тора әнә өстәлемдә. Миңа да Гүзәлгә нидер бүләк итәргә бик җайлы. Ул, гадәттә, алдан ук алып куя да: «Күптән хыяллана идем... Бу синнән туган көнгә бүләк булыр, яме!» – ди. Туган көн җиткәнче ул онытыла, билгеле *(көлә)*. Аның миңа биргән иң зур бүләге – ике балам. Алардан да кадерле бүләк юк!..

Тулысынча укыгыз »





Бу йогышлы авыруны икенче төрле әнә шулай дип тә атарга була. Балалар арасында аеруча күп таралуының сере дә нәниләрнең гигиена таләпләрен тиешенчә үтәп җиткермәүләрендә. Республика балалар клиник хастаханәсенең Сәламәтлек үзәге мөдире, югары категорияле балалар табибы Гүзәл ЯРУЛЛИНА белән сүзебез балаларда лямблиоз турында булыр.

ПЫЧРАК КУЛЛАР ЧИРЕ

Лямблиоз – киң таралган чирләрнең берсе. Аның белән балалар гына түгел, олы кешеләр, этләр, мәчеләр дә авырый. Лямблиозны патоген микроорганизмнар китереп чыгара. Алар ике төрле формада яши – вегетатив һәм циста формасында. Беренче очракта лямблияләр нечкә эчәкнең өске өлешләрен зарарлый, һәм алар әйләнә-тирәлек факторларына бик сизгер. Цисталар исә юан эчәктә була һәм тәрәт белән бүленеп чыгып, тирә-юньгә тарала.

Еш кына лямблиозның билгеләре күренмәскә дә мөмкин. Бала дискомфорт кичерми, әмма лямблияләрне таратучы булып тора.

Организмда патоген микроорганизм булуын баланың тәрәт анализыннан ачыклыйлар. Шулай специфик иммуноглобулинны ачыклар өчен кан анализы һәм стандарт лаборатор анализлар ясала. Соңгысы баланың гомуми сәламәтлеген бәяләр өчен кирәк.

Органнарның функциональ халәтен билгеләр өчен, балага гастроэнтеролог, кардиолог, невролог консультациясе кирәк булуы да ихтимал.

Лямблиоздан дәвалауның максаты икәү. Берсе – организмны лямблиялардән арындыру, икенчесе – пациентның гомуми халәтен яхшырту.

Билгеләре:
- еш эч авырту. Күп очракта ул өянәк рәвешендә була;
- тәрәт бозылу (эч китәргә яисә эч кибәргә мөмкин);
- тәрәтнең күбекләнүе;
- аппетит начарлану, авырлык киму;
- чәчләр, тырнаклар, тиренең зәгыйфьләнүе (эчәклектәге микроэлементларның үзләштерелүе бозылу аркасында);
- кикертү, күңел болгану;
- аллергия (тән чабыру, кычытыну).

✓

Белә идегезме:



■ Кабак төше һәм кабак мае – организмда яшәүче паразитлардан бик яхшы дәва чарасы. Аның ярдәмендә баланың организмын лямблиялардән дә арындырырга мөмкин.

■ 300 г вакланган кабак төшен коры чиста банкага салып, 50 г чиста су һәм 50 г бал өстәгез. Шуны балага бер сәгать дәвамында аз-азлап кына биреп бетерегез. Соңыннан эчне йомшарта торган дару эчертелә һәм төнгелеккә клизма ясала. Әлеге процедураны 7 көн дәвамында кабатларга кирәк. Ләкин башта табиб белән киңәшегез, чөнки үсемлек препаратлары даруларның нәтиҗәлелеген киметергә мөмкин.

Фото: www.pexels.com

БУ МӨҺИМ: балада лямблияләр ачыкланган очракта дәва курсын аның белән контактта булган һәркем бер үк вакытта алырга тиеш. Дәваланган вакытта кыздырылган һәм ысланган ризыклардан тыелырга, порцияләрне киметергә кирәк.

Лямблиозны йоктыру сәбәпләре:
■ авыру кеше белән бер өйдә яшәү;
■ шәхси гигиена таләпләрен үтәмәү;
■ өйдә эт һәм мәче асрау;
■ чит балаларның уенчыгы белән уйнау;
■ яшелчә, җиләк-җимешләрне юмыйча ашау;
■ цисталар булган суда коену;
■ балага кайнамаган су эчертү;
■ әнисе авырган очракта, бала туганда ук лямблиоз йоктырырга мөмкин.

Табиб киңәш итә:
■ дәвалау табиб күзәтүендә комплекслы уздырыла;
■ организмны микроорганизмнар бүлеп чыгарган токсиннардан арындыру өчен энтеросорбентлар билгеләнә;
■ пробиотиклар һәм пребиотиклар эчәклекнең нормаль микрофлорасын үстерә;
■ микроорганизмнарның үзләрен юк итү өчен микробларга каршы дәва чаралары кулланыла;
■ ашказаны асты бизе һәм үт куыгы функцияләре бозылганда өстәмә рәвештә ферментлар кабул ителә.





Үз гомерендә һәркемнең дә йокыдан муены йә җилкәсе авыртып уянганы бардыр. «Муенга җил бәргән, борып булмый», – дип зарланышабыз. Моның сәбәбе – миозит булырга мөмкин. Җәйге эссе көннәрдә бу – аеруча еш таралган авыруларның берсе. Казан шәһәре 18 нче клиник хастаханәсенең неврология бүлеге мөдире, югары категорияле табиб-невролог Гөлназ ФӘСАХОВА белән сөйләшүебез бүген шул хакта.

МИОЗИТ

Миозит – скелет мускулларының ялкынсынуы ул. Теләсә кайсы мускул зарарланырга мөмкин. Күп очракта миозит бер яки берничә мускулда күзәтелә. Кайчагында барлык мускуллар берьюлы ялкынсына. Анысы полимиозит дип атала.

Ялкынсыну процессыннан мускулда киеренкелек башлана. Бу – аның саклык фукциясе, организм шул рәвешле хәрәкәтләрне чикләргә омтыла. Миозит озакка сузылса, вакытында дәваланмаса, мускулларда хәлсезлек көчәя, гипотрофия башлануы ихтимал.

Миозитлар бигрәк тә җәй көнне, көн кызуында ешая. Без тирлибез, тирләгән килеш салкынча бинага керәбез, кондиционер астында, үтәли җилдә булабыз. Җылыдан кисәк кенә салкынга күчү аркасында мускулларның киеренкелеге арта һәм алар ялкынсынырга мөмкин. Аеруча муен, күкрәк, бил мускуллары ешрак зарарлана.

Миозитны остеохондоз белән бутарга ярамый. Остеохондроз – умыртка баганасы сөякләрен һәм буыннарын зарарлый, ә миозит вакытында мускулларга зыян килә.

Төгәл диагнозны ачыклау өчен, әлбәттә, табибка мөрәҗәгать итәргә кирәк. Ситуациягә карап, ул рентген, МРТ яисә РКТ билгеләи.

Миозитның катлауланулрсыз узучы җиңелрәк формаларын амбулатор шартларда дәвалыйлар.

Мазьлар, коры җылы гына ярдәм итмәгән очракта магнитлы физиотерапия, гирудотерапия, энә кадап дәвалау ысуллары, массаж, дәва физкультурасы кулланылырга мөмкин. Әмма боларның барысы да бары тик табиб күрсәтмәсе белән генә башкарыла. Белер-белмәс дәвалануның җитди өзлегүләргә китерүе ихтимал.

Табиб киңәш итә:

- үз-үзеңә иң беренче ярдәм – авырткан мускулны тынычлыкта калдыру;
- табиб билгеләве буенча ялкынсынуны басучы нестероидлы препаратлар кабул итеәә;
- авырткан урынга коры җылы куярга, җылыта торган мазьлар кулланырга була;
- авырту бик кискен булганда, шешенкелек күзәтелсә, беренче көннәрдә кайнар мунчага керү тыела. Мунча керү мускулларның шешенкелеген тагын да арттырырга мөмкин.

Сәбәпләре:

- теләсә кайсы вируслы инфекция (грипп, ОРВИ);
- инфекция;
- аутоиммун чирләр;
- токсин матдәләр йогынтысы (алкоголь, наркотик матдәләр);
- травмалар, физик нагрузкалар;
- туңу, үтәли җилдә булу;
- озак вакыт мускулларның статик киеренкелеге, җайсыз халәттә булуы.

Билгеләре:

- мускулларда локаль авырту барлыкка килә;
- хәрәкәтләнгәндә мускуллардагы авырту көчәя;
- хәрәкәтләнү кыенлаша;
- бармак белән баскалаганда авырта;
- кайчагында авырткан урында тән тиресе кызарып, шешенеп тора;
- субфебраль температура (сирәк очракларда);
- мускулларның хәлсезлеге.



Профилактика:

- юеш киемнән йөрмәскә;
- тирләгән килеш кондиционер кабызырга һәм үтәли җилдә утырырга ярамый;
- җылыдан кисәк кенә салкынга күчү мускуллар өчен зыянлы булуын онытмаска;
- мускулларны ныгыту һәм алардагы кан әйләнешен яхшырту өчен физик күнегүләр белән шөгыльләнергә;
- җайсыз халәттә эшләргә туры килсә, әледән-әле мускулларга ял бирергә;
- спорт белән даими шөгыльләнү, фитнес залларга йөрү, йөзү – мускулларның тонусын күтәрә. Чыныккан мускулларда миозит бик сирәк күзәтелә.



АШЛЫ-СЫЙЛЫ АВГУСТ

Җәйнең иң сыйлы, иң юмарт ае, мөгаен, августтыр. Июль җиләкләре, карлыганнары белән сыйласа, августта яшелчәләр өлгереп җитә – бакчалардагы муллыкка күңел сөенә.

Гөлбакча

Чәчәк үстерергә яратучылар өчен киләсе ел сезоны нәкъ менә августта башлана. Күчереп утыртабыз, чәчәбез, ашлыйбыз... Нәркиз гөлләренең суганчаларын август аенда да күчереп утыртырга була. Кышка кадәр аларның тамырлары ныгып калырга тиеш. Шул очракта гына алар кышны өшеми чыгачак. Шулай да туфракның җылылыгына карагыз, ул 10 градуска кадәр төшәргә тиеш.

Сөмбелләрне (гиацинт) шулай ук августта күчереп утырталар. Суганчаларны туфракка 15 см күмдерергә, ә араларын 12 см калдырырга кирәк.

Август пионнарны бүлгәләү өчен дә яхшы вакыт. Җәй азагына аларның суыручы тамырчалары инде корыган була. Гөл куагын бар яклап казып алып, берничә өлешкә бүләргә, тамырдагы яраларына коры утын көле сибәргә кирәк. Чалмабаш әче туфракны, су җыелып торганны, кызыл балчыклы, артык коры урынны яратмый. Утыртасы чокыр шактый зур – 60 см тирәнлектә, киңлеккә дә шул чама булсын. Бу урында аңа әле тагын 10 ел яшисе. Чокырга черемә салып калдырыла, ләкин тирес кулланырга ярамый. Утырткан вакытта йорт стенасыннан, биек агачлардан 2 метр ара калдырыгыз. Тамырларны бары 4–5 см чамасы гына күмдерергә кирәк. Пион кремний микроэлементына сизгер. Чокырына кош-корт каурыйлары салып калдыра аласыз. Бу аның өчен яхшы ашлама булачак.

Алты-җиде ел саен флокслар да яңа урынга утыртуга мохтаҗ. Флокслар тамыр муентыгыннан үсеп чыккан тамырчалар хисабына яңара. Тора-бара тамыр системасы шулкадәр зурая, яңа тамырчаларны җир өстенә этеп чыгара башлый. Флокс нейтраль реакцияле ашлы туфракта яхшы үсә. Чәчәк атуын озагракка сузу өчен, ярым күләгәле урынга утыртуы отышлырак.

Август аенда күпьеллык чәчәкләрне – купальница, лютик, горечавка, василистник, ветреница, виола, эхинацея, люпин, маргаритка орлыкларын туфракка чәчеп калдыралар.



Августта чәчәк атучы гөлләрнең барысы өчен дә бердәй кагыйдә – чәчәк бөреләре формалашкан чорда үсемлекләрне фосфорлы-калийлы ашламалар белән ашлау. 10 литр суга 2 аш кашыгы суперфосфат, 1 аш кашыгы калий сульфаты алына. Әмма августның икенче яртысыннан ашлауны туктаталар, үсемлек кышка әзерләнергә тиеш. Биек булып үсүче дәлия (георгин), туй чәчәкләре (гладиолус) көчле җилләрдән сынмасын өчен, аларны терәккә бәйлиләр. Дәлияләрнең бәрәңге бүлбеләре яхшырак өлгерсен өчен, төпләренә өяләр һәм аскы яфракларын өзәләр.

Яшелчәчегә

Яшелчә үстерүчеләр өчен август – уңыш җыю чоры. Суган, сарымсак, иртә өлгерешле бәрәңгеләрне казып алганнан соң, буш калган түтәлләргә иртә өлгерешле пекин кәбестәсе, кара торма, шалкан һәм редисның иртә өлгерешле сортларын, салат, укроп, кинза кебек аштәмләткечләр чәчәргә була. Үсәр өчен вакыт әле бар.

Кишернең үсеше тоткарланса, августта аны тирес сыекчасы белән ашлыйлар (10 литр суга 1 литр сыекча алына). Тамыразыклар кыш көне яхшырак саклансын өчен, августның икенче яртысында аларны хлорлы калий (10 литрга 50 г ашлама) белән тукландыралар.

Туфракны авырулардан йогышсызландыру да мөһим. Әлеге максаттан буш түтәлләргә «Байкал ЭМ-1» препараты сибәргә була. Ул җылы туфракта аеруча яхшы нәтиҗә бирә.

Җимеш бакчасы

Карлыган, куралары инде җыеп бетердек тә, оныттыкмы? Киләсе елның уңышы нәкъ менә хәзер формалашуын истән чыгармаска кирәк. Бар көчен җимешләр үстерүгә биргән куакларны август аенда калий (утын көле) һәм фосфор белән ашлыйбыз. Утын көленнән универсаль ашлама ясау өчен, 10 литр кайнар суга 0,5 литрлы банка белән коры көл салып төнәтелә. Карлыганнар эре, баллы булсын өчен, аларны крахмал белән тукландырганнарын белә идегезме? Иң кулай вариант – куак төпләренә бәрәңге кабыгы күмү. Бәрәңге кабыгыннан сыек ашлама да ясарга була. Бер өлеш кабыкка ике өлеш су салып, биш көн җылы урында төнәтергә һәм бер куакка 5 литр исәбеннән сибәргә.



Фото: www.pexels.com



Кадерле укучыларыбыз! «Сөембикә» журналы сайтында яңа фотоконкурс игълан итәбез. Бакчагызның иң матур, ямьле, күзләрне иркәләүче почмакларын фотога төшереп безгә юллагыз.
Адрес: 420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2 нче йорт. «Сөембикә» журналы редакциясе. Электрон адресыбыз: ssuum@yandex.ru яисә suumbike@tatmedia.com
Конкурсның нигезләмәсе – сайтта: www.syuyumbike.ru Нәтиҗәләр сентябрьдә ясалачак. Җиңүчеләрне бүләк көтә!



«ТОЛЛАР БӨКРЕСЕ»Н ЧЫГАРМЫЙК

Җиденче умыртка өстендәге май катламын русча «вдовий горб», диләр. Ул, нигездә, 40 яшьтән узган хатыннарда очрый иде. Моңа генетика, гормоннар эшләп чыгарудагы үзгәрешләр, артык авырлык сәбәпче. Әмма хәзер аннан яшьләр дә җәфа чигә башлады. Бу – аз хәрәкәтләнүдән, даими рәвештә компьютер алдында башны сузып утырудан. «Толлар бөкресе» чыкмасын өчен, махсус профилактик күнегүләр бар, аларны даими эшләсәгез, булган май катламын да бетерергә мөмкин», – ди массажист Ләйсән САБИТОВА.





✓ Күнегүне муен тирәсен җылытудан башлыйбыз. Җилкәләрне сикертәбез.

✓ Җилкәләрне өскә күтәрәбез дә, кисәк кенә аска ташлыйбыз.

✓ Кулларны алга-артка селтибез.


✓ Кулларны артка җибәреп, бармаклар белән йозак ясыйбыз да, булдыра алганча өскә күтәрәбез. Авыртыр, түзегез!



✓ Менә бу күнегү бик яхшы. Аны аерым да ясарга була. Стенага терәлеп басыгыз. Ике теннис тубын калак сөяге турысына куегыз. (Туп умыртка сөяге өстенә менәргә тиеш түгел!) Өскә, аска хәрәкәтләнеп, аларны умыртка буенча йөртегез. Бу – калак сөяге тирәсендәге мускулларны йомшартыр.



✓ Сул кул белән уң яктагы трапеция сыман мускулны артка этәбез, шул ук вакытта җилкәне әйләндерәбез. Без, гадәттә, җилкәләрне өскә күтәреп, бөкрәеп йөрүчән. Әлеге күнегү муен тирәсендәге мускулларны йомшарта.





✓ Хәзер башны күркә кебек хәрәкәтләндерәбез. Иякне алга җибәрәбез дә, су сосып алган кебек итеп ясыйбыз. Бу вакытта арка селкенергә тиеш түгел. Бары тик муен гына эшли.

✓ Иякне муенга якын китерәбез дә (бу вакытта икенче, өченче ияклар чыга икән, димәк, дөрес) башны уңга, сулга борабыз, аннан соң ян-якка янтайтабыз.

✓ Муен, җилкә мускуллары буенча массаж тубы йөртәбез.

✓ Кул белән дә трапеция сыман һәм муен мускулларын яхшы итеп ышкыйбыз.





Һәр күнегүне 10–15 тапкыр эшлибез. Көнгә берничә тапкыр кабатласагыз, тагын да яхшырак.



QR-код аша кереп, күнегүләрне видеодан да карап ясый аласыз.
Фото һәм видео: Анна Арахамия.

Паңнода... җәйнең хуш исе

Җәйнең хуш исләрен үзегез белән көзгә, кыш айларына да алып керәсегез киләме? «Моның өчен үләннәрдән панно үреп, бик матур кул эшләнмәләре ясарга була», – ди Светлана МЕДВЕДЕВА. Белгечлеге буенча Светлана – рәссам, Татарстанның Рәссамнар берлеге әгъзасы. 2000 нче елларда әнисенең дусты өйрәткән аны бу осталыкка. Беразга онытып торганнан соң, Идел буенда үзләре бакча йорты алгач, Светлана бу һөнәренә яңадан әйләнеп кайткан. Беренче панноларын әнисе белән бергә үргәннәр. Узган елны Светлананың әнисе вафат булган... Аның якты истәлеге булсын дип, туганнарына, дусларына бүләк итәр өчен, Светлана ханым яңа паннолар иҗат иткән. Үзенчәлекле кул эшенә бакчадагы күршеләрен дә өйрәткән хәтта. «Иң матур паннолар июль аенда үскән үләннәрдән үрелсә дә, җәй исләрен август аенда саклап калырга да соң түгел», – ди Светлана.







Үләннәрдән панно әзерләр өчен рама асты, вак кадаклар, чүкеч, калын йон яки җитен җепләр, зур тешле тарак, кайчы кирәк булачак.







■ Тыгыз, калын җитен җептән астагы беренче кадакка төен ясап, җепне өстәге кадакка сузыгыз. Өстәге беренче кадакны җеп белән бер тапкыр әйләндереп, янәшәсендәге икенче кадакка күчегез. Аннары астагы икенче кадакка төшегез. Анысын да шулай урап, янәшәдәге өченче кадакка күчәргә кирәк. Шул рәвешле бөтен кадакларны урап чыгыгыз.

■ Өстән аска сузылган җепләр арасына панноны тотып торачак таяк киертеп куегыз. Таякны кадаклардан 5–6 см өскәрәк беркетегез. Эш тәмамлангач җепләрне кисеп алганда, бәйләр өчен кирәк була бу ара. Таяк кулланмый да ясарга була. Аның астын соңыннан бисер, бахрома белән бизәп куярга мөмкин. Таяк кулланмаган очракта беренче 4–5 рәтне теләгән төстәге калын җеп белән үреп куярга кирәк. Җепләр арасыннан үткәрергә җиңелрәк булсын өчен, калын энә кулланыгыз. Палас суккан кебек, шахмат тәртибендә җепләрне кадакка тарттырылган җеп араларыннан үреп барасыз. Рәт ахырына җиткәч, әйләндереп, киретә таба икенчеләре астыннан үткәрегез. Шул рәвешле үрелгән панно нык була, сүтелеп китми.

■ Панно өчен яңа гына өзелгән үләннәр кирәк булачак. Шиңмәсен өчен, аларны суга утыртып торыгыз. Кипкәннән соң да формасын яхшы саклый торган үләннәргә өстенлек бирегез. Әрем, гөлбадран, меңъяфрак, арыш, бодай башаклары, сарут (пырей), чәнчәвек (синеголовник), үлмәс гөл (бессмертник) үләннәреннән ясалган панно уңышлы чыга.



■ Үләннәрне дә җепне керткән кебек үреп барыгыз. Үлән бер рәткә җитмәсә, янына икенчесен өстәп, шул ук рәт буенча дәвам итегез. Калынрак булсын өчен, берничә сабакны берьюлы үрергә була. Калын тешле тарак белән үләннәрне тарап, тигезләп барсагыз, алар кипкәннән соң да куе булып калырлар. Үләннәрне шул рәвешле, чиратлаштырып, шахмат тәртибендә үреп барыгыз. Арасына тагын 4–5 рәт калын җеп өстәргә була.

■ Панно бик хуш исле килеп чыга. Аны тагын да матурларга теләсәгез, төп өлеше үрелеп беткәннән соң, өстәмә үләннәр белән бизәп чыгарга мөмкин.

■ Кирәкле үлчәмгә кадәр үләннәр белән үргәннән соң, таяк, матур агач ботагы, йә калын башаклар белән тәмамлыйбыз. Шулай ук өстән дә таякка кадәр 5–6 см ара калырга тиеш. Таякны җепләр арасына керткәннән соң, өстәге һәр кадактан җепне кисеп, таякка бәйләп, беркетеп куябыз. Астагы җепләрне дә шулай ук кисеп, һәрберсен бәйләп куябыз.

■ Беренче чиратта рамны әзерләгез. Ул нинди үлчәмдә булса да ярый. Иске агач тәрәзә рамын куллансагыз да була. Иң мөһиме – ул нык булырга тиеш. Зур рама белән дә бәләкәй панно ясарга мөмкин. Озынча кирәкме, киңме – шулай ук формасын да үзегез теләгәнчә көйли аласыз.

■ Рамның аскы һәм өске өлешендәге алгы якка кадаклар кагыла. Һәр сантиметр саен бер сантиметр ярым биеклектә кадакларга кирәк. Кадакларны рамның бөтен киңлегенә кагып чыгыгыз.



Алсу ШАКИРОВА әзерләде.
Фото: Алексей МЕДВЕДЕВ.

AELITA ROOMS
8-987-228-29-99
@aelita_rooms
/ авторские шторы / люстры /
/ дизайн-проект / карнизы /
/ производство мебели /
Мы переехали. Ждем вас по адресу:
г. Казань, ул. Родины, 24 Б
РЕКЛАМА

Карлыганлы зефир

Зилия БУДАЙЛОВА – Казан кызы. Һөнәре буенча архитектор-проектлаучы ул, Казан дәүләт архитектура һәм төзелеш университетын тәмамлаган. Балачагыннан ук рәсем белән мавыгып, сәнгать мәктәбендә белем алган Зилияне нәкъ менә биналарны проектлаштыру шөгыле җәлеп итә. Уку дәверендә укытучыларыннан: «Ныклап уйладыгызмы, хатын-кыз эше түгел бу», – дигәнне бер генә ишетми. Шундый җитди һәм катлаулы эш белән шөгыльләнүче кызның десертлар әзерләү белән дә мавыгуына, бәлки, кемдер гаҗәпләнеп тә куяр. Кызыксынып кына башлаган бу эше хәзер аның яраткан хоббие. Төп эшеннән бушаган араларда тәмле тортлар, пирожныйлар, капкейк, зефирлар пешерә ул. Аш-суга тартылуы – әнисеннән. Ә менә татарча матур итеп сөйләшергә өйрәткәннәре өчен дәү әтисе белән дәү әнисенә рәхмәтле.
Проектлаштырудагы кебек үк, катлаулы десертлар әзерләүдә дә зур төгәллек кирәк. Ә Зилиядә төгәллек җитәрлек. Карап торышка гади генә кебек тоелган зефир әзерләүнең дә серләре шактый күп икән. Зилия безгә әнә шул серләрнең барысын да яшермичә ачты. Җиләк-җимешләр өлгергән чорда хуш исле алсу зефирларны аның белән бергәләп әзерлибезме?



Кирәк

(меренга өчен)
- 123 г йомырка агы;
- 130 г шикәр комы.

Ширбәт өчен
- 100 г су;
- 400 г шикәр комы;
- 200 г алма пюресы;
- 100 г җиләк пюресы (карлыган, кура, җир җиләге, чия, бөрлегән булырга мөмкин);
- 16 г агар.

Болардан тыш, үлчәү, кондитер капчыгы, пергамент кәгазе, миксер, термометр, шикәр оны да кирәк булачак. Беренче тапкыр әзерләгәндә барлык ингредиентларны да яртылаш кына ала аласыз.

Эш барышы

■ Йомырканың агын сарысыннан аерып, коры савытка (бу мөһим!) салабыз. Савытны үлчәүгә куеп, граммлап үлчәгез, чөнки ингредиентларның төгәл граммнарда булуы кирәк.
■ Йомырка агын миксер белән агарганчы күпертәбез. Кашыклап кына 130 г шикәр комын сала барабыз. Шикәр комы эреп, күбек кашыктан төшмәслек булганчы күпертүне туктатмыйбыз. Меренга әзер.
■ 16 г агар порошогын стаканга салып, 100 г су өстибез, бик яхшылап туглыйбыз.
■ Әзер алма пюресына (алманың кабыгын һәм төшен чистартып, йомшарганчы пешерергә һәм блендер белән издерергә кирәк) 100 г үзегез яраткан берәр төрле җиләкне салып, блендер белән бик яхшылап издерәбез. Аннары 400 г шикәр комын, суда җебеткән агарны кушып, савытны утка куябыз. Җиләк пюресы савыт төбенә ябышмасын өчен, гел болгатып торырга кирәк. Пюрены 108–110 градуска кадәр җылытабыз. Термометр булмаса, ширбәтнең әзерлеген белер өчен,



ике бармак арасында сузып карарга кирәк. Өзелмичә сузылса, әзер дигән сүз.

■ Ширбәтне нечкә генә агым белән меренга өстенә агыза барабыз, миксер белән туглый торабыз. Ширбәт белән йомырка агы тәмам кушылып бетәргә тиеш.

■ Зефирны салкынча бүлмәдә әзерләве җайлырак. Кондиционерыгыз яки җилләткечегез булса, аны алдан ук кабызып, бүлмәне суытыгыз. Зефирны тезәр өчен тактага пергамент кәгазе җәеп, әзерләп куегыз, чөнки меренга бик тиз куера.

■ Әзер массаны кондитер капчыгына салып, пергамент өстенә 4 см чамасы зурлыгындагы «роза»лар сытып чыгарабыз. Салкынча бүлмәдә меренга җәелми, зефирлар кабарынкы, матур була.

■ Зефирларны шул килеш биш-алты сәгатькә калдырабыз, кипшерсеннәр.

■ Кипшергән зефирларга өстән нечкә иләк белән шикәр оны бөркибез. Кәгазеннән сак кына кубарып, ике «роза»ны бергә ябыштырабыз.

Хуш исле, матур һәм гаҗәеп тәмле зефирлар әзер. Чәйләрегез тәмле булсын!



Видеоны карар өчен смартфонның камерасын QR-кодка якынайтыгыз.
Фото һәм видео: Анна Арахамия.

PRESSA



Алмадан десерт

Август – алмалы ай. Алма файдалы да, тәмле дә ул. Уңган хуҗабикәләр аннан кышка әллә ниләр әзерли. Киптереп тә куялар, компотын да ябалар, бәлеш эчләре әзерләп куялар... Бәлеше ничек тәмле алманың!!! Шулай да алмадан әзерләнә торган иң популяр ризык – шарлоткадыр, мөгаен. «Дөрес туклану» рубрикасы авторы Камилә ДИМӨХӘММӘТОВА бүген безгә шарлотканың чын-чынлап файдалысын һәм искиткеч тәмлесен әзерләргә тәкъдим итә.



Алма – витаминнар һәм клетчатка чыганагы. Ул органик кислоталарга, калий, натрий, кальций, магний, фосфор, тимер, йод кебек микроэлементларга бай. Агачтан гына өзгән алмаларда С, А, В витаминнары күп була. Ул организмны ныгыта, авыруларга каршы торучанлыкны арттыра. Алма кандагы холестеринны киметә, кан басымы уйнаганда шифа бирә, күз күремен яхшырта, чәч һәм тырнакларны үстерергә булыша. Бер алма ашап кую да озак вакытка тамакны тук тота. Ябыгырга теләүчеләр өчен алма – менә дигән файдалы ризык.

«Дөрес» шарлотка

Әлеге сый дөрес туклану кануннарына тулысынча җавап бирә. Эремчек һәм солы ярмасы аның файдалы үзлеген арттыра. Эремчекле шарлотка күпләрнең күңеленә хуш киләчәк. Камыр ясар өчен йомшак яки бөртекле эремчек алырга була. Бөртеклесен кулланcагыз, аны башта блендер белән вакларга кирәк.

Кирәк:

• 400 г эремчек;
• 4 йомырка;
• 110 г озак пешә торган солы лачавы (аны да блендер яки кофетарткыч белән онланганчы ваклыйбыз);
• 3 уртача зурлыктагы алма;
• 0,5 чәй кашыгы камыр көпшәкләндергеч;
• 0,5 чәй кашыгы дарчин (корица);
• тәменчә шикәр алыштыргыч.

Эш барышы:

■ Эремчекне блендер белән ваклыйбыз (бөртекле булса). Куе күбек булганчы, аерым савытта блендер белән йомырканы күпертәбез.
■ Йомырканы эремчеккә кушып, дарчин, камыр көпшәкләндергеч һәм солы онын өстибез. Яхшылап тугълаганнан соң, камыр шактый куе булырга тиеш.
■ Чистарткан алмаларны шакмаклап турап, камырга кушабыз.
■ Табаны яки махсус форманы майлап (он гына сипсәң дә була), камырны агызабыз. Өстен тигезлибез.
■ Эремчекле шарлотка 180 градус кызулыктагы мичтә 30–40 минут пешә (конвекция режимын кулланмыйбыз).
■ Әзер шарлотканы формасыннан алмыйча, суынганын көтәбез.

Алмалы-эремчекле десерт

Кирәк:

• 250 г майсыз эремчек;
• 2 алма;
• 1 йомырка;
• 2 аш кашыгы бал;
• 50 г әстерхан чикләвеге (грецкий).

Эш барышы:

■ Кабыгын әрчеп, төшен алган алмаларны эре угычтан уабыз.
■ Тирән эчле савытта йомырка, эремчек һәм уылган алмаларны кушып туглыйбыз.
■ Әзер массаны кечерәк формаларга салып, 200 градус кызулыктагы мичтә 15 минутлап пешерәбез.
■ Әстерхан чикләвеген пычак яисә блендер ярдәмендә ваклыйбыз.
■ Өсте алланган шарлотканы мичтән алып, бал ягабыз һәм чикләвек сибәбез



Фото: www.pixabay.com

арыслан хатын-кыз

Арыслан йолдызлыгы астында туган хатын-кызлар горур, максатчан, үз-үзенә ышанган, уңышка, популярлыкка омтылучан була. Еш кына эмоцияләр һәм хисләр шаукымына бирелләләр. Кыю да, киң күңелле дә бу ханымнар. Һәр ситуациядә үзләрен тота беләләр, игътибар үзәгендә булырга яраталар. Бик яхшы хуҗабикәләр.

Мәхәббәт. Арыслан – мәхәббәттән, игътибардан башка яши алмый. Романтик хисләр кичергән вакытта чын холкын күрсәтергә сәләтле. Ул сайлаган ир-ат уңышлы, максатчан, көчле булыр. Гашыйк Арыслан оялчан, ләкин барысын да үз кулына алып, беренче адымны ясарга да мөмкин. Мөнәсәбәтләрне контрольдә тотарга ярата.

Мөнәсәбәтләр. Арысланнар юл куярга яратмыйлар, үз фикерләрен алга сөрәләр. Шуның аркасында дуслары да күп түгел. Холкы буенча – командир, шуңа күрә эше уңышлы бара, хезмәттәшләрен тыңлату сәләтенә ия. Юмарт һәм тугры була белә, сайланып төзелгән мөнәсәбәтләре дәвамлы, хәтта гомерлек була.

Гаилә. Оештырырга һәм бар нәрсәне дә контрольдә тотарга яратучы Арысланнан яхшы хуҗабикә, кайгыртучан әни чыга. Чисталыкка да, ризык әзерләүгә дә, үз кыяфәтенә дә игътибарлы. Төрле чараларга йөрергә, кунак каршыларга ярата. Үз бәясен арттыру өчен башка ирләрнең игътибарын җәлеп итүчән. Ләкин иренә һәрвакыт тугры булып кала.

йолдызнамә сентябрь

Кучкар. Җаваплы эшләр, көндәлек мәшәкатьләр белән мәшгуль булырсыз. Боларны башкару һәрвакыт энергияне ала, үзегезне гел бәйдә итеп тоярсыз, бәлки. Шуңа күрә иммунитетыгыз какшарга мөмкин, авырып китүдән сакланыгыз. Машина, фатир сату кебек эшләр өчен бик уңышлы вакыт.

Үгезбозау. Сезнең өчен уңдырышлы һәм кызу ай башлана. Тормышның яхшы якларын гына күрә белү сәләтегез көч, энергия бирер. Ләкин туры сүзле булып, фикерегезне бәреп әйтүдән сакланыгыз. Спортта һәм иҗатта яңа үрләр яулый алырсыз.

Игезәкләр. Өй эшләре, йортыгызга үзгәрешләр кертү белән шөгыльләнер өчен кулай вакыт. Ремонт ясагыз, яңа җиһаз сатып алыгыз, нәрсәне дә булса алыштырыгыз. Үзенчәлекле фикер йөртүче кешеләр белән танышуыгыз ихтимал. Алар сезгә тормышның яңа якларын ачарга ярдәм итәр.

Кысла. Бар яктан да уңышлы ай. Тән һәм җан сәламәтлелеге юлдаш булыр. Дусларыгыз, хезмәттәшләрегез аркылы яңа проектларга кереп китәрсез, эшлекле һәм иҗади активлык күрсәтерсез. Җитәкчелеккә мөрәҗәгать итү, спонсорлар эзләү дә уңай нәтиҗә бирер.

Арыслан. Сәламәтлек ягы бераз какшап китәргә мөмкин. Шуңа күрә тотынган эшләрегезнең нәтиҗәсе максатчанлыгыгызга бәйле. Холкыгызның бу ягы барлык киртәләрне җиңеп, уңышка ирешергә ярдәм итәр. Айның икенче яртысыннан яңа проектларга алынмавыгыз хәерле.

Сөмбелә. Сезнең өчен елның иң уңышлы ае булыр бу. Сәламәтлегегез ныгыр, тормыш энергиягез яңарыр. Җилкәгездән авыр йөк төшкән кебек хис итәрсез. Мондый күтәрелеш чоры үзегезне төрле яклап ачарга, көчегезне, талантларыгызны күрсәтергә бер этәргеч булсын. Тәвәккәлләгез!

Бизмән. Сентябрьнең беренче яртысында энергетикагыз үзгәрә торган вакыт. Шуңа күрә төшенкелек сизелер. Айның икенче яртысында башлаган эшләрегезне тәмамларга, бурычлардан котылырга кулай вакыт. Һәрнәрсәгә позитив карашыгыз сезгә игътибар җәлеп итәр, киңәш сораучылар күп булыр.

Чаян. Коллектив иҗат, эшлекле мөнәсәбәтләр өчен бик уңышлы вакыт. Шул нисбәттән, айның беренче яртысы аралашуларга, актив тормыш рәвешенә бай булыр. Ай азагына таба сездән вакыйгалар үзгәрешенә тиз яраклашу таләп ителер. Башкалар фикеренә дә колак салыгыз.

Укчы. Бу ай активлыгы белән аерылып тормаса да, тынычлап утырыр вакыт түгел. Эшегездә үзгәрешләр, яңа вазыйфалар ачылырга мөмкин – читтә калмагыз. Үз фикерегездә нык торыгыз, кечкенә шансларны да кулдан ычкындырмагыз. Максатка ирешү өчен киртәләргә игътибар итмәгез.

Кәҗәмөгез. Айның беренче яртысы профессиональ яктан бик кызу үтәр. Яңа мөмкинлекләр, перспективалар ачылыр. Идеяләрегез ярдәмендә популярлык казануыгыз мөмкин. Үз-үзегезне күрсәтергә, яңа үрләр яуларга кулай вакыт. Айның икенче яртысында амбицияләрегезне бераз артка чигерү киңәш ителә.

Сукояр. Бик күптән үзгәрешләргә омтыла идегез, бу айда аларга ирешерсез. Сезнең алда яңа ишекләр ачылыр. Мөнәсәбәтләр ачыклау белән шөгыльләнмәгез, акча ягына игътибарлы булыгыз. Оештыру сәләтегезне күрсәтер өчен кулай чор.

Балыклар. Командада эшләү өчен уңышлы вакыт. Үзегез генә яңа эшләргә тотынмагыз. Бердәмлектә – көч. Үз эчегезгә йомылу аркасында конфликтлар, аңлашылмаучанлык килеп чыгарга мөмкин. Шуңа күрә хисләргә бирелеп китүдән сакланыгыз. Барысы да сезнең кулда.

«Хатын-кыз галәме» сәхифәсен Алсу ШАКИРОВА, Чулпан ГАЛИӘХМӘТОВА, Лилия ГӘРӘЕВА әзерләде.







ҖАН ТАЛӘБЕ

Соклану, уйлану, милли гамь, ачык төсләрдән курыкмау һәм... төзелеш пумаласы. Яшь рәссам Ләйсән Галимова картиналарында менә шушындый бөтенлек. Кайчандыр, әле Чаллының 1 нче номерлы сәнгать мәктәбендә, аннан сәнгать училищесында укыганда, акбур, күмер, сангина ярдәмендә картиналарга әверелгән хисләр елдан-ел яңа төсмерләр белән байый бара. Бүген кулда гап-гади төзелеш пумаласы. Әйе, әйе, киндергә майлы буяу белән төшкән күңел матурлыгын чагылдыру өчен шуннан да уңайлысы юк кебек. Ник дисәң, ун елдан артык Чаллы Татар дәүләт драма театрында бутафор-рәссам булып эшләү дәверендә кулларга нәзберекләнеп торырга туры килми, монда ирләрчә бер ныклык белән тотыну таләп ителә: чүлмәген дә, курчагын да, хәтта «бетон» стенасын да ясарга кирәк! Ә менә картиналар... Алар – җан таләбе. Аларда – «безнең милләткә Россиядә яшәгән халык дип кенә карамасыннар иде. Шундый зур тарихыбыз бар, уйлана, горурлана белсәк иде», – дигән якты гамь. Ләйсәннең байтак картиналары Болгар тематикасын чагылдыра, рәссамның тарихны, төрле риваятьләрне яхшы белүен ассызыклый. «Биек үлән арасында. Апа-сеңел» картинасына гына күз салыгыз. Дәүләтен яклап, кулына корал алган кызлар. Аларның карашында бераз гына сагаю да, ныклык та, үз-үзләренә ышаныч та чагыла. Аркада – ук-җәя, кулда хәнҗәр булуга карамастан, алар иң беренче чиратта – хатын-кыз! Картинага озаклап текәлеп торсаң, озын толымнарга кушып үрелгән көмеш чулпыларның, колактагы көмеш алкаларның чыңы ишетелер кебек... (Бу җәһәттән рәссамның борынгы бизәнү әйберләрен өйрәнү өчен музейларда еш булуын искәртеп үтү кирәк.) Бүген Биләр музеен бизәгән «Ныклык» картинасында да көрәшче хатын-кыз йөзендәге кылыч кырыслыгын һәм кылган йомшаклыгын күрергә мөмкин. Биләрнең үз туфрагында, Кызлар тавында рәссамның агачларны коча-коча алган хис-тойгыларыннан яралган сурәт бу. «Бию», «Ауда», «Сугышчы кыз», «Болгар көрәшчеләре» картиналары үзләре тулы бер цикл тәшкил итә, аларда – халкыбызның көчле рухлы кыз-уллары үзәк урын били.

«Сөембикә улы Үтәмешгәрәй белән» картинасында игътибарны аеруча җәлеп иткәне – ханбикәнең куллары. Монда да рәссамның капма-каршылыкны бербөтен итүе ярылып ята: сулы – улын кочкан назлы ана кулы, анда наз да, җылылык та, йомшаклык та; уңы – дәүләт кадәр дәүләт белән идарә иткән хаким кулы. Йодрыкка йомарланмаса да, аннан көч һәм ныклык бөркелә. Арткы пландагы кичке караңгылык һәм ярым айлар күзендә – билгесезлек, сискәнү, нидер көтү...

Соңгы елларда язылган картиналарда зәңгәр, сары, шәмәхә төсләрнең шактый кыю рәвештә өстенлек итүен күрми калып булмый. Моның үзенә күрә кечкенә генә сере дә бар икән. «Мин элек ачык төсләрдән курка идем. Укыганда да безне алардан качарга өйрәттеләр. Берничә ел элек танылган рәссам Мәдияр Хаҗиев курсларына йөреп дәресләр алдым, һәм ул мине бөтенләй яңа яктан «ачты». Үземнең экспрессионист булуыма инандырды», – ди Ләйсән.

Рәссамның иҗатына игътибарым аның Ринат Гобәйдуллин портретын ясап утырган мәлендә башланды. Чаллы сиреньнәре белән бизәлгән картина мәрхүм композиторның шул исемдәге җырына гына түгел, рухына мәдхия булып тоелды. Гаҗәеп төгәл сызыклар белән аның күз карашын, басып торуын, кул хәрәкәтен чагылдыра алуы башкаларны да битараф калдырмаган – әлеге картина Чаллыда үткәрелгән бәйгедә беренче урынны яулаган икән. Ләйсән Илдар кызы – Татарстан Рәссамнар берлеге әгъзасы, картиналары Россиядә уздырылган күргәзмәләрдә куелып килә, Чаллыда үзенең шәхси күргәзмәсе дә уздырылган. Хәзинәсендәге натюрмортлар, портретлар, татар халык әкиятләренә, эпосларга таянып язылган картиналар да байтак.

Айгөл ӘХМӘТГАЛИЕВА











ЛӘЙСӘН ГАЛИМОВА

12+

«КИТАП» ТЫҢЛА!

КИТАП МИЛЛИ радио

КАЗАН 98,6 FM



АО «ТАТМЕДИА» Адрес: 420066, г. Казань, ул. Декабристов, д. 2 ГРН 1071690057834

РЕКЛАМА



